ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

ЗНАМЕНИТЫЕ ЛИЧНОСТИ



# Галимҗан ИБРАҺИМОВ

# *Галимҗан Ибраһимовның тормыш юлы һәм эшчәнлеге турында*

## Кайбер диссертацияләрдән үрнәкләр



Казань – 1967



КАЗАНСКИЙ ОРДЕНА ТРУДОВОГО КРАСНОГО ЗНАМЕНИ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ имени В. И. УЛЬЯНОВА-ЛЕНИНА

*На правах рукописи*

М. Ш. МАННУРОВА

ИНТЕРНАЦИОНАЛЬНЫЕ ИДЕИ И ОБРАЗЫ В ТАТАРСКОМ ИСТОРИКО-РЕВОЛЮЦИОННОМ РОМАНЕ

(Изображение русского революционера в романах Г. Ибрагимова, К. Наджми, Н. Гази)

(10. 642 — Литература народов СССР)

Автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата филологических наук.

Казань — 1971 г.



ТВОРЧЕСТВО ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Автореферат

Казань—1961



ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСТОРИИ им. Г. ИБРАГИМОВА

КАЗАНСКИЙ НАУЧНЫЙ ЦЕНТР РОССИЙСКОЙ АКАДЕМИИ НАУК

На правах рукописи

САДЕКОВА АЙСЛУ ХУСАИНОВНА

ФОЛЬКЛОР В ЭСТЕТИКЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

10.01.03 Литература народов СССР (татарская литература)

АВТОРЕФЕРАТ



НАТУРАЛИЗМ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

АВТОРЕФЕРАТ





На правах рукописи

РУССОИСТСКИЕ ТРАДИЦИИ В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

10.01.02 – Литература народов Российской Федерации (татарская литература)

Автореферат

Казань – 2009



## Кайбер гыйльми хезмәтләрдән үрнәкләр




























С.Ш. Поварисов
Роль Г. Ибрагимова
в развитии татарского
литературного языка


Суфиян Сафуанов
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
ҺӘМ
БАШКОРТСТАН
Уфа 2000


Галимджан
Ибрагимов


С.Ш. Поварисов
Галимджан Ибрагимов
и татарский
литературный
язык


Галимджан
Ибрагимов


Галимҗан Ибраһимовның
иҗат дөньясында
В мире творчества
Галимджана Ибрагимова


С.Ш. ПОВАРИСОВ
ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ –
ВЕЛИЧАЙШИЙ МАСТЕР
ХУДОЖЕСТВЕННОГО СЛОВА


АКАДЕМИЧЕСКИЙ ЦЕНТР
НАРКОМПРОСА ТАССР
Документы и материалы


МИРАСХАНӘ
РУХИ МИРАС
ЭЗЛӘНҮЛӘР ҺӘМ ТАБЫШЛАР
ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ
ПОИСКИ И ОТКРЫТИЯ

## Кайбер гыйльми конференцияләр

*(Казан, Яр Чаллы, Уфа, Стәрлетамак. 1967–2017 еллар)*



















Галимҗан
Ибраһимов
Чакыру


«ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ һӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН»


ПРОГРАММАСЫ
ПРОГРАММАҺЫ


1887
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
2007
ТАТАР ЯЗУЧЫСЫ,
ГАЛИМ,
ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ
туууына 120 ел


1 2 0
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ


120
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ һәМ XXI ГАСЫР
ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ И XXI ВЕК


ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
һӘМ XXI ГАСЫР


Галимҗан Ибраһимов мирасы
һәм хәзерге заман


Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ
һӘМ ТӨРКИ ДӨНЬЯ


ПРОГРАММА


125
Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ ҺӘМ ТӨРКИ ДӨНЬЯ
НАСЛЕДИЕ Г. ИБРАГИМОВА И ТЮРКСКИЙ МИР


ПРОБЛЕМЫ ИЗУЧЕНИЯ
И ПРЕПОДАВАНИЯ ТЮРКСКОЙ ФИЛОЛОГИИ:
ИСТОРИЯ, СОВРЕМЕННОСТЬ, ПЕРСПЕКТИВЫ


Ибрагимовские чтения


130
НАСЛЕДИЕ
ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА
В КОНТЕКСТЕ МНОГООБРАЗИЯ КУЛЬТУР
МӘДӘНИЯТЛӘР
ТӨРЛЕЛЕГЕ КОНТЕКСТЫНДА
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ
Сборник
материалов конференции


130
НАСЛЕДИЕ
ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА
В КОНТЕКСТЕ МНОГООБРАЗИЯ КУЛЬТУР
МӘДӘНИЯТЛӘР
ТӨРЛЕЛЕГЕ КОНТЕКСТЫНДА
ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ
Программа конференции

## Документаль, әдәби әсәрләр















## Кайбер рәсем һәм сынлы сәнгать үрнәкләре



Рәссам П. Беньков эше. 1926



Г. Ибраһимов туграсы.
Хаттат Н. Нәкъкаш эше. 2007



Рәссам Л. Фәттахов эше. 1971



Рәссам М. Рәхимов эше. 1977



Сынчы Б. Урманче эше. 1963



Сынчы Б. Урманче эше. 1968



Сынчы З. Басыйров эше. 1987

## Г. Ибраһимовның кайбер әдәби әсәрләренә иллюстрация үрнәкләре



Рәссам Л. Анисимов эше



Рәссам Т. Хаҗиәхмәтов эше



Рәссам Н. Байбурин эше

## Театр сәнгатеннән үрнәкләр




«Яңа кешеләр» спектакленең афишасы. Уфа, Башкорт дәүләт театры. 1928, 16 март




«Алмачуар» спектакленең программасы. Казан, Татар дәүләт яшь тамашачылар театры. 2004



«Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән күренеш. Г. Камал ис. Татар дәүләт академия театры. Казан, 1978

## Исемен мәңгеләштерү



Г. Ибраһимовның Солтанморат авылындагы музееның әүвәлге бинасы. 1987–1993



Г. Ибраһимовның Солтанморат авылындагы музееның яңа бинасы




**Казанда Г. Ибраһимов исемендәге 17 нче санлы гимназия һәм әдипнең бюсты. 2020**



**Казанда Г. Ибраһимов проспекты. 2020**



Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты бинасы. Казан, К. Маркс ур., 12. 2020






Г. Ибраһимовның 120 еллыгына багышланган фәнни конференциянең күкрәк билгесе. 2007

Авыргазы районы хакимияте тарафыннан гамәлгә куелган Г. Ибраһимов исемендәге премиянең күкрәк билгесе. 1996




**Уфада Г. Ибраһимов исемендәге бульвардагы 25 нче санлы йорт диварына куелган барельеф. 2010**




**Ялтада Халтурин урамындагы 5 нче санлы йорт диварына куелган истәлек тактасы. 2008**




**Казанда Архангел зиратында Г. Ибраһимов җирләнгән дип фаразланган урынга куелган истәлек билгесе. 2020**

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ – ДОКУМЕНТЛАРДА

**2 том**

Совет чоры документлары

Казан
«Җыен» нәшрияты
2020

ББК 83.3(2Рос=Тат)
И13

*Редколлегия:*
Р. И. Вәлиев, М. Б. Галиев, Х. Й. Миңнегулов, И. Г. Һадиев,
Ф. М. Рәфыйков, Ф. Ш. Сафиуллин

*Фәнни мөхәррир:*
Җәүдәт Миңнуллин,
тарих фәннәре кандидаты

*Төзүче:*
Рәмил Исламов,
филология фәннәре докторы

*Бәяләүче:*
Хатыйп Миңнегулов,
филология фәннәре докторы, профессор

И13 **Галимҗан Ибраһимов – документларда: 2 томда** / Төзүче: Р. Ф. Исламов, филология фәннәре докторы. – Казан: Җыен. 2020. – 2 т.: Совет чоры документлары. – 672 б. («Шәхесләребез» сериясендә)

ISBN 978-5-902783-49-7

Ике томлы хезмәтнең икенче томына татар әдәбияты классигы, галим, педагог, публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Батыры Г. Ибраһимовка (1887–1938) мөнәсәбәтле совет чоры документлары (хатлар, телеграммалар, мөрәҗәгатьләр, автографлар, котлаулар, репрессия һәм аклау чоры документлары, шәхси тормышына караган һәм исемен мәңгеләштерү документлары, тормышы һәм эшчәнлеге хроникасы, яшәгән фатирларының, кунакханәләрнең һәм ул булган йортларның, төрмәләрнең исемлеге, яңа библиографиясе) тупланды. Биредә урын алган документларның күбесе беренче мәртәбә һәм оригиналда китерелә.

Китап әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүче киң гавамга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-902783-49-7

© «Җыен» нәшрияты, 2020
© Р. Ф. Исламов, төзү, 2020

# V
# СОВЕТ ЧОРЫ ДОКУМЕНТЛАРЫ

## ХАТЛАР

### 1918
### Письмо В. И. Ленину от заместителя Комиссариата по делам мусульман Г. Ибрагимова[1]

1 сентября 1918 г.

Тов[арищу] Ленину

Коллегия Центрального мусульманского Комиссариата по поводу преступного покушения на вождей мирового пролетариата тов[арища] Ленина[2] и предательского убийства тов[арища] Урицкого[3] выражает глубокое негодование по адресу убийц, предателей революции, и призывает мусульманский пролетариат теснее сплотиться вокруг вождей революции и Советской власти, взять их под свою защиту и быть готовыми к беспощадной борьбе с контрреволюцией.

Заместитель председателя Комиссариата Г. Ибрагимов

---

[1] Төп нөсхә элекке СССР Октябрь революциясе Үзәк дәүләт архивында саклана (130 ф., 2 тасв., 454 эш, 148 кәг.). Текст «В. И. Ленин и Татария: Сборник документов, материалов и воспоминаний. Издание второе, исправленное и дополненное» дигән китаптан алынды (Казань, 1970, с. 207–208).

[2] *…преступного покушения на вождей мирового пролетариата тов[арища] Ленина* – 1918 елның 30 августында Михельсон заводында эсер-террористка Фаина Ефимовна Каплан (Феги Ройдман) пистолеттан Ленинга ата һәм аны яралый. Рәсми аңлатма шулай, ләкин бу вакыйгада әле ачыкланып бетмәгән моментлар бик күп.

[3] *…предательского убийства тов[арища] Урицкого* – Моисей Соломонович Урицкий (1873–1918), Россиядә революция хәрәкәте эшлеклесе. Эсерлар тарафыннан атып үтерелә.

## 1920
## Эшче-крәстиән иптәшләргә белдерү[1]

3 декабрь 1920 ел

Иҗтимагый революция хәрәкәте бөтен дөньяның матди-мәгънәви көчләрен бер-беренә каршы көрәшкән ике сафка аерым ачык рәвештә оештырып җиткерде. Хакыйкый азатлык әмәлләре юлында меңнәр, миллионнарча корбаннар биреп көрәшмәктә булган хезмәт халыкларының алдында баручы бәйнәлмиләл пролетариат һәм аның юлдашларыннан авыл-шәһәр ярлылары өчен бердәнбер юл, бердәнбер оешма Өченче Коммунист Интернационалы[2] икәнлеге өч-дүрт еллык канлы көрәштә һәркемгә ачылып җитте.

Хәзер тарих шундый бер дәвергә килеп керде ки, гөруһ[3] фанатизмнарын ташлап, Советлар ысулы, гамәлдә интернационализм, пролетариат диктатурасы һәм коммунизм яклы барлык көчләрнең бер мәркәзгә буйсынган бәйнәлмиләл бер оешма тупланулары үзеннән-үзе бер бурыч булып әверелде.

Менә шул хәлләр хәзер һәрбер революционерны Өченче Коммунист Интернационалы [өчен] үзенең көчен тапшырырга чакыра, революционер вөҗданы өчен бердәнбер юл шунда икәнен исбат итә.

Дүртенче елы барган революциянең һәммә дәверләрендә, һәммә фаҗигаләрендә коммунист иптәшләр белән бергә барганлыгым, ике партия (РКП белән Л[евый] С[оциалистический] К[оммунистический] И[нтернационал]) арасында булып үткән ихтиляфларның[4] һәрберендә пролетариат хакимияте ягында калуым, фикердә һәм гамәлдә өч ел буенча бөтенләй РКП белән бергә эшләгәнлегем һәммә иптәшләрнең күз алдында иде.

---

[1] «Эшче» газетасының 1920 елгы 3 декабрь санында «Идарәгә мәктүпләр» рубрикасында, аннан соң «Кызыл Армия» газетасының 1920 елгы 7 декабрь саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 104–105) басылган. Текст «Эшче» газетасыннан алынды.

[2] *Өченче Коммунист Интернационалы* – 1919–1943 елларда инкыйлаби эшчеләр хәрәкәте бурычлары һәм мәнфәгатьләренә яраклы рәвештә төзелгән халыкара оешма; 1 һәм 2 нче Интернационалның дәвамы.

[3] *Гөруһ* – төркем.

[4] *Ихтиляфларның* – каршылыкларның.

Бу бергәлекне рәсмиләштерү өчен үзенең идеологиясе һәм тактикасы белән камил бөлгенлеге ачылган сул социалист революционер-интернационалистлар партиясеннән чыгып, бәйнәлмиләл пролетариатның юлбашчысы Өченче Коммунист Интернационалның Русиядәге секциясе – Русия коммунист большевиклар партиясенә керүемне эшче-крәстиән иптәшләргә, фикердәшләргә рәсми рәвештә белдерәм.

Галимҗан Ибраһимов,
1920 ел, ноябрь 30 – Казан

## 1922
## Безнең заманның Әбуҗәһелләре, Ишмиләре, Пуришкевичләре
## (Яшьләргә ачык хат урынында)[1]

1922, № 2

Мәмләкәттә булган җимереклекне, ачлыкны бер дәрәҗәдә җиңеләйтү өчен килеп чыккан яңа икътисади сәясәт буржуазияне бераз аякка бастырды. Аңа вак-төяк мастерскойлар, завод-фабрикалар, кибетләр, магазиннар ачарга юл бирде. Моның аркасында әле кичә генә пролетариат алдында калтырап торган сыйныфлар хәзер инде үзләрен бераз көчәйгән кебек, бераз ныгыган кебек сизәләр.

Хәзер алар, кибетләр, завод-фабрикалар ачу белән генә тукталмыйча, мәктәпләргә, театрга, көтепханәләргә, әдәбият дөньясына кул сузарга омтылмак булалар, яңа икътисади сәясәт бит хәзер, дип, үзләренең иске идеологияләре белән халыкның миләрен, йөрәкләрен агуларга һәртөрле чаралар эзлиләр, планнар коралар. Караңгы авылларда элекке заманның һәртөрле җен-карачкылары баш күтәрде. Үзләренең бөтиләре, тәсбихләре, «Иман шартлары» белән яшь буынның җанын каралыйлар. Шәһәрләрдә дә дини-милли каралыкларның реакция өчен терәк булачагын аңлаган буржуалар һәм аларның ялчылары булган кайбер муллалар, кайбер контр мөхәррирләр бу караңгы почмаклардан, каберстаннардан терелеп чыгар өчен кузгала башлаган үлекләрне яклыйлар, шуларны тере дип, җанлы кеше дип, дини, милли теләк дип якларга маташалар.

Кыскасы, әллә кайларда, чормаларда, базларда яткан кара, пычрак бер сөрем һаваны агуламак була. Буржуазия кибет ачып, чак кына матди көч алу аркасында, идеология дөньясын да үзенең пычрак фикерләре белән нәҗесләмәк була. Моның өчен халык тормышындагы һәрбер авырлыктан файдаланырга тели.

[1] «Кызыл Шәрык яшьләре» журналының 1922 елгы 2 нче санында (б. 23–25), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 106–109) бастырылган. Текст журналдан алынды.

Ачларга ярдәм дигән булып Уфа Духовный собраниесе хөкүмәткә үзенең «хезмәтен» тәкъдим кыла[1] да шул арага бер дини журнал, дини әсәрләр басу өчен бер матбага ачарга план кора[2]. Галимҗан мулла үләксәсен[3] әллә нинди дини-милли караңгылыклар юлына корал итү өчен зур демонстрация ясарга маташып карый.

Контрреволюция каберстаныннан күтәрелгән бу черек исле сөрем хәзер инде мәсьәләнең кая барырын аңлап җитмәгән безнең иптәшләр, кайбер язучылар, артистлар, укытучылар арасында үзенең кара сукмагын салырга, сиздермәстән анда да агуын чәчәргә уйлый.

Мисаллары күз алдында.

Татар контрларыннан беренең «Зөләйха»сын кую өчен чаралар эзләп маташтылар[4]. Тик эшче-крәстиән угылларының

---

[1] *Ачларга ярдәм дигән булып Уфа Духовный собраниесе хөкүмәткә үзенең «хезмәтен» тәкъдим кыла* – Уфада Эчке Россия һәм Сибирия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтендә 1921 елда Ачларга ярдәм комиссиясе төзелә. Аның рәисе казый Кәшшаф Кыяметдин улы Тәрҗемани (1877–1943) була. Өстәмә кара: Таһиров И. Ачлык фаҗигасе / И. Таһиров // Мирас.– 1996.– № 4.– Б. 101–105.

[2] *…бер дини журнал… ачарга план кора* – Уфада Эчке Россия һәм Сибирия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте каршында казый К. Тәрҗемани наширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Ислам мәҗәлләсе» дигән айда бер мәртәбә чыга торган дини, әхлакый вә фәлсәфи журналның беренче саны 1924 елның 2 августында дөнья күрә. 1927 елда туктатыла.

[3] *Галимҗан мулла үләксәсен* – Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев (Баруди) (1857–1921), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, җәдитчелек тарафдары, 1881 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен нигезли һәм аның җитәкчесе була. 1917–1921 елларда Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе (мөфти) вазифасында була. Идел буенда ачлыктан интегүчеләр өчен ярдәм оештыру максаты белән Мәскәүгә баргач, 1921 елның 6 декабрендә кинәт вафат була. Аның җәсәде махсус вагон белән 13 декабрьдә Казанга алып кайтыла. Дәфен кылу мәрасимендә бик күп халык катнаша. Бу вакыйгага карата Г. Ибраһимов үзенең мөнәсәбәтен шулай белдерә. Мөфти хәзрәтләренә карата бу хәкарәтле сүзләр Г. Ибраһимовтан алда Г. Касыймовның «Солтангалиевчелек һәм аның тарихи тамырлары» дигән китабында әйтелә: «Шул 23 нче елда булырга кирәк, Мәскәүгә барган җирендә… мөфти Галимҗан Баруди үлеп кала. Казан солтангалиевчеләре моның өчен махсус поезд сатып алып, аның үләксәсен зур тантана белән Казанга кайтаралар һәм Казанга кайтарып аны шулай ук зур тантана белән күмәләр»: Qasimof Ƣ. Soltanƣəliefcelek həm anьŋ tamrlarь / Ƣ. Qasimof.– Qazan: Tatizdat, 1930.– B. 80.

[4] *Татар контрларыннан беренең «Зөләйха»сын кую өчен чаралар эзләп маташтылар* – «Зөләйха» – язучы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Г. Исхакый драмасы. Мәскәүдә үз наширлегендә 1918 елда бастырыла. Беренче мәртәбә «Сәйяр» труп-

ник торулары гына бу кара планга юл бирмәде. Якын арада куелып үткән «Янгура»да[1] татар контрларының йөзе ник ачылды (бу хакта минем дә бераз гөнаһым бар, тәфсыйле «Татарстан»дагы мәкаләмдә[2]).

Ләкин мәсьәлә, иптәшләр, моның белән тукталырга уйламый. Яңа сәясәт дип театрга, нәшрият шөгъбәсенә табыш кирәк, үзен-үзе яшәтергә кирәк, дигән бәһанә белән бу кара хәрәкәтне караңгы почмаклардан киң мәйданга чыгарырга хыяллану дәвам итә. Әдәбият, театр дөньясына кара сөрем капларга план төзелде. Кайбер язучылар үзләре дә сизмәстән, аңламастан буңа корал булалар. Ни язганнарына хисап бирмәстән, шул күтәрелеп килгән кара туфанга җиңелеп, һәртөрле динчелек, шовинистлык рухларын үз әсәрләрендә чыгаралар.

Уфадагы дини журнал, дини матбугат планнары, Галимҗан мулла үләксәсе белән демонстрацияләр, бөтен дини фанатизм белән агуланган «Зөләйха»ларны куйдырырга азапланулар, «Янгура»ны куйганда артистларның бу әсәрне бөтенләй кара фанатизм хәрәкәте төсе бирүләре – болар шул кара туфанның беренче дулкыннарыдыр.

Үзе ачыктан-ачык революция хәрәкәтенә катнашкан кайбер иптәшләрнең бу туфанны сизмәве, сизмәстән шуңа хезмәт итүе – бу тагы куркынычрак бер хәлдер.

Ишетелүенә күрә, Троицкиның бер язучы Сәлахетдин Әюби хакында, Чыңгыз, Мамайлар хакында байтак кына драмалар язган һәм яза икән[3]. Икенче бер казанлы иптәшебез Хәсән, Хөсәен (хәзрәте Гали балалары) хакында бер фаҗига эшли ди[4].

---

пасы тарафыннан Казанда зур театр сәхнәсендә 1917 елның 17 мартында ук куела.

[1] *Якын арада куелып үткән «Янгура»да* – «Янгура» – язучы Афзал Таһиров (1890–1937) драмасы. Беренче мәртәбә Казанда 1922 елның 28 гыйнварында сәхнәгә куела.

[2] *…тәфсыйле «Татарстан»дагы мәкаләмдә* – кара: Ибраһимов Г. Татар сәхнәсе («Янгура» уйналуы мөнәсәбәте белән) / Г. Ибраһимов // Татарстан хәб.– 1922.– 31 гыйнв.

[3] *…Троицкиның бер язучы Сәлахетдин Әюби хакында, Чыңгыз, Мамайлар хакында байтак кына драмалар язган һәм яза икән* – сүз драматург Әхмәт (Шаһиәхмәт) Таҗетдин улы Рахманкулов (1886–1942) һәм аның сәхнә әсәрләре хакында бара. «Чыңгызхан» дигән әсәре 1914 елда Истанбулда нәшер ителүе мәгълүм.

[4] *Икенче бер казанлы иптәшебез Хәсән, Хөсәен (хәзрәте Гали балалары) хакында бер фаҗига эшли ди* – сүз язучы, драматург Нәкый Исәнбәт (1899–1992) хакында барса кирәк.

Алдан әйтергә кирәк, бу әсәрләрнең һичберсен аерым алып контрреволюционный, фәлән дип әйтеп булмый, әгәр дә бер революционер каләменнән үтсә, һәртөрле Чыңгызлар, Әюбиләр, Мөхәммәтләр бөтен мәгънәсе белән тарихтагы сыйнфый икътисади революция хәрәкәтләрен ачып бирергә яраклык мәүзугълардыр. Ләкин, бердән, мондый нәрсәләр хакында язу планнары революционерлар тарафыннан түгел, бәлки иң азы битараф кешеләр каләменнән чыкканга, аннан да бигрәк, берсе Оренбургта, берсе Казанда, берсе Троицкида, берсе әллә кайда яткан язучыларның берсен-берсе белмәстән, күрмәстән берьюлы шундый мәүзугъларга тотынулары бу тормышның кайбер җирендәдер, ниндидер бер кара дулкын күтәрелүен, болар шуның җимеше генә икәнен күрсәтә торган галәмәтләрдер (симптом) . Икенче сүз белән әйткәндә, каядыр, нинди каберстандадыр әллә кайчан дөмеккән Әбуҗәһелләр[1], Ишмиләр[2], Пуришкевичләр[3] баш күтәрергә итәләр, үзләренең таралган өммәтләрен җыеп, шул иске фанатизмны яңадан терелтергә, шуның белән эшче-крәстиәннең йөрәген агуларга үзләренең ләхетләрендә план коралар. Кайбер йомшак иптәшләр, шул кабер сөремнәренә җиңелеп, шул адәм балалары тарихында хәзер бөтен мәгънәсе белән реакционерлык, әбуҗәһеллек, ишмичелек ролендә булган һәртөрле динчелек, ишмичелек рухларына үз язуларында юл бирәләр.

Ләкин аңларга кирәк ки, ул заман өчен чыннан да иң бөек революционер булган Мөхәммәткә каршы иске потпәрәстлекне яклап чыккан Әбуҗәһел, шулай ук җәдит хәрәкәтенә каршы хиҗабны, иҗекне, кадимне яклап чыккан Ишми муллалар, буржуазный революциягә каршы иске феодальлекне яклап сугышкан Пуришкевичләр үз заманнары өчен ни дәрәҗәдә зарарлы контрлардан булса, тарихның да хәзерге дәвере өчен, бу дәвернең алдындагы хезмәтләре өчен дә мондый динчелек, милләтчелек хәрәкәтләре нәкъ шул хиҗабны, кадимне яклаучыларның, Алла берлегенә каршы барып, Лат[4], Гозза[5], Мәнат[6] кебек тә-

---

[1] *Әбуҗәһел* – Мөхәммәд пәйгамбәр дошманнарының берсе.

[2] *Ишми* – Ишмөхәммәт (Ишми ишан) Динмөхәммәтов (1842–1919), дин эшлеклесе, кадимчелек тарафдары; 1919 елда большевиклар тарафыннан атып үтерелә.

[3] *Пуришкевич* – Владимир Митрофанович Пуришкевич (1870–1920), рус сәясәт эшлеклесе, монархист, карагруһ.

[4] *Лат* – борынгы мәҗүси гарәпләрнең табына торган потларының берсе.

[5] *Гозза* – борынгы мәҗүси гарәпләрнең табына торган потларының берсе.

[6] *Мәнат* – борынгы мәҗүси гарәпләрнең табына торган потларының берсе.

реләрне-потларны бетермәү өчен көрәшүчеләрнең һәм дә буржуага каршы феодальне яшәтергә тырышучыларның хәрәкәтләре белән бердер.

Ул Садри Максудилар, Фуатлар, Исхаковлар, ул Милюков, Гучковлар[1], ул Галимҗан Барудилар, Батталлар – болар һәммәсе шул хәзерге дәвернең Ишмиләре, Әбуҗәһелләре, Пуришкевичләредер.

Һәртөрле динчелек, шовинистлык рухын каберстаннардан киң дөньяга чыгарырга азапланулар – һәммәсе безгә Ислам кирәкми, без Лат белән Гоззага, Мәнатка табынабыз, җәдит хәрам, яшәсен хиҗаб белән иҗек, безгә хөррият кирәкми, иске феодализм калсын, дип йөрү белән бердер. Чөнки, заманнар үткән саен, тормышның кирәкләре алмаша бара. Бер заманда революционерлык булган хәрәкәт икенче вакытта, тормышның тагы да яңарак кирәкләре тугач, контрлыкка әйләнә.

Бу хакта мин икенче бервакыт тәфсилләп тукталырга уйлыйм. Хәзергә шуның белән сүземне бетерәм. Яңа икътисади сәясәт дип һәртөрле каберстаннардан Әбуҗәһелләрнең, Пуришкевичләрнең рухын тергезеп чыгаруга юл бирелмәсен! Һәрвакыт, һәркайда, һәрбер халыкта бөтен хәрәкәтләрнең, яңалыкларның алдында искелеккә каршы көрәшкән яшь буын бу турыда үзенең вазифасын үтәсен!

Галимҗан Ибраһимов,
гыйнвар, 28

[1] *Гучков* – Александр Иванович Гучков (1862–1936), зур капитал иясе, Октябристлар фиркасен нигезләүче һәм лидеры.

## Газыйм Касыймовка, Давыт Юлтыйга[1]

2 август [1922] ел

Газыйм, Давыт[2]!

Хатыңны алдым. «Рахил» һаман миңа тапшырылмаган әле[3]. Шуңа күрә ул хакта бернәрсә дә әйтә алмыйм. «Урал»ны укый

---

[1] Төп нөсхә Уфада академик Гайса Батыргәрәй улы Хөсәеновның шәхси архивында саклана. Штемпельдән күренгәнчә, хат әүвәл БАССРның Фәнни (хәзерге Башкортстан Республикасының Зәки Вәлиди исемендәге Үзәк республика) китапханәсендә 1930 елда теркәлгән. Шунда ук кулдан гарәп хәрефләрендә «Г. Ибраһимовның кульязмасы» дип язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче (б. 99–100), аннан соң башкорт теленә тәрҗемә ителеп «Ағиҙел» журналының 1962 елгы 5 нче (б. 77–79), «Социалистик Татарстан» газетасының 1962 елгы 14 март саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 110–112) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Хатта язылу елы күрсәтелмәгән. Ләкин төп нөсхәгә китапханәнең шул еллардагы хезмәткәре Гает Әхмәров шулай язып куйган: «Язучының үзе тарафыннан кайсы елда язылганы куелмаган булса да, сүзләрнең килеше уңгае белән 1921 нче [елда] язылган булуы хакланды. Г. Ә.». Әмма әдипнең «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» дигән китабының басылуы хакында үзе әйткән хәбәренә күрә, хат 1922 елда язылган булырга тиеш.

Хат белән бергә, Г. Әхмәров язган булса кирәк, шундый эчтәлектә икенче язма да бар: «Татар, башкортларның атаклы язучыларыннан Галимҗан Ибраһимовның кульязмасы. 1921 нче елның август числасында кайбер иптәшләренә язган хаты. Хат ул вакытның сәяси хәяты турында язылганлыктан хосусый булудан бигрәк гомуми дияргә ярый. Шуның белән бергә сәяси әһәмияттән дә хали түгел».

[2] *Давыт* – Давыт Исхак улы Юлтый (Юлтыев) (1893–1938), башкорт язучысы, җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *«Рахил» һаман миңа тапшырылмаган әле* – С. Сүнчәләйнең «Рахил күз яше» (1920) исемле тәрҗемә пьесасы. Ул рус язучысы Н. А. Крашенинниковның (1878–1941) «Плач Рахили» (1910) дигән драмасыннан тәрҗемә иткән: Крашенинников Н. Плач Рахили. Тысячелетняя сказка / Н. Крашенинников // Друкарь. Литературный сборник под редакцией Н. Д. Телешова.– М.: Изд-е Вспомогательной кассы типографистов, 1910.– С. 133–162. Әмма тәрҗемә әсәр нәшер ителмәгән, аның кульязмасы хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музееның С. Сүнчәләй фондында саклана (№ 17520).

киләм[1]. Теге Уфа белән Эстәрле талашы[2], чыннан да, бик күңелсез бер талаш булып алды. Еллар буенча партия сафында торып та, әллә нинди блок-фәлән дигән ахмак сүзләрне сөйләүчеләр булуына ни дияргә дә белмим. Коммунист – коммунист инде ул, партия һәм революция ни боерса, шуны эшли. Ниндидер тагы блок хакында сүз сөйләүчеләр чыннан да мәҗнүнлек сатканнар.

Һәркайда алты татар коммунистының, җиде группага бүленгән булып, үзара юкка талаш чыгарып йөрүе бик артык туйдырган инде. Сезнең анда тагы, бер яктан, башкортчы, икенче яктан, татарчы, өченче яктан татар-башкортчы булып талашып, революция алдында торган гомуми хезмәткә зарар китерәчәк булса, һәм партия, һәм пролетариат алдында җинаять ясаган булачагымыз мәгълүм. Безнең Казанда, Мәскәүдә дә мондый мәгънәсез талашлар бик җанга тиеп бетте. Уфа Башкортстанга кергән икән, ул җөмһүрияттә башкорт гаммәсе төп нигез икән, партия һәм революция юлын шулай дип таныган икән, бик-бик табигый ки, башкортлык мәсьәләсе анда һәммә турыда нигез ташы булып салыначак. Казанда саф интернационалист рус бер груһ коммунистлар һәммә эшкә татар гаммәсе күзлегеннән карап эшли башладылар. Уфада шул урынны башкорт алуы бик табигый. Менә бу мәсьәлә яхшы аңлашылса, татар белән ике арада талашка да, ышанмауга да юл калмас.

Бөтен дөньяны берләштерергә теләгән без – бәйнәлмиләлчеләр татар дип, башкорт дип, кабилә талашлары чыгарып баш катырсак, бу тарихи каралык булыр иде. Буржуазный идеологиянең баш күтәрүенә каршы революционный марксизм шигаре астында саф берләштерү – менә мин шул дип уйлыйм хәзерге задачаларның берсен.

---

[1] *«Урал»* – РКП(б)ның Уфа губерна комитетының басма органы буларак 1921–1922 елларда Уфада татар телендә чыккан газета. Шул вакытларда аның мөхәррире Г. Касыймов була.

[2] *Теге Уфа белән Эстәрле талашы…* – сүз 1922 елның августына кадәр Уфада эшләгән татар хезмәткәрләре белән Кече Башкортстанның башкаласы Стәрлетамакта эшләгән башкорт хезмәткәрләре арасында Уфа губернасының Зур Башкортстанга керү-кермәү мәсьәләсендә булып үткән бәхәс һәм талашлар хакында бара.

Башкортстан партия оешмасының 1922 ел, 16–20 сентябрендә булган Алтынчы конференциясе әлеге бәхәсләрне туктату турында карар кабул итә. Г. Ибраһимов Зур Башкортстан төзелүне яклап мәкалә бастыра: Ибраһимов Г. Зур Башкортстан мәсьәләсе / Г. Ибраһимов // Татарстан хәб.– 1922.– 25 гыйнв.

Г. З[1]. мәсьәләләрен аз-маз ишеткән идем. Бунлар турында берни дә язып тормыйм, чөнки бу һәркемнең үзенең эчке, бик эчке дөньясы булганга, читтән әйтелгән сүзләрдә һәрдаим бер хаталык буладыр.

Үзем хәзергә Казанда, ярым хәл җыеп, ярым Насыйри мәҗмугасын[2] ашыктырып ятам. Авылга кайтып килергә ниятем зур. Шунда күрешербез.

Казандагы хәлләрне ул сөйләр[3].

Иптәшләрнең һәрбарчасына – Хөснигә[4], Зәйнәпкә[5], Шәрифкә[6], Мәҗит агайга һәм башкаларга күптән-күп сәлам.

Галимҗан, Казан – август 2.

«Татар студентлары» дигән кечек бернәрсәмне басканнар[7]. Әле төпләнмәгән. Өлгергәч йибәрермен.

Казаннан төрле юк-бар сүз күп бара булыр, әһәмият бирмәгез. Кайбер иптәшләр алама хатыннардан да аламарак булып, башларындагы хыялларын, гайбәтләрне сөйләп йөриләр бугай. Бунларга кухня гайбәте дип карау лязем.

---

[1] *Г. З.* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[2] *Насыйри мәҗмугасын…* – сүз шушы мәҗмуга хакында бара: Каюм Насыйри мәҗмугасы. Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. Редакторы: Һәйят.– Казан: Т.С.С.Җ. дәүләт нәшрияты, 1922.– 160 б.

[3] *Казандагы хәбәрләрне ул сөйләр* – «ул»ның кем булуы хакында әлегә мәгълүматыбыз юк. Бәлки, хатны алып барган кешедер.

[4] *Хөснигә* – сүз Хөсни Кәрим турында бара. Хат язылган вакытларда, ягъни 1919–1924 елларда ул халык мәгарифенең Уфа шәһәр бүлегендә мөселман әдәбияты секциясе мөдире булып эшләгән.

[5] *Зәйнәпкә* – сүз Х. Кәримнең хатыны Зәйнәп Кәримова турында бара.

[6] *Шәрифкә* – сүз Шәрифҗан Сүнчәләй турында бара. Хат язылган вакытта ул Уфада Гыйльми үзәк рәисе була.

[7] *«Татар студентлары» дигән кечек бернәрсәмне басканнар* – Ибраһимов Г. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә. Татарстан өлкә комитеты коммунист яшьләр союзы нәшере / Г. Ибраһимов.– Казан: «Татарстан» матбагасы, 1922.– 42 б.

## 1923
## Мәҗит Гафурига[1]

16 май [1923] ел

Мәҗит агай,

Синең бәйрәмең булачагын ишетеп бик шатландым[2]. Син икенче дәвер татар әдәбиятының бүген исән булган шагыйрьләренең иң карты, иң күп эшләгәне һәм мәсләге буенча тарихның яңа әмәлләренә килеп ирешкәне булганга, пролетариат революциясе вакытында һәрбер эшче-крәстиән баласы синең юбилееңә чын күңелдән катнашачак.

Егерме еллык туктаусыз әдәби хезмәт – бу үзе генә дә бик зур бер бәхеттер. Ләкин синең бәхетең – халыкка хезмәт юлында чиккән газапларыңнан туган бәхетең. Бу хезмәтләреңнең эчке мәгънәсе, мөндәриҗәсе белән тагы да тирәнә[я], тарихи кыйммәт ала.

Син, хәзерге әдәбиятыбызның олыгайган буыннарының башкалары кебек, кадим, дин, схоластика эчендә тудың, яшь гомереңне шуның эчендә үткәрдең. Соңра мөтәрәккый[3] буржуазиянең милләтчелек, яңа динчелек баскычын үтеп чыктың. Каты реакция, империализм сугышлары синең фикер күзең алдында яңа дөньялар, яңа мәгънәләр ачты, шуңа күрә Февраль революциясен син зиһене, акылы, йөрәге милли буржуазия әмәлләре эчендә туңып каткан бәндәләр белән түгел, бәлки эшче-крәс-

[1] Төп нөсхә дәүләт фәнни бюджет учреждениесе «Татарстан Фәннәр академиясе» «Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган берәмлегенең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (12 ф., 2 тасв., 10 эш). Беренче мәртәбә «Башкортстан» (хәзерге «Кызыл таң») газетасының 1923 елгы 3 июнь, аннан соң «Совет әдәбияты» журналының 1963 елгы 1 нче саннарында (б. 110–111), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 113–114) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Синең бәйрәмең булачагын ишетеп бик шатландым* – 1923 елның 3 июнендә Уфада шагыйрь Мәҗит Гафуриның (1880–1934) 20 еллык иҗади хезмәт бәйрәме киң билгеләп үтелә. Котлау хаты шул уңай белән язылган.

[3] *Мөтәрәккый* – алга киткән.

тиән сафында каршы алдың, пролетариатның «Кызыл байрагы»н җырлап[1], сыйнфый сугышта безнең гаммә[2] ягында булдың.

Февраль вакытында «кызыл» күренгән, «революционер» күренгән күп бәндәләр, Октябрьнең, канлы гражданлык сугышларының, авыр террорларның рәхимсез көннәрендә, пролетариатны ташлап, капитал ягына чыктылар. Син бу хурлыкка төшмәдең, үзеңнең үсүеңдә дәвам иттең: үзеңнең йомшак күңелле булуыңа карамастан, канлы көрәш вакытларында һаман революция ягында калдың.

Татар әдәбияты тарихында син менә шул бер-бер артлы килгән фикри-әдәби-иҗтимагый зур үзгәрешләрдә башкалар кебек бер баскычка туктап калмадың, һаман үсә бардың, һаман алга бардың, шуңа күрә син, шәхси хәятыңның гадәттән тыш авырлыгына карамастан, үзеңне бәхетле санарга тиешлесең!

Феодализм хәрабәләре эчендә тәрбияләнеп тә, төрле баскычларны үтә-үтә, туктаусыз үсә-үсә коммунист пролетариат сафына килеп ирешү – актык көчне шул көчле полетариат белән бер сафта торып, инсаният[3] дөньясының олуг әмәлләре өчен сарыф кылу – бу һәркемгә насыйп була торган бәхет имәс[4].

20 еллык әдәби хезмәтең белән, бу хезмәтнең әнә шундый олуг әмәлгә юнәлгән булуы белән ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Галимҗан Ибраһимов.

Казан матбугатында мәкалә язачакмын[5]. Уфага башка нәрсә бирә алмадым. Газыймга[6], Мусага[7], Давытка[8], башкаларга сәлам сөйлә. Аларга әйт: минем бу мәктүбемне синең юбилей көнендә газетада чыгарсыннар.

Г. И.

Май – 16.

---

[1] *…пролетариатның «Кызыл байрагы»н җырлап* – сүз М. Гафуриның «Кызыл байрак» дигән шигыре хакында бара. Шигырь беренче мәртәбә социал-революционерларның Уфада Ф. Сәйфи-Казанлы наширлегендә һәм Г. Ибраһимов мөхәррирлегендә татар телендә нәшер ителгән «Ирек» газетасының 1917 елгы 21 апрель санында бастырылган. Ул аерым китап итеп тә нәшер ителгән: Гафури М. Кызыл байрак / М. Гафури.– Уфа: «Шәрык» матбагасы, 1917.– 42 б.

[2] *Гаммә* – масса.

[3] *Инсаният* – кешелек.

[4] *Имәс* – түгел.

[5] *Казан матбугатында мәкалә язачакмын* – Г. Ибраһимовның бу мәкаләсе Казан матбугатында нишләптер бастырылмаган.

[6] *Газим* – сүз Газыйм Касыймов хакында бара.

[7] *Муса* – сүз Муса Йосыпов хакында бара.

[8] *Давыт* – сүз Давыт Юлтый хакында бара.

## 1924
## Гражданке Тарасовой[1]

19 июля 1924 г.

Г[раждан]ке Тарасовой.

Как Вам известно, за дачу мною уплачено за весь сезон, и потому посылаю к Вам тов[арищ] Такташева: он будет жить в моей даче-квартире. От него, само собой разумеется, никакой платы не будете взыскать.

Галимджан Ибрагимов.

1924 г[од], 19/VII.

## 1925
## Мәҗит Гафурига[2]

16 май 1925 ел

Мәҗит агай,

Хатыңны алдым. Рәсемең дә тапшырылды. Ләкин үз каләмең белән язылган биографияң дә кирәк. Син бунның урынына китап йибәргәнсең. Иренмә: яңадан 2–3 бит язып йибәр. Аның язучыдан үз каләме белән булуы кирәк.

Казанда исәнлек.

Бик каты эшләү бара.

Хуш.

Галимҗан.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (124352–734). Татар теленә тәрҗемә ителеп беренче мәртәбә Һ. Такташ «Әсәрләр»енең 3 нче томында (Казан, 1983, б. 370), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 121) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Гыйльми үзәк рәисенең рәсми кәгазенә язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 100), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 121) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1925, сентябрь 1, Казан
## Татарстан нәшрият комбинатына[1]

1921 нче елда Мәҗит Гафури иптәшнең шигырьләр мәҗмугасы ул вакыттагы дәүләт нәшрияты тарафыннан алынып, басарга карар бирелгән иде. Мин берничә мәртәбә кузгатсам да, комбинат идарәсендә эшләүче иптәшләр: «Хәзергә төрле сәбәпләрдән болай мәҗмугаи асарьлар басарлык чама юк, бераз кичектерергә мәҗбүрбез»,– дия килделәр. Шулай кичегелә килде.

Озаклык сәбәбеннән 1921 нче ел договорының хокукы, әлбәттә, чыкты инде. Хәзер бу мәҗмуганы, шагыйрьгә биреп, басар өчен яңадан сөйләшергә кирәк, чөнки комбинат-нәшрият идарәсе шул күп вакыт эчендә үз хакыннан файдаланмады, шулай ук договор буенча шагыйрьнең әсәрләрен басып, дөньяга чыгара алмады.

«Татар әдәбияты көтепханәсе» сериясендә Мәҗит Гафури иптәш исеме бар. Анда аның әсәрләреннән 6–7 табагы керер. Буны аерым сөйләшергә кирәк. Гыйльми үзәк бунларны үз карамагында җыеп, аерып тапшырыр.

Гафури иптәш киткәнче Ленинградтан кайтып җитә алмавым ихтимал булганга, Гыйльми үзәкнең рәисе сыйфаты белән, бу мәҗмуга хакында шул фикеремне хәзердән әйтеп үтәм: мәҗмуга, әлбәттә, басылып чыгарга тиешле әсәрләрдән. М. Гафури иптәш бездә 1905 нче елдан туып реакция, сугыш, февраль аркылы пролетариат революциясе идеологиясенә килеп ирешкән бердәнбер

---

[1] Төп нөсхә дәүләт фәнни бюджет учреждениесе «Татарстан Фәннәр академиясе» «Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган берәмлегенең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (12 ф., 2 тасв., 7 эш). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 121–122) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Әмма бу җыентык басылмый кала. Аның титул битенә Г. Ибраһимов шулай язып куйган: «Шигырьләр. Мәҗит Гафури. Мәҗмугаи асәр. Шагыйрь Мәҗит Гафуриның бу мәҗмугасы 1921 елда Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты тарафыннан сатып алынган иде. Хәзер инде ул договорның көче-хокукы бетте. Чөнки үткән дүрт ел буенча дәүләт нәшрияты (һәм комбинат) баса алмадылар. Минем фикеремчә, шагыйрьнең әсәрләрен басып тарату турында комбинат (яки яңа төзеләчәк Татар[стан] дәүләт нәшрияты) яңадан сөйләшергә, яңа договор ясарга кирәк булыр. Г. Ибраһимов – 1925, сентябрь – 1, Казан.

Бу мәҗмуганы югарыда әйтелгән сәбәп буенча яңадан мөхәрриренә бирдем. Бу хакта комбинатка аерым кәгазь бирелде. – *Г. И.*».

шагыйремез булганга, аның әсәрләре классик матбугат җөмләсеннән булып басылачак нәрсәләрдәндер.

Гыйльми үзәк рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

## 1926
## Театр юбилеен уздыру комиссиясенә[1]

Татарстан Социал Шуралар Җөмһүрияте
Мәгариф халык комиссариатының
Гыйльми үзәк рәисе
–
ТССР
Народный комиссариат просвещения
Председатель
Академического центра
Служебная записка
23 января 1926 г.

Театр юбилеен уздыру комиссиясенә[2].

Гыйльми үзәк сотрудниклары өчен иң киме 30 билет җибәрегез. Билетның санын шуннан да киметергә һич мөмкин түгел.

Г. Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә (Гыйльми үзәк рәисенең рәсми кәгазенә кулдан гарәп хәрефләре белән язылган) Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана (119947–2). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Сайланма әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 128) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Театр юбилеен уздыру комиссиясенә* – 1926 елның гыйнвар аенда Казанда киң җәмәгатьчелек катнашлыгында татар театрының егерме еллыгы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. ТАССР Халык комиссарлары Советы карары белән ул академия театры дип атала башлый.

## Гәжур мөдире Сәлах Атнагуловка[1]

26 март 1926 ел

ТССҖ
Мәгариф халык комиссариатының
Гыйльми үзәге
–
Тат. Соц. Сов. Республика
Академическй центр
Народного Комиссариата
26 март 1926 г.

Гәжур[2] мөдире Сәлах Атнагуловка үтенеч.

Гыйльми үзәк әдәби көчләргә эшче-крәстиән районнарына мәгълүм вакытка әдәби максудлар өчен командировка бирү ысулын кулланырга карар бирде. Бунның өчен бераз матди ярдәм кыйлыначак. Беренче нәүбәттәгеләрдән берсе Һади Такташев шагыйрь билгеләнде. Ул апрельнең 15 еннән июль башына (2 ½ ай) кадәр йөриячәк. Гәжур идарәсенә үтенеч: шагыйрь Такташны шул эш вакытында тәгътыйльгә[3] җибәрсәгез иде. Аның урыны, әлбәттә, сакланырга тиешле.

Гыйльми үзәк рәисе: Галимҗан Ибраһимов (*имза*).

---

[1] Төп нөсхә (Гыйльми үзәкнең рәсми кәгазенә кулдан гарәп хәрефләре белән язылган) Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (119947, ДВХ-8/502). Документның өстә уңъягында гади карандаш белән кыйгачлап шулай язылган: «Һади Такташны 2 ½ га Гыйльми үзәккә командировать итеп торырга Гәжур каршы килми. Сәлах Атнагулов. 26. III. 1926)». Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Сайланма әсәрләр»енең 9 нчы томында (б. 128) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Гәжур* – 1925 елның 25 сентябрендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршында ачылган газета-журнал нәшрияты. 1925–1927 елларда Татарстанда барлык газета-журналларны әзерләп бастыру шушы нәшрият аша үтә. 1927 елның 7 мартында Татгиз составыннан К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты чыгарылып, Гәжур аңа кушыла һәм Татиздат дип атала башлый.

Һ. Такташ ул вакытта «Чаян» журналында эшли. Әлеге командировка буенча җәй аенда Пенза якларында йөреп кайта.

[3] *Тәгътыйль* – ял.

## Бакуда тюркология корылтаен чакыру өчен төзелгән Үзәк комиссиясенә[1]

1926 ел, Казан

Татарстан Халык мәгариф комиссариатының Гыйльми үзәге янында Казандагы гыйльми көчләрнең катнашы белән ясалган киңәшмә тюркология корылтаеның програмын караганнан соң, көн тәртибенә куелган мәсьәләләрне әсасән кабул итте. 7, 8 нче нәүбәткә куелган мәсьәләләрне, бердән башка мәсьәләләргә бәйләнеше ул дәрәҗәдә көчле булмаганга, икенчедән, каралачак әсаси мәсьәләләр озак вакыт телгәнгә, киңәшмә көн тәртибеннән алынуын матлуб таба[2].

11 нче нәүбәткә куелган «Төрек телләренең[3] ысулы тәдриси[4]» мәсьәләсенең ни рәвешле һәм нинди мөндәриҗәле булып куелуы хакында Үзәк комиссиядән тизлектә изах[5] бирүен сорый; ягъни монда төрек телләренең аерымлыгыннан килгән аерым методнымы яки тел сабакларының мөндәриҗатынмы аңларга?

Шуның белән бергә Үзәк комиссия корылтайның көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләрнең дә арттырылуын үтенә:

1) Төрек телләренең нәхүе төзелеше.

2) Әдәби төрек телләре һәм алардагы әдәбиятның үсүе (урыннардан доклад).

3) Цифрлар һәм фәнни формулалар.

Ниһаять, киңәшмә корылтайга бөтен төрек халыкларының тигез катнашуы кирәклеген игътибарга алып чуаш һәм уйгыр өлкәләреннән дә тюркология корылтаена тавыш бирү хакы белән берәр вәкил чакырылуын Үзәк комиссиядән сорый.

Татарстан булышлык комитетының рәисе: Галимҗан Ибраһимов

Секретаре: Гыйбад Алпаров

---

[1] «Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре / Төзүчесе Гали Рәхим» дигән җыентыкта (Казан, 1926, б. 21–22) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] 7 нче маддә «Төрек халыкларының башлангыч дини карашлары», 8 нче маддә «Төрек халыкларының башлангыч тарихы».

[3] *Төрек телләренең* – төрки телләрнең.

[4] *Ысулы тәдриси* – укыту ысулы.

[5] *Изах* – аңлатма.

Комитет беренче утырышыннан соң ук корылтай турындагы хәбәрнең соң алынуын, куелган мәсьәләләрнең зурлыгы, аларга хәзерлек күрү өчен озак вакыт кирәклеген һәм башка кайбер мәсьәләләрне күз алдында тотып, Бакудагы Үзәк оештыру комиссиясеннән корылтайның гыйнварга кичектерелүен сорап телеграм биргән иде. Шуңар җавап буларак Гыйльми үзәккә Бакудан түбәндәге телеграм алынды:

«Казан, Галимҗан Ибраһимовка. Сезнең соравыгыз буенча корылтайны ачу вакыты катгый рәвештә декабрьнең 30 ына билгеләнде, (димәк) гыйнвар диярлек. Агамәгале угылы»[1].

---

[1] *Агамәгале угылы* – Агамәгале угылы Самәд Ага (1897–1930), дәүләт эшлеклесе. 1922–1929 елларда Әзәрбәйҗан ССРы Үзәк Башкарма Комитеты рәисе.

## Хади Такташу[1]

25 августа 1926 г.

Т[оварищ] Такташ А.

Согласно постановления Президиума Акадцентра ТНКПса от 24 августа с/г § 4 Вам предлагается представить в недельный срок со дня получения настоящего извещения отчет о Вашей поездке в рабоче-крестьянские районы по командировке Акадцентра.

Председатель Акадцентра (*подпись Г. Ибрагимова*)
За ученого Секретаря (*подпись неразборчива*)

---

[1] Төп нөсхә (Академүзәкнең рәсми кәгазенә кулдан язылган (чыгу № 13418) Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (124352–735). Татар теленә төгәлсезлекләр белән тәрҗемә ителеп беренче мәртәбә Һ. Такташ «Әсәрләр»енең 3 нче томында (Казан, 1983, б. 370–371), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 121) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

## В Главполитпросвет Башнаркомпроса[1]

10 сентября 1926 г.

Как Вам известно, журнал «Безнен-Юл», издаваемый в Казани как орган Татнаркомпроса, в настоящее время является единственным литературно-художественным и научно-общественным журналом на татарском языке по всему Союзу ССР.

В декабре прошлого года на совещании при Отделе ЦК ВКП(б) было принято особое постановление об оставлении этого журнала, как журнала всесоюзного значения для татарского литературного мира. В связи с этим постановлением журнал «Безнен-Юл» существенно изменил свой характер, как в смысле улучшения своего художественного облика, так и в смысле привлечения все больше и больше литературных сил. В журнале «Безнен-Юл» участвуют не только Казанские писатели (и вообще писатели Татреспублики), но и писатели из других восточных республик и областей. В области литературных форм и техники журнал «Безнен-Юл» за время своего пятилетнего существования являлся тем зеркалом, которое отражало все литературные течения, имеющиеся в татлитературе.

Но несмотря на все вышеизложенные, в области распространения этого журнала мы имеем неудовлетворительный успех. Причины этого неудовлетворительного успеха главным образом является то, что соответствующие культурно-просветительные учреждения недостаточно обращают внимания на подписку этого журнала как для самих, так и для своих подведомственных культурно-просветительных единиц (библиотеки, клубы, избачи, красные уголки, школы и т.п.).

Принимая во внимание близость начала нового хозяйственного года, редакция «Безнен-Юл» обращается Вам с просьбой об включении журнала «Безнен-Юл» в списках тех изданий, которое Вами будет выписываться с начала этого хозяйственного года для Ваших подведомственных культурно-просветительных единиц.

Ответ[ственный] редактор журнала «Безнен-Юл»

(Г. Ибрагимов) (*подпись разборчива*)Ответ[ственный] секретарь (*подпись Г. Галиева разборчива*)

[1] Төп нөсхә (Татарстан Мәгариф халык комиссариатының штампасы сугылган кәгазьдә машинкада басылган (чыгу № 545) Башкортстан Республикасының Милли архивында саклана (Р-798 ф., 1 тасв., 1792 эш, 12 кәг.). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Сайланма әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (б. 313). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Габдулла Гыйсмәтигә[1]

10 сентябрь 1926 ел

Габдулла Гыйсмәти иптәш!

Казанда чыга торган «Безнең юл» журналы партия Үзәк Комитетының матбугат бүлеге тарафыннан бөтен СССР татарлары өчен уртак әдәби-гыйльми журнал ителеп танылгандыр. Шулай булса да, Башкортстан эчендәге татарлар арасында моңарчы бик аз таралды. Сездәге татар көтепханәләре, татар мәктәпләре буны ала алмыйлар. Яңа хуҗалык елы[2] керү уңае белән Сез бу хакта чара күреп, журналның таралуы, ягъни Наркомпрос буенча үз учреждениеләрегезгә таралуы, абунә язылуы хакында берәр нәрсә эшләсәгез иде. Юкса, андагы татарлар мәхрүм калалар. Журнал да уңайсыз бара.

Казанда исәнлек. Бер көе эшләп ятабыз. Үзең ник бер дә Казанга килеп чыкмыйсың? Иптәшләргә сәлам.

Хөрмәт белән: Галимҗан Ибраһимов (*имза*)

---

[1] Төп нөсхә (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында Гыйльми үзәкнең рәсми кәгазенә гарәп хәрефләрендә кызыл кара белән кулдан язылган) Башкортстан Республикасының Милли архивында саклана (Р-798 ф., 1 тасв., 1792 эш, 11 кәг.). Өстә сул якта кулдан шундый язма бар: «С нашей стороны – объявим в нашем «Белем»е. Имза (*танылмый*)»; уң якта – «Статья помещена в 9-м № журнала «Белем». Имза (танылмый)». Язмалардан күренгәнчә, адресат хатны 1926 елның 21 сентябрендә алган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1967 елгы 3 нче санында (б. 143–144), аннан соң Г. Ибраһимов «Сайланма әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (б. 130). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Яңа хуҗалык елы* – ул вакытта яңа хуҗалык елы 1 октябрьдән башланган.

## 1927
## Гомәр Толымбайскийга[1]

4 декабрь 1927 ел

Үткән кыш Казанда чагымда кайбер иптәшләр 20 еллык мәсьәләсен күтәрергә чамалаганнар иде. Болар арасында Гомәр Галиев тә бар иде. Мин кискен рәвештә каршы тордым. Һичбер төрле риза булмаячагымны белдердем. Чөнки егерме елны юбилей өчен аз дип уйлый идем. Тарихның, сәяси дөньяның шундый зур вакыйгалар белән кайнаган чагында революционер өчен, коммунис[т] – активис[т] өчен андый бер үз мәсьәләң белән халыкны мәшгуль итәргә һичбер төрле ярамый дип карый идем.

Бу елның октябрь аенда мин, 20 еллыкны котлап, байтак телеграмнар алдым. «Кызыл Татарстан» гәзитәсеннән Сәгъдинең мәкаләсе[2] басылган хәбәрне миңа кисеп җибәрделәр. Ләкин бу котлауларга мин бер хәтергә алу, авыруның күңеле юансын дигәннән иптәшләрчә бер эш дип караган идем. Синең, башкаларның хатлары һәм Сәгыйдуллин иптәшнең мәкаләсе[3] бу мәсьәләне яңадан инде бәйрәмләү рәвешендә күтәрелү ихтималы барлыгын күрсәтте.

Боларның һәммәсе, чынын әйтим, мине бераз аптырауда калдырды.

Скромность күрсәтә дип, әлбәттә, уйламаслар иптәшләр, төп асылда мин әле хәзер дә бу мәсьәләгә карашымда былтыргы – Казандагы фикердәмен.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 4 декабрь, кыскартып «Безнең юл» журналының 1927 елгы 12 нче санында, Г. Ибраһимовның «Әдәбият мәсьәләләре» (Казан, 1960) исемле мәкаләләр җыентыгында, шактый төгәлсезлекләр белән Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (б. 133–137) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] *Сәгъдинең мәкаләсе* – Сәгъди Г. Зур әдипләребездән берсе (Аның 20 еллык хезмәте уңае белән) / Г. Сәгъди // Кызыл Татарстан.– 1927.– 25 окт. Алга таба аның тагын бер мәкаләсе дөнья күрә: Сәгъди Г. Егерме еллык әдәби хезмәтенең беренче адымында (Бөек әдип Галимҗан Ибраһимовның егерме еллык юбилейсен ясау мәсьәләсе кузгалу уңае белән) / Г. Сәгъди // Кызыл Татарстан.– 1927.– 20 нояб.

[3] *Сәгыйдуллин иптәшнең мәкаләсе* – Сәгыйдуллин М. Галимҗан иптәш Ибраһимовның егерме еллык иҗат эшчәнлеге уңае белән (Мәсьәләнең куелышы) / М. Сәгыйдуллин // Кызыл Татарстан.– 1927.– 15 нояб.

...Хәлем, сәламәтлегем шул бер көенчә бара. Үзем һаман бик азлап, тамчылап кына ныгыйм кебек. Элекке докторым[1] Ленинградка командировка алып китте. Аның тапшыруы буенча миңа хәзер Герцман дигән икенче доктор йөри. Моңарчы климат белән дәвалану иде. Дарулау тик ярдәмче иде. Якын арада үземне рентгенга алып баралар. Шуннан соң, бәлки, пневмоторакс – үпкәгә газ уздыру ысулын башлау мәсьәләсен куймакчылар. Бу – зур техниканлы, моңар бераз сабыр итәргә, тагын ныграк тазаруны көтәргә лязем булыр, дип уйлыйлар.

Дәвалану мәсьәләсе болай тора: Кырым миңа акрынлап файда итә. Докторлар әйткәнчә, миңа озак вакыт шул климат эчендә дәвам итү кирәк. Миңа хәзер Татарстан хөкүмәте айлык жалуния бирә. Аның өстенә, теге вакыттагы карарынча, дәваланырга дип тагын акча җибәрә. Боларның бик чуалган чаклары, ничә айлар буенча җәй көне килми торган, рәтсезләнгән заманнары булды. Әле дә һәр ай өчен хатлар, телеграмнар җибәрергә мәҗбүр булган вакытлар юк түгел. Ләкин шулай да октябрь, ноябрь айлары шул бер билгеле югаргы нормага керделәр кебек күренә. Әгәр шул айларда җибәрелгән акча алда да һәр айга үз вакытында өзлексез килеп торса, минем Кырымда дәвалануым тәэмин кылынган була. Миңа шул җитә. Тик моның, төрле ихтималлардан саклануы өчен, терелгәнчә, һәр ай шул нормада җибәрелер дигән кебек бер рәсми канун астына керүе кирәк. Аннан соң финаппаратның саботаж яки гафләт ясамыйча, миннән хат, телеграм көтмичә, вакытында җибәрә торуы тәэмин кылынса, шуның белән минем дәвалануның беренче баскычы юлга салынган була.

Кырым климаты миңа файда итә. Ныгыйм азрак, аякка басам. Ләкин минем авыру гади түгел, минем уң үпкәмдә тавык йомыркасы зурлыгында каверна (тишек) бар. Сул үпкәм бөтенләй сәламәт. Ләкин уңнан буңа да чир күчү куркынычы һәрвакыт бар. Шуңа күрә бозык үпкәне техника ярдәме белән кысарга – бара торган процессын бетерергә кирәк. Моны Ялтада эшләп азапла给алар. Докторлар үзләре бик мактаналар да. Минем яңа докторым ниятләп тә тора. Ләкин үзләре, бу методны кулланмаучы докторлар, ачыктан-ачык әйтәләр: бу техника, үпкәне өрдереп, газлап кысу техникасы һәм, гомумән, каты процесслар белән көрәшү методлары Германиядә гаҗәп югары куелган, диләр. Бездә аның обстановкасы да, өйрәнүе дә, даруы, техникасы да җитми, диләр.

[1] *Элекке докторым* – сүз доктор А. В. Дьяконов хакында бара.

Авыруның психологиясе шундый ки, ул дөньяның читендә маһир бер доктор бар дип белсә, шуңа өстерәлеп китәргә әзер тора. Германиягә китү – миндә дә шулай. Бу минем авыруга көрәштә актык чарам!!

Мәсьәлә, минемчә, түбәндәгечә куелса, китап базары һәм укучылар дөньясы һәм әдәбият тарихы өчен дә, бәлки, уңай һәм файдалы булыр иде:

Бер язучының, бер шагыйрьнең аерым әсәрен яки берничәсен бер китап итеп бастыру бездә ике сериягә оешты. Беренчесе – «Татар әдәбияты көтепханәсе»[1], икенчесе – «Хәзерге әдәбияттан». Болар үз урынында ярыйлар, кирәкләр, файдалылар. Ләкин без бит үсә барабыз. Укучы да, мәктәп тә, көтепханә дә, әдәбият та үсә бара. Шуңа карап без дә, әдәбиятны басу-тарату формалары да үсәргә тиеш түгелме? Без, шөбһәсез, хәзер аерым язучының аерым әсәрләрен басу белән канәгатьләнү баскычыннан үттек. Бездә хәзер әсәрләрнең тулы җыелмасы (мәҗмугаи әсәр) ысулына күчәргә вакыт. Матур әдәбият моңарчы басылу-таралу формасында кустарьлык белән барды. Хәлбуки, ул рәвештә укучыга да, көтепханәгә дә, мәктәпкә дә тулы бер азык, тулы бер материал бирә алмый.

Урыста хәзер кемнәрнең генә «Тулы җыелма»ларын бирмәделәр. «Гиз»[2], «Зеф»[3] һәм башкалар, ничаклы нәрсә чыгарып, «Җыелма»лар ташлый торалар. Базар шуларны йота тора. Бездә революциягәчә бу эш башланган иде[4]. Хәзер совет нигезендә күтәреп чыгару ляземдер. Моның белән әдәби нәшрият кустарьлыктан котылыр. Әгәр укучының, мәктәпнең, көтепханәнең интересын уятырлык итеп тәртип кылынса, «Тулы җыелма»лар бездә, шөбһәсез, таралырлар, файда китерерләр, әмма әдәбият укыту материалларын бөтенләй баетырлар иде.

Югаргы сөалеңә мин әнә шул нигездән чыгып җавап бирәм.

Дөньяның киң форсатлы мөхәррирләре – зурлары, кечекләре – үзләре, эшләү характерлары турында күп-күп язганнар. Язалар. Мин бу хакта моңарчы да яза алмадым. Әле дә авы-

---

[1] *«Татар әдәбияты көтепханәсе»* – бу серия 1925 елда Г. Ибраһимов Гыйльми үзәк рәисе булып эшләгәндә аның инициативасы белән башлана.

[2] *«Гиз»* – «Государственное издательство».

[3] *«Зеф»* – «Земля и фабрика» (нәшрият).

[4] *Бездә революциягәчә бу эш башланган иде* – Г. Ибраһимов 1914 елда Г. Тукайның һәм Г. Исхакыйның 1911–1917 елларда нәшер ителгән «Мәҗмагуи асарь»ләрен күз алдында тотса кирәк.

рулыгымнан бербөтен нәрсә язарга хәлемнән килми. Без бит көрәш – иҗтимагый-әдәби көрәш эчендә гомерне үткәрдек. Шуңа күрә элек вакытыбыз булмады, хәзер авырып егылгач, инде вакыт күп, ләкин хәл юк, кулда, тәндә куәт юк.

Моңарчы минем турыда байтак-байтак яздылар. Рус, татар, башка төркиләрдә күп кенә нәрсә чыкты. Күбе үземдә барлар. Боларны сәламәт вакытта актаргалый идем. Җыенысыннан сыгып алганда, арада дөресрәк фикерләре, карашлары менә шуңа кайта иде:

Мин – реалис[т] мөхәррир. Беренче әсәрләремнән хәзергәчә шул әдәби мәсләктә бардым. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында). Ләкин боларда да төп мөндәриҗә – нигез реализм иде. Беренче әсәрләремнән хәзергәчә мөндәриҗәләрдә төп характерлар һаман-һаман көрәш вакыйгалары, халыкның хезмәт процесслары тирәсендә, шулар белән сугарылды. Хезмәт авылда, шәһәрдә төрлечә тасвирга алынган кебек, көрәш тә үзенең тәфсыйлен үзгәртте генә түгел, бәлки нык тирәнәйтте дә.

Беренче әсәр «Зәки шәкерт»тә яңа фикер иске реакциягә каршы көрәшсә, «Татар хатыны ниләр күрми»дә хатын коллыкка каршы көрәшсә, бара торгач, бу инде иҗтимагый каршылык, иҗтимагый көрәшләргә әйләнә.

Миңа бу турыда Киев хәрәкәте, Киев зинданы байтак тәэсир кылды. Аннан соңгы «Көтүчеләр»[1], «Мәрхүмнең дәфтәреннән»[2], 1914 нче елда язылып тәмам булган һәм үзгәртми басылган «Безнең көннәр» менә шуңа мисал булыр.

Революциягәчә мин ул заманның хәрәкәтенә оппозициядә бардым. Февраль дәвере буржуага каршы тел, каләм көрәше белән үтте. Анда яза алмадым. 1918 нче елның башыннан Петербургта (Ленинградта) Комиссариаттан башлап тагы – Октябрь һәм Совет өчен көрәш белән үтеп, әдәбиятка форсат тимәде.

[1] *«Көтүчеләр»* – беренче мәртәбә «Аң» журналының 1913 елгы 22 нче санында «Көтүче карт» (Басылмаган романнан бер фасыл)» исеме белән бастырыла (б. 380–387). Аннан соң 1920, 1922 елларда аерым китап итеп нәшер ителә: Ибраһимов Г. Көтүчеләр // Картлык көннәрендә.– Казань: Электро-тип. «Миллят», 1920.– Б. 4–23. Ибраһимов Г. Көтүчеләр / Г. Ибраһимов.– Казан: Татар Социал Шуралар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты матбугат-нәшрияты, 1922.– 23 б.

[2] *«Мәрхүмнең дәфтәреннән»* – беренче мәртәбә «Аң» журналының 1914 елгы 24 нче санында басыла (б. 428–430). Аннан соң 1920 елда аерым китап итеп нәшер ителә: Ибраһимов Г. Мәрхүмнең дәфтәреннән // Караңгы төннәрдә / Г. Ибраһимов.– Казань: 6-я Гос. тип., 1920.– Б. 2–6.

Бөтен үткән хәятем яшьтән каты эшләп, бөтен 10–15 ел уку һәм яшь язучы заманнарын ачлык, ялангач һәм көрәш белән үткәрүләр мине мәҗбүри рәвештә коммунис[т]-активис[т] булуга хәзерләп китерделәр. Минем марксис[т] әдип булуым пролетариат байрагы астында эшләвемне үземә тормышның, гомеремнең төп максуды итеп куеп, шул юлны алуым – бөтен үткән хәятемнең тарихи мәҗбүре нәтиҗәседер.

Әгәр гомер булып та, бу үткән хәятне бер киң рәвештә яза алсам иде, хәзерге яшьләр өчен үткән безнең буынның нинди кыен-мөшкел шартлар, киртәләр, көрәшләр соңында киңәеп, пролетариат байрагы астында көрәшергә, шунда эшләргә, каләмне, әдәбиятны шуңа корал итәргә насыйп булганнарын күрерләр иде.

Татар мәдәнияте ярлы чагында мәйданга чыкканга, бөтен көчне матур әдәбиятка гына бирә алмадык. Минем төп эшем әдәбият булса да, моңа янәшә тагын ике тармак барды: 1) лингвистика, филология, 2) рев[олюцион] хәрәкәт тарихы. Шулай итеп, каләм җимеше өч ботакта үсә барды.

Ләкин эшләгәннәрдән эшләнәчәкләрем, яртылай эшләнеп яки аклауны көтеп, дөньяга чыгуны көтеп ятканнарым – миннән гомер, сәламәтлек көтеп яталар. Ни булыр – боларга кайтып, яңадан каләмгә утырыр көн килерме, әллә кабер алырмы?

Хәзергә хуш.

## Һади Такташка[1]

4 февраль 1927 ел

Һади!

Менә бу язучыны бирүче иптәшләр – синең белән бергәләшеп Тәүфикъ Фикрәтнең[2] «Тарихы кадими» дигән әсәрен тәрҗемә итү турында сөйләшергә телиләр. Син алар белән сөйләш һәм аңлаш әле. Ул әсәрне татар әдәбиятына матур рәвештә кертәсе иде[3]. Татгиз һәр икегезгә дә гонорар вәгъдә итте, китап иптәшләргә бирелде.

Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә (Гыйльми үзәкнең рәсми кәгазенә кулдан язылган) Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (124352–736). Беренче мәртәбә Һ. Такташ «Әсәрләр»енең 3 нче томында (Казан, 1983, б. 371), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 131) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Тәүфикъ Фикрәт (1867–1915)* – төрек шагыйре, журналист.

[3] *Ул әсәрне татар әдәбиятына матур рәвештә кертәсе иде* – әсәр бастырылмаган.

## Башкортстан Гыйльми үзәгенә[1]

24 февраль 1927 ел

Татарстан Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге һәм Гыйльми үзәк янындагы «Татар педагогия җәмгыяте»[2] киләсе язга татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларының киңәшмәсен[3] чакыра. Киңәшмәнең көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләрне куярга уйлана:

1. Татар грамматикасы нигезләре һәм формаль грамматика агымы.

2. Икенче баскыч мәктәпләрдә татар теле һәм аның укыту методлары.

3. Урта мәктәпләрдә әдәбият, аның күләме һәм укыту методлары (икенче баскыч, техникум, гаскәри мәктәп кебекләрдә).

4. Беренче баскыч мәктәпләрдә комплекс системасында ана теле.

5. Беренче баскыч мәктәпләрдә әлифба өйрәтү методлары.

6. Татар әдәбиятын тикшерү эшләре.

7. Мәктәпкәчә тәрбия яшендәге учреждениеләрдә балаларның телләрен үстерү.

8. Икенче баскыч мәктәпләрдә халык әдәбиятын өйрәнү юллары.

Шуны сезгә хәбәр итү белән бергә, Татарстан Мәгариф комиссариаты һәм «Татар педагогия җәмгыяте» идарәсе сезне шул

---

[1] Төп нөсхә Башкортстан Республикасының Милли архивында саклана (Р-798 ф., 1 тасв., 1775 эш, 273 кәг.). Татарстан Мәгариф халык комиссарлыгының рәсми кәгазенә машинкада гарәп хәрефләрендә бастырылган. Өстә уң якта кулдан шулай язылган: «Ашыгыч рәвештә хәбәр итәргә: Көн тәртибенә куелган мәсьәләләргә өстәлмә ясамыйбыз. Йибәреләчәк вәкилләрнең расхутларын күтәрербез. Имза (танылмый)». Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Сайланма әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән (б. 314) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Татар педагогия җәмгыяте»* – Татар мәдәнияте йорты янында 1926 елның көзендә Казанда оештырыла.

[3] *Татар теле һәм татар әдәбияты укытучылары киңәшмәсе* – 1927 елның 15–22 июнь көннәрендә Казанда үткәрелә. Аның материаллары аерым җыентык итеп бастырыла: 1927 нче ел июньнең 15–22 нче көннәрендә Казанда Бөтенсоюз күләмендә беренче мәртәбә җыйналган төрек-татар тел һәм әдәбият укытучылары конференциясенең тулы хисабы.– Казан: татар мәдәнияте йортының басмасы, 1927.– 202 б.

киңәшмәне чакырышуга һәм чыгымнарын үз өстегезгә алып, киңәшмәгә вәкилләр җибәрергә чакыра. Киңәшмәнең кайсы числода чакырылуы турында хәбәр ителер.

Шуның белән бергә, югарыда күрсәтелгән көн тәртибенә үзегез кирәкле тапкан мәсьәләләрне өстәргә һәм үзегездән докладчылар да билгеләргә мөмкин.

Соралган мәсьәлә турында март 15 ләрендә хәбәр көтәбез.

Татарстан Мәгариф халык комиссары: *имза* (М. Таһиров)
Гыйльми үзәк рәисе: *имза* (Галимҗан Ибраһимов)
«Татар педагогия җәмгыяте» рәисе: *имза* (М. Корбангалиев)
Җәмгыятьнең гыйльми секретаре: *имза* (М. Сафин[1])

---

[1] *М. Сафин* – Мирсәет Закир улы Сафин (1897–1942), тел галиме; «Яңалиф» җәмгыятенең сәркятибе.

## Мөхәммәт Таһировка[1]

22 ноябрь 1927 ел

Мөхәммәт туган,

хатыңны алдым. Бераз аңлашылмауга охшаш хәлдә калдым. Ул 20 еллыкны былтыр ук кайбер иптәшләр кузгаткан иде. Мин аңа бөтенләй каршы идем. Быел көз тәбрик телеграмнарын алгач, иптәшләрчә бер сәламләп хәтерләү, авыруның күңелен җуату дип уйлаган идем. Соңгы көннәрдә килгән хәбәрләр, гәзитәдән кисеп җибәрелгән мәкаләләр буның хәзер юбилей төсенә керүе ихтималын күрсәтә. Мин 20 елны азда саный идем. Мондый көрәшләр кызган чорда коммунист өчен бер үз мәсьәләң белән халыкны мәшгуль итү ярамый дип тә карый идем. Әле дә шулай дим. Ләкин Сәгыйдуллин мәкаләсеннән күренгәнчә, анда инде машина әйләнергә торганы күренә. Казан хәлләрен яхшы белмәгәч, дөньядан хәбәрсез яшәгәч, ни дип әйтергә дә аптырабрак калдым. Үзегез тагын быелның декабреннән калдырмаска, дисез. Шул арада ике телдә мәҗмуга[2] чыгарырга, әсәрләрнең тулы җыелмасын[3] да басарга уйлыйсыз. Мин үзем, беләсең, берничә юбилейлар үткәрдем. Болар минем билемне бөкрәйттеләр. Сезнең комиссиягә кергән иптәшләр[4] һәммәсе

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (15 ф., 6 тасв., 6367 эш, 23, 23 (икенче ягы) кәг.). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (б. 137–138) шактый хаталар һәм төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *...ике телдә мәҗмуга...* – мәҗмуга бер телдә генә бастырылган: Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык) // Җыентык Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәти иптәшләрдән гыйбарәт комиссия редакциясендә чыга.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1928 ел.– 196 б.

[3] *...әсәрләрнең тулы җыелмасын…* – әдипнең 20 еллык әдәби иҗат юбилее уңае белән «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең җиде томын бастырып чыгару планлаштырыла. Әмма аларның 2, 5, 6 нчы томнары гына дөнья күрә:

Ƣalimcan İbrahimьf əsərləre.– Qazan: Jaŋalif, 1929.– tum II.– 470 b.

Ƣalimçan İbrahimof əsərləre.– Qazan: Jaŋalif, 1931.– tum V.– 198 b.

Ƣalimçan İbrahimof əsərləre.– Qazan: Jaŋalif, 1930.– tum VI.– 116 b.

[4] *Сезнең комиссиягә кергән иптәшләр* – Г. Ибраһимов юбилеен үткәрү Үзәк комиссиясе ВКП(б) Өлкә Комитеты секретариатының 1927 ел, 1 декабрь утырышында төзелә. Аның составына Н. Мөхетдинов (рәис), Г. Баһаветдинов, М. Таһиров, И. Рәхмәтуллин, М. Корбангалиев, Н. Фирсов, И. Бороздин, Г. Сәгъди, Г. Линсцер,

гадәттән тыш мәшгуль иптәшләр. Алар ничек җыелышка килеп озаклап утырыр да ничек материалларны карар? Ягъни декабрьгә ничек өлгерерсез сез? Ашык-пошык эшләп, әллә ничаклы хаталар, гафләтләр, мөсаһәләләр[1] китү, тиешенчә оештырып җитә алмау, ни апара, ни камыр булу ихтималы бик-бик якын түгелме? Тарихи мәсьүлиятле бер эшне башлап та, бик зәгыйфь бернәрсә алдында калуыгыз ихтимал түгелме? Хәзерлекнең, вакытның азлыгы, иптәшләрнең бик мәшгульлеге теге югарыгы сәбәпләр өстенә минем сәлби[2] карашыма болар да кушылалар түгелме? Ничек тә эш бик мәсьүлиятле. Ничек очлап, тиз арада оештырып чыгарсыз, шуңа тәнкыйтьле күз белән карыйм.

Бу хакта иптәшләргә, аеруча сиңа нык уйлап карарга кирәк. Минем тәнкыйди карашымны әйтеп, Сәгыйдуллин белән дә, Сәйфи Фатих белән дә сөйләшеп үт әле.

Бәлки, тагын язарым, чөнки үземнең мондагы хәлләрем турында язарга хәзер арыдым. Кайбер мәсьәләләр турында, Тулбайның соравынча[3], берничә җавап яздым. Син шуны алып карасаң ярар иде. Ул хатлар җибәрелгән инде. Сиңа җавап та әле кайта яза торырга хәлем җитми, арыдым.

Хуш.

Иптәшләргә сәлам әйт.

Дустлык белән Галимҗан.

Ялта, ноябрь 22–1927.

Ахырдан:

---

Н. Векслин, К. Мәһди, Ш. Камал, Ф. Сәйфи-Казанлы, С. Борһан, М. Фазлуллин, Ф. Бурнаш, Г. Толымбайский, М. Сәгыйдуллин, М. Давыдов, Ф. Хәсәнов, Г. Галиев (сәркятип).

1927 елның 5 декабрендә бу мәсьәлә тагын карала: «Заседание секретариата Областного Комитета ВКП(б).

Слушали: О составе комиссии по проведению 20-летнего юбилея тов[арища] Ибрагимова Г. Предлагается комиссию сделать правительственной.

Постановили: Комиссию по проведению 20-летнего юбилея общественно-литературной деятельности тов. Ибрагимова Г. оставить при Народном Комиссариате Просвещения. Состав комиссии пополнить тов. Г. Нигмати (редактор газеты «Кызыл Татарстан».

[1] *Мөсаһәләләр* – игътибарсызлыклар.

[2] *Сәлби* – кире.

[3] *Тулбайның соравынча* – сүз язучы Г. Толымбай хакында бара; әдип биредә аңа 1927 елның 22 ноябрендә язган хатын искә ала булса кирәк.

Син Рифгатьнең библиографиясе турында[1] язгансың. Ялгышлык булмасын өчен, син Рифгать белән сөйләш әле. Ул аны Гөлсем белән икесенең исеменнән чыгарган буладыр бит. Чөнки Гөлсем, берничә ел эшләп, ул библиографияне әсасан җыеп, машинкада бастырып, син тагын арттыр, тутыр, икәү чыгарырбыз, дип, үткән ел Рифгатькә биреп киткән иде. Гөлсем бераз борчылып калды. Минем берничә ел түккән хезмәт югалмасын иде, дип. Ул шул библиография мәсьәләсе өчен Казанга кайтып килергә дә дәртләнеп китте.

Хуш. Г.

---

[1] *Рифгатьнең библиографиясе турында* – Рифгать Шакирҗан улы Таһиров (1903–1977), тарихчы, педагог. Мәскәү университеты каршындагы Рус библиография җәмгыяте әгъзасы (1927). Г. Мөхәммәдова белән берлектә Г. Ибраһимов әсәрләренең библиографиясен төзеп, әдипнең 20 еллык әдәби юбилее уңае белән нәшер ителгән җыентыкта (Казан, 1928) бастыралар.

## 1928
## Г. Ибраһимовның Ялтадан Мәҗит Гафурига язган хаты[1]

18 гыйнвар 1928 ел

Кадерле Мәҗит агай,

хатыңны алдым. Кичегебрәк булса да, искә төшерүең өчен рәхмәт. Дөнья шулайрак булып китте бит: мин көн-төн туктамыйча, аруның нәрсә икәнен белмичә, дәртләнеп эшләп йөргән чакта, кинәтрәк аяктан егылдым да, бөтен эшләремне ташлап, үлем белән көрәшү мәҗбүрияте астына калдым. Бу – минем өчен көтелмәгәнрәк хәл булды.

Бәлки, гәзитләрдә күргәнсеңдер, [19] 26 нчы елның сентябрендә, кич кабинетымда эшләп утырганда, бик аз җүтәл соңында күкрәгемнән кан китте (стакан ярым чамасы). Докторлар киңәшенчә, Кавказга – Сухумга киттем. Анда өч айга якын торып кайткач, Казанда яңадан әүвәлгечә иркенлек белән эшкә тотындым. Мәсьәләләр шулай тыгыз килде ки, миңа иртәдән сәгать 4 [кә] кадәрле Гыйльми үзәктә, совет аппаратында эшләү өстенә, ике ай ярым эчендә «Урал» һәм уралчылар» белән «Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак?» атлы ике зур мәсьүлиятле әсәр язып чыгарга туры килде.

Бәлки, шулар нәтиҗәседер, март 17 дә, көндез Татарстанның Советлар съездында утырган чакта тагын бераз гына җүтәл артыннан күкрәктән кан китте. Ике тәүлек эчендә өч мәртәбә күпләп килгән канның микъдары алты стаканнан артып китте. Нәтиҗәсендә үпкәне кан басудан аспирационная пневмония булып, минем хәл үлем чигенә килеп җитте. Эсселек 40 тан артып китте. Мин бөтен бер ай Казанның Иске университет клиникасында яттым[2]. Беренче көннән үк йөрү, сөйләшү бөтенләй

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында (б. 53–55), аннан соң рус телендә тәрҗемәсе «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче санында (с. 171–173), шактый кыскартылып, «Үлем җиңәрме, минме?» исеме белән «Кызыл таң» газетасының 1967 елгы 11 март санында, тулы килеш Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 139–142) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Мин бөтен бер ай Казанның Иске университет клиникасында яттым* – Г. Ибраһимов анда 1927 елның 21 мартыннан 21 апрельгә кадәр дәвалана. Клиникада аның медицина картасын ординатор (соңыннан медицина фәннәре кандидаты,

мөмкин булмады. Үлем куркынычы әүвәлге атналарда бөтенләй килеп баскан иде.

Докторларның гадәттән тыш зур әһәмият белән караулары-ның да бер тәэсире булгандыр, мин тәндә җан сүнмәгән хәлдә, апрель 21 дә Татнаркомздравның мине озатырга, юлдаш булырга дип биргән докторы[1] һәм үземнең гаиләм белән берлектә, Кы-рымга киттем[2]. Дөресте – мине күтәреп алып төшеп, поездга күтәреп кертеп, Кырымга алып киттеләр. Әлбәттә, куркыныч иде. Кырым шикелле ерак җиргә минем хәлемдә барып җитә алуның бик мөшкеллеге күз алдында иде, шулай булса да, Казан-да калу минем үпкәләрем өчен һичбер төрле ярамаганга, мин ике куркынычның өметкә якынрагын сайладым. Ни булса шул дип, Кырым сәфәренә тәвәккәл иттем. Монда килгәндә һәм килгәч, хәлем, рентгеннар аркылы карап, түбәндәге рәвештә табылды: өченче стадия туберкулез, уң үпкәдә ике каверна (тишек). Болар-ның берсе тавык йомыркасы зурлыгы, берсе кечерәк. Тәндә бер потка якын үлчәү җитми, ягъни тик сөяк белән тире калган. Үзем теләгәнчә сөйләшә алмыйм, караваттан кузгалырга һич төрле ярамый, бөтен эшем тик шунда үтәлә. Болар өстенә малярия белән колит бар, кыскача хәл менә шулай иде. Әгәр бервакыт мин терелеп, яңадан хәятка кайта алсам, эшкә тотына алсам, син уйларга тиеш булырсың: Галимҗанның организмысы үткән күпме җәфалы тормыш аркасында бик чыныккан икән, дип.

Ләкин хәзергә ачык бер әйбер әйтеп булмый әле: үлем җиңәр-ме, минме?

Менә ун ай инде Кырымда дәваланам. Килгәч, 3–4 айдан соң, караваттан кузгалып, верандага чыга башладым. Көзгә та-ба ишек алдындагы бакчага чыгып утырырлык хәл керде. Җир тетрәү вакытларында мин инде хатынымның култыклавы белән һәр селкенүдә тиз-тиз ашыгып, ләкин ахылдап, арып, тын кысы-лып, өйдән чыгаладыр идем инде. Бу миндә байтак өмет арттыр-ган иде. Ләкин декабрь ае яңадан бик нык күңелсезлек китерде:

---

доцент) Александр Иванович Голиков (1900–1990 елдан соң) тутыра. Бу хакта ту-лырак кара: Исламов Р. Әдипнең медицина картасы табылды / Р. Исламов // Мәд. җомга.– 2011.– 25 февр.; Шул ук // Кызыл таң.– 2011.– 11 март.

[1] *…юлдаш булырга дип биргән докторы* – аның исеме мәгълүм түгел, бары тик яшь татар табибы булганлыгы гына билгеле – *Р. Ф.*

[2] *…Кырымга киттем* – аны кичекмәстән дәваланырга җибәрү мәсьәләсе белән профессор М. Чебоксаров Татарстан Халык комиссарлары Советы рәисе Х. Габи-дуллинга мөрәҗәгать итә.

декабрьнең берендә, төнлә яңадан кан килде. Күплеге Казандагы шикелле булмаса да, бу үзе 3 көн өзелү белән декабрь 21 енәчә дәвам итте. Мин тагы гыйнвар 15 енәчә бөтенләй караваттан тормыйча, теләгәнчә сөйләшә алмыйча, каты яттым. Менә тик 3–4 көн генә әле, тагын торып, бүлмәдә йөри башладым. Ләкин үземә бернәрсә укырга, язарга ярамый. Шуңа күрә бу мәктүбне үз кулым белән түгел, Гөлсемгә әйтеп яздырам. Гомумән, Кырымга килгән[нән] бирле бөтен хатлашуларны диярлек ул алып бара. Тик көзге айларда гына, бераз хәлләнгәч, үзем мәктүбләр яза башлаган идем.

Нинди дә булса бер әсәр, мәкалә язу кебек әйбер турында, әлбәттә, уйларга да ярамый.

Менә минем хәл шулай бара. Үлемгә каршы бу көрәш байтак дәвам итәр әле. Докторлар әйтәләр: озак вакыт тынычлык белән, тыныч күңел белән нык дәваланганда, шөбһәсез, яңадан тазарырга, һич булмаса, әдәби-гыйльми эшкә кайтырга мөмкин булачак, диләр. Үзем, менә шул өметләр белән юанып, үлемгә каршы озак, кискен көрәш алып барырга планнар корып ятам.

Һич булмаса, күңелемдә эшләнеп беткән, кайбере яртылай кәгазьгә төшкән яки аклауны гына көтеп яткан әсәрләремне бетерә алырлык куәт кайтсын иде, шул чаклы гына гомер миңа яңадан килсен иде. «Безнең көннәр»нең II нче, III нчеләре, «Тугры сүз» әдәби хикәясе, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре»нең Октябрь җилде һәм «Әдәбият кануннары» кебек гыйльми нәрсәләрем, ашыгып, мине үзләрен тизрәк эшләп бетерергә чакырып, папкаларда яталар бит. Әгәр кабер бик якын килгән булмаса, бер өмет бар, бәлки, шундый әйберләремне тәмам итәрлек куәт, гомер яңадан кайтыр әле. Әгәр кайтмаса, угылым Рөстәм тәмам итәр, бәлки, дип җуанудан башка чара калмый!

Син бик нык кеше булып чыктың. Әле һаман да күп эшләгәнең күренә. Әйдә, эшлә инде, эшлә. Безнең кебек фронтта җыгылганнар өчен дә эшлә!

Уфадагы иптәшләргә, барча каләм әһелләренә, әгәр анда булсалар, Газыйм белән Мусага һәм башкаларга сәлам сөйләрсең. Башкорт иптәшләрдән Кәрим Иделхуҗиннарга[1] аеруча сәлам.

---

[1] *Кәрим Иделхуҗин* – Кәрим Габдулла улы Иделхуҗин (1895–1937), башкорт милли хәрәкәте эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

Кырымның һавасы декабрьдә бик начар булган иде. Хәзер төзәлеп тора. Минем өчен бу мәсьәлә иң зур чараларның берсе инде. Һава яхшырса, минем дә кәеф яхшыра, төзәлә башлый.

20 еллык турында минем үз фикерем каршы иде. Үткән ел Казанда чагымда да, бу ел Ялтадан да бу мәсьәләне кузгатучы иптәшләргә кискен рәвештә сәлби җавап бирә килгән идем. Чөнки дөньяның шундый кайнаган чагында, иҗтимагый көрәшләрнең нык кызган заманнарында, хезмәт халкын үз мәсьәләң белән мәшгуль итү коммунист-активист өчен, әлбәттә, ярамый дип карый идем. Ләкин иптәшләр минем сүзне тыңламадылар. Татарстанның ВКП(б) өлкә Комитеты бу ел ноябрендә комиссия төзетеп, эшкә керешкәннәр. Мин: хәерле булсын, бөтен бу мәсьәләдәге мәсъүлият[1] сезнең үз өстегезгә йөкләнә диюдән башка, әлбәттә, бернәрсә дә кыла алмадым. Инде кала, терелгәч, халыкның бу дәртен канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә яңадан ныклап хезмәт итү.

Казанга кайчан кайта алуымны әйтеп булмый. Бу мәсьәлә бөтенләй минем авырып терелүемнең барышына баглыдыр. Хатыным Гөлсемнән һәм Рөстәмнән иптәшеңә һәм угылыңа сәлам.

Андагы хәлләрне белдереп, хат яз. Хәзергә хуш. Сәламәтләнеп, көрешү өмете һәм иптәшлек сәламе белән: Галимҗан.

1928 – гыйнвар 18 – Ялта.

[1] *Мәсъүлият* – җаваплылык.

## В Государственную Академию художественных наук[1]

20 февраля 1928 г.

Ваше извещение за № 108 от 25/I-1928 г. о моем избрании членом ГАХН получил.

Считаю своим долгом выразить глубочайшую благодарность перед Академией за оказанную мне честь.

В настоящее время (с апреля 1927 г[ода]) нахожусь в г[ороде] Ялте на климатическом лечении, имея туберкулез легких с кавернами.

Моя поездка в текущем академическом году для прочтения доклада в ГАХН целиком связана с ходом моего лечения и темпом моего выздоровления.

При первой же возможности почту своей обязанностью представить доклад лично.

Ответ мой на Ваше извещение запоздал по той причине, что я только на днях получил его через Татреспублику, куда оно было отправлено Вами.

С почтением: Галимджан Ибрагимов.
г[ород] Ялта, Барятнинская, 5.

[1] Төп нөсхә Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында (941 ф., 10 тасв., 25 эш), фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемәсе «Казан утлары» журналының 1977 елгы 3 нче санында, аннан соң «Татарстан» журналының 1997 елгы 3 нче санында (б. 28), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (б. 142) бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә китерелә.

## Мөхәммәт Таһировка[1]

26 февраль 1928 ел

Мөхәммәт иптәш.

Бу сиңа язган хат белән берлектә Совнарком рәисе Исмаев[2] иптәшкә ике мәсьәлә турында үтенеч җибәрдем.

Бер мәсьәлә – минем дәвалануым өчен хөкүмәттән ярдәм турында. Беләсеңдер, буңарчы дәвам иткән февраль эчендә туктатылып, мине гадәттән тыш уңайсыз хәлгә куйды бит. Миңа 183 сум жалуния – бер, 175 сум ярдәм – ике. Барлыгы 358 сум килә иде. Ахрысы, Мәскәүнең миңа авыру вакытым өчен персональный пенсия бирәчәк дигән хәбәрен (180 сум) ишеткәч, боларны шул сылтау белән бөтенләй кистеләр. Мәскәү (180) нең хәбәре килсә дә, үзен алганым юк әле. Ул Казанга җибәрелеп, аннан минем үтенеч буенча Кырымга күчәчәк икән. Бу волокита әйләнеп чыкканчы, мин монда ярлы укытучылардан акча бурычка соранып яшәрем.

Кичә ике мәртәбә телеграмм (берсен җавабы түләнгән) биргәннән соң, 185 сум акча алдым. Аны ТатЦИК җибәргән. Бу ни эштер, аңламадым. Мәскәү пенсия биргән дип миңа жалунияны туктатсалар да (183 сум), әмма теге минем дәвалануым өчен җибәрелә торган 175 сум, әлбәттә, тукталып калмый килергә тиешле бит. Хөкүмәтнең карары шулай бит. Мәскәү пенсиясе бу ярдәмне аларга каршы булмавын күрсәтү өчен мин Сезгә персональный пенсия чыккан кешеләрнең кулларына бирелгән карарлардан беренче маддәне күчереп җибәрәм һәм ышанамын, бу мәсьәләне бутап, минем дәвалану эшемне ярты юлда калдырмаслар дип. Чөнки Мәскәүнең 180 сумында мин һәрвакыт кеше ярдәменә мохтаҗ, каты хәстә, әлбәттә, Ялтада яши алмыйча, Казанга кайтырга мәҗбүр булырмын.

---

[1] Төп нөсхә (кулдан кириллицада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (15 ф., 3 тасв., 6367 эш, 15 (икенче ягы), 16 кәг.); күчермәсе дә бар (15 ф., 3 тасв., 6327 эш, 13, 14 кәг.). Беренче мәртәбә «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» җыентыгында (Казан, 1989, б. 54–55), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 142–143). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Исмаев* – Кәримулла Хөснетдин улы Исмаев (1898–1978), 1928–1930 елларда Татарстан Халык комиссарлары Советы рәисе.

Боларны Исмаев иптәшкә яздым, син дә мәгълүмат бирсәң иде. Икенче мәсьәлә – квартир мәсьәләм. Гомер буе җүнле бүлмәсез, квартирасыз яшәгәннән соң, үзем ташландык квартир табып, коммунхоз төзәтеп җиткерә алмагач, үзем гонорарымнан ремонт ясатып кергән идем. ТатЦИК үткән ел мине гыйльми, әдәби эштә картайган, авыру хезмәтче дип, бу квартираны миңа буш файдаланырга бирү турында Бәһаветдинов[1] иптәш имзасы белән карар да җибәрткән иде. Хәзер шул җимерелгән икән. Бу хакта да яздым. Бу мәсьәлә бөтенләй синең җилкәңдә барганга, бәлки, тагын бер мәртәбә сөйләшеп карарсың. Сине мәшәкатьлим. Ләкин башка ни чара? Бу ике нәрсә минем тыныч дәвалана алуымның төп шартлары бит. Хуш. Иптәшләрчә сәлам.

Галимҗан – Ялта – 1928 – февраль 26.

[1] *Бәһаветдинов* – сүз Гыймаз Бәһаветдинов хакында бара.

## «Башҡортостан» гәзитенә хат-телеграмма[1]

17 март 1928 йыл

Ялта, 14 нсе март.

Һуңғы айҙарҙа күп ойошмаларҙан, тантаналы йыйылыштарҙан, айрым кешеләрҙән йегерме йыллыҡ хеҙмәтемде ҡотлап бик күп телеграмдар, хаттар, тәбриктәр, мәҡәләләр алдым. Быларға айрым яуаптар бирергә мөмкинлегем булмағанға, аҙ хеҙмәтемде олуғлап йебәргән ҡотлауҙарҙың бөтәһенә матбуғат арҡылы тәрән күңлемдән рәхмәттәр уҡыйым. Мин пролетариат революцияһенең бер һалдатымын. Бөтә үткән тормошом мине быңа әҙерләп китерҙе. Үҙемде тыуҙырған, тарихи теле тыуған булған татар халҡымдың ғына һәм яҡын ҡәрҙәш халкыбыҙ башҡорттар ғына түгел, бәлки донъялағы бөтә иҙелгән милләттәрҙең ижтимағи аҙатлыҡтары пролетариат байрағы аҫтында, ленинизм нигеҙҙәренсә көрәшкәндә генә мөмкин тип эшләүселәрҙәнмен. Әгәр игенсе-крәҫтиән халҡына файҙалы әйберҙәр бирә алған булһам, мының сәбәптәре минең шәхси талантымда ғына түгел, бәлки революцион ялпыға бағланған булғанлығынан да, бигрәк тә тарихтың берҙән бер ижадсы юлбашсы принцибы – марксизм методтарының миңә биргән ҡеүәтендә күрһәткән тура юлдарындадыр.

Үҙемде шулай аңлайым. Телеграмдарҙа сәләмәтлегемде һорайҙар. Аҡрынлап төҙәләм. Көстәрем яңынан ҡайтырҙар тип ышанам. Киләсәктә ғилми, әҙәби хеҙмәттәремде революцион марксизм нигеҙҙәрендә дауам иттерә алыу өмөтөндә йәшәйем.

Коммунислыҡ сәләме менән:

Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] Хат-телеграмма «Башҡортостан» газетасының 1928 елгы 17 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге башкорт хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла, орфография һәм стиль үзенчәлекләре сакланды.

## Татарстан Социал Советлар Җөмһүрияте
## Халык мәгариф комиссариатына[1]

17 апрель 1928 ел

Кырымда дәваланучы авыру мөхәррир Галимҗан Ибраһимовтан

XX еллык хезмәт юбилей ясалу уңае белән Татарстан Халык мәгариф комиссариаты тарафыннан минем яныма җибәрелгән Гыйльми үзәк рәисе Мөхәммәт Таһиров иптәш Кырым-Ялтага, миңа килеп, үзенең хөкүмәт һәм Мәгариф комиссариаты исеменнән котлауларын ирештерү белән бергә 20 еллыкның байтак материалларын да тапшырды. Аз хезмәтемне олуглап бирелгән адрес һәм кадерле тышта бүләк ителгән ике китап өчен аеруча рәхмәтләремне белдерәм.

Сәламәтлегем арта бара. Күптән түгел консилиум булды, моның карары, тулы мәгълүматы Мөхәммәт Таһиров иптәш аркылы Татарстан Халык мәгариф комиссариатына җибәрелде. Ул тапшырыр.

Татарстан Халык мәгариф комиссариаты тарафыннан, үзенең җаваплы юлбашчыларыннан берсе булган Мөхәммәт Таһиров иптәшне җибәреп миңа әхвалне белдерүе, хәлемнең яхшыруына чаралар күрүе өчен аеруча рәхмәт укырга үземне бурычлы саныйм.

Коммунистлык сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.
1928 – апрель 17 – Ялты.

---

[1] Беренче мәртәбә «Безнең юл» журналының 1928 елгы 5 нче санында (б. 29), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 144–145). Текст журналдан алынды.

## 1930
## Ике мәсьәлә уңае белән (мәдәният, яңалиф)[1]

Татар мәдәнияте турындагы китап моннан өч ел элек басылып чыкты[2]. Чыгуы белән, 1927 нче елның язында ук партия активының киңәшмәсендә бу хакта ВКП(б) Татарстан Өлкә Комитетының җаваплы секретаре тарафыннан доклад ясалып, мәсьәлә тикшерелде, әсәрдә булган ялгышларымны күрсәтеп, аерым карарлар кабул ителде[3].

Ләкин ул чакта, каты авырып, үләр хәлендә Кырымда дәваланып яткан заманым булганга[4], үз вакытында бу мәсьәләгә катнаша алмадым. Шулай ук партия оешмасы активының киңәшмәсе тарафыннан кабул кылынган резолюциядә күрсәтелгән хаталарымны икърар кылып, боларны төзәтергә тиешлеген белдереп матбугатка да чыга алмадым.

Бу ел Татарстан партия оешмасында уң, «сул» группачылыкларны бетерү уңае белән, ул мәсьәлә икенче тапкыр калкып килеп чыккан һәм яңадан кузгатылган икән. Казанда Татиздат тарафыннан Г. Кушай[5] иптәш карамагында «Контрреволюцион

---

[1] Беренче мәртәбә «Безнең юл» журналының 1930 елгы 3–4 нче кушма санында (б. 53) «Редакциягә хат» дигән рубрикада, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (б. 154–156) бастырылган. Текст журналдан алынды.

[2] *Татар мәдәнияте турында китап моннан өч ел элек басылып чыкты* – Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1927.– 40 б.

[3] *...1927 нче елның язында ук партия активының киңәшмәсендә бу хакта В.К.Р.(б) Татарстан Өлкә Комитетының җаваплы секретаре тарафыннан доклад ясалып, мәсьәлә тикшерелде, әсәрдә булган ялгышларымны күрсәтеп, аерым карарлар кабул ителде* – мәсьәлә 1927 елның 14 июнендә ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты бюросында тикшерелеп, ул китапка карата тискәре мөнәсәбәт белдерелә: Мухсинов З. Дом Татарской Культуры (Приложение: библиография печатных материалов о Доме Татарской культуры, составленная С. Тагировой) / З. Мухсинов.– Казань, 1930.– С. 10–13.

[4] *...үләр хәлендә Кырымда дәваланып яткан заманым булганга* – Г. Ибраһимовны, Иске клиникада бер ай (21 марттан 21 апрельгә кадәр) ятканнан соң, дәваланырга Кырымга Ялта шәһәренә алып китәләр.

[5] *Г. Кушай* – Гобәйдулла Габдулла улы Кушаев (1902–1937), журналист. Бу вакытта «Кызыл Татарстан» мөхәрриренең урынбасары. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

солтангалиевчелеккә[1] каршы»[2] исемендә чыгарылган мәҗмугада, Газыйм Касыймов иптәш минем ул китабыма кагылып үтә (68 нче бит)[3], һәм мондагы ялгышларны язучының төзәтүе тиешлеген әйтеп уза. Мин моны мәкалә иясенең үз шәхси фикере дип кенә карамадым. Шуның өчен дә хәзер, инде өч елдан соң булса да, партия алдында матбугат аркылы түбәндәгечә игълан итүне үземнең коммунистлык бурычым саныйм:

Татар мәдәнияте турындагы китабымның партия оешмасы тарафыннан күрсәтелгән бөтен хаталарын икърар кылам[4] һәм партия актив киңәшмәсенең бу хактагы карарларын дөрес дип табам.

Бу уңай белән шуны арттырырга тиешле табам.

1928 нче елның 13 нче маенда чыккан «Кызыл Татарстан» гәзитендә яңалиф мәсьәләсендә минем карашымны ачык күрсәткән мәкалә басылды[5]. Ул мәкаләдә мин яңалифкә күчү

---

[1] *...солтангалиевче* – 1920–1930 елларда СССРда татар һәм башкорт һәм башка төрки халыкларның партия, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренә «милли тайпылышта» гаепләп тагылган сәяси ярлык. «Солтангалиевчелек» төшенчәсе совет сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиевнең (1892–1940) эшен тикшерү барышында таралыш ала. Ф. Бурнашка 1929–1930 елларда ук солтангалиевчеләргә теләктәшлек итүче шагыйрь дигән гаепләүләр бирелә башлый. Мәсәлән, кара: Mortazin S. Ədəbiatta cit sьjnьf cɵƣşlarь turnda dokumintlar / S. Mortazin // Jaŋalif.– 1930.– № 5.– B. 65–68; Tulumbajski Ƣ. Soltanƣliefcelər eşe turnda jaŋa dokumint / Ƣ. Tulumbajski // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 12 nojəbr. Ф. Бурнаш, үзенең гаепләрен танып, матбугатта хат та бастырырга мәҗбүр була: Bornaş F. Ridaksiəgə xat / F. Bornaş // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 5 dikəbr. Янә кара: Yzbəkstan soltanƣliefcelərе // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 13 iyl.

[2] *«Контрреволюцион солтангалиевчелеккә каршы»* – Kontr-rivolytsion soltanƣliefcelekkə qarşь (Çiьntьq)/ Tɵzycese – Ƣ. Quşaj.– Qazan: Tatizdat, 1929.– 100 b.

[3] *...минем ул китабыма кагылып үтә (68 нче бит)* – Qasьjmьf Ƣ. Kul’turь məs’ələsndə soltanƣliefcelek / Ƣ. Qasьjmьf // Kontr-rivolytsion soltanƣliefcelekkə qarşь (Çiьntьq)/ Tɵzycese – Ƣ. Quşaj.– Qazan: Tatizdat, 1929.– B. 65–68.

[4] *Икърар кылам* – таныйм.

[5] *...яңалиф мәсьәләсендә минем карашымны ачык күрсәткән мәкалә басылды* – Таһиров М. Кырым истәлекләре / М. Таһиров // Кызыл Татарстан.– 1928.– 13 май. Анда Г. Ибраһимовның яңалиф хакында шундый фикерләре китерелә: «…Сөйләшә торгач, хәреф, әлифба мәсьәләсенә килеп җиткәнбез. Ул бу турыдагы Өлкә комитетының һәм Татарстан хөкүмәтенең карарлары белән таныш. Ул бу турыда менә нәрсә ди: «Партиянең Татарстан Өлкә комитеты тарафыннан ачык карар, Татарстан хөкүмәте тарафыннан рәсми декрет чыкканнан соң бу хакта тагы нинди сүз, нинди икенче караш булырга мөмкин?» – ди. «…Мин һәрнәрсәдән элек партия әгъзасымын. Моннан ике ел элек партиянең Татарстан органнары рөхсәте белән ачылган

мәсьәләсендә үз тарафымнан ясалган сәяси хатаны икърар кылып, Татарстан партия оешмасының тоткан юлы буенча, үз ялгышымны төзәтеп үттем, татар хезмәт массасын бөек мәдәни үсү коралы булган яңалифне тизлектә тормышка кую юлында практик эшкә чакырып яздым.

Ләкин ул ике турыдагы ялгыш адымнарның авыр нәтиҗәләре быел ачыла төште.

Мин Татарстанда уңнарга, солтангалиевчеләргә каршы еллар буенча сугыш алып барган коммунистларның берсемен. Мин 1924 нче елда Мәскәүдә басылган «Кара маяклар»[1] атлы китабымда солтангалиевчеләрне фашистлар дип, Шәрык фашистлары дип атадым, гомумән аларга каршы каты көрәш фронтында бардым. Ләкин югаргы ике мәсьәлә миңа бер трагедия булып чыкты: солтангалиевчеләр минем мәдәният һәм яңалиф турындагы хаталарымны үз хәрәкәтләренә хезмәт иттерергә тырышканнар, үзем кискен рәвештә солтангалиевчелеккә каршы барганым хәлдә, минем ул ике сәяси ялгышым – солтангалиевчеләр тегермәненә су булып төшкән[2], алар шулай файдаланганнар. Контрреволюционер солтангалиевчелек хәрәкәте турында матбугатта игълан ителгән материаллар хәзер моны нык ачып

һәм партия газетында дәвам кылган ул каты дискуссиягә катнашу бер нәрсә; безнең партиябезнең тарихында, уставында бу бик табигый һәм мәгълүм бер әйбер. Әмма партия оешмасының, совет хөкүмәтенең ачык карарларыннан, рәсми декретыннан соң бу турыда яңадан мәсьәлә, сүз кузгатып яки карышып азаплану бу инде бөтенләй башка нәрсәгә әйләнә: большевик-коммунист өчен ярамый торган әйбергә әверелә».

[1] Ибраһимов Г. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар / Г. Ибраһимов.– Мәскәү: «Нәшрият» кооперативы, 1924.– 70 б.

[2] *...солтангалиевчеләр тегермәненә су булып төшкән* – бу Г. Ибраһимовның 1927 елда нәшер ителгән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китабы хакында Г. Толымбайский язган мәкаләдән: «Шуның белән бергә Галимҗан ага үзе дә аңларга тиеш – аның бу китаптагы карашлары, объектив караганда, *солтангалиевчеләрнең тегермәненә ныклап су коя*, хәзерге сыйнфый көрәш көчәйгән бер чорда партиянең эшенә нык комачаулый. Шуңа күрә ул үз ялгышларын үзе дә ачып салырга тиеш. Яңалиф турындагы ялгышу белән культура турындагы ялгышуы – бер-берсенә нык бәйләнгән. Ибраһимов моны нык аңларга тиеш»: Tulumbajski Ƣ. Iskrməgən ber uŋnьq turnda / Ƣ. Tulumbajski // Bezneŋ jul.– 1929.– № 11.– B. 25. Г. Касыймовның «Солтангалиевчелек һәм аның тарихи тамырлары» дигән китапта да шулай әйтелә: «Менә шул мәсьәләдә дә Галимҗан ип. Ибраһимов көрәшнең иң кызу чорларында алар ягында тора, аларга әсир төшә һәм үзенең шул эше белән ул объектив рәвештә аларга, *солтангалиевчеләр тегермәненә су сала*»: Qasimof Ƣ. Soltanƣəliegcelek həm anьŋ tamrlarь / Ƣ. Qasimof.– Qazan: Tatizdat, 1930.– B. 84.

бирделәр. Бу хаталарның минем өчен иң фаҗигале ягы менә шул партия-совет дошманнары тарафыннан пролетариат революциясенә каршы хәрәкәттә корал ителүләре булды.

Һичнәрсә эшләмәгән кеше генә ялгышмый, диләр. Байтак елларга сузылган күптөрле хезмәтләрем эчендә минем дә хаталанган чакларым булуы, әлбәттә, мөмкин иде. Җүеш урыннардан үткәндә пролетариат революциясенең иң көчле солдатларының да аяклары тайган чаклары булганын һәркем белә. Югарыгы ике мәсьәлә – ленинчы большевикның күп хезмәтләр, күп тикшерүләр арасында аяк таеп киткән аерым моментлары булып кичтеләр, партия юлбашчылыгы белән төзәтелделәр.

Мин һәрвакытта, һәр эштә партиянең туры эшчесе, туры көрәшчесе булуымны үземә максат итеп тотканмын. Контрреволюционер солтангалиевчелек хәрәкәтенең иң кискен дошманы булып килдем һәм әле дә, алда да шулай барачакмын.

Мин пролетариат революциясенең бер солдатымын, әле хәзер авырып имгәнгән солдатымын. Ләкин сәламәтләнеп эш көчем кайту белән яңадан винтовкага, яңадан марксизм-ленинизм нигезендә гыйльми, әдәби хезмәтләргә тотынырга әзер торам.

Коммунистлык сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.

*«Безнең юл» редакциясе Г. Ибраһимовның бу хатын басу белән бергә «Кызыл Татарстан» редакциясенең шушы хатка карата булган түбәндәге искәрмәсен дә урнаштыруны кирәкле саный һәм үзенең тулы килеш шушы искәрмәгә кушылуын белдерә.*

Галимҗан Ибраһимов иптәш пролетариат культурасы һәм шуның бер тармагы булган яңалифкә ялгыш каравы белән объектив рәвештә солтангалиевчеләр тегермәненә су койды. Бу ялгышларын Галимҗан Ибраһимов иптәш икърар итә.

Ләкин бу ялгышларның ничек эшләнүен ул «гади аяк таюлардан булган бер аяк таюы» рәвешендә куеп, мәсьәләне кечерәйтә төшә. Безнең фикеребезчә, Ибраһимов иптәшнең бу сәяси хаталары гади бер революция солдаты тарафыннан эшләнгән гади бер аяк таюы гына түгел, бәлки, Ибраһимов иптәшнең үткәннәре белән бәйләнгән һәм шулар тәэсире астында килеп чыккан хаталар. Ибраһимов иптәш безнең партиябезгә килгәндә үзе дә вак буржуа эченнән чыгып[1], эсерлык баткаклары аша үтеп

[1] *...үзе дә вак буржуа эченнән чыгып* – Г. Ибраһимовның мулла гаиләсеннән булуына ишарә булса кирәк.

килгән зур язучы. Безнең фикеребезчә, аның бу хаталарында, һичшиксез, менә шул үткәннең, менә шул тарихның үзен сиздерүе, менә шуларның икенче шартларда кабатлануы ята. Монда һичбер төрле шик-шөбһә мөмкин түгел.

Ләкин, Ибраһимов иптәш, хәзерге вакытта каты авырулыгына да карамастан, мондый күрсәтүләргә әһәмият биреп, соң булса да хаталарны игътираф итүен[1] искә алып, аның шушы хатын басуны кирәк таптык.

«Кызыл Татарстан» редакциясе.

---

[1] *Игътираф итүен* – тануын.

## Кави Нәҗмигә[1]

27 май 1930 ел

Кадерле Кави,

үз вакытларында хатыңны да, телеграмыңны алдым. Бер җавап та салган идем, шаять, тапшырылган булыр.

Бу хат белән бергә сиңа «Ерактан сәлам» мәкаләсен җибәрәм. Әйтүеңчә, бу – юбилейга карата язылды. Син анда кемнәргә нинди темаларга мәкаләләр бирелгәнен әйтмәгәнсең. Шуңа күрә миңа гомумирәк рәвештә язарга туры килде. Бәла бит, үпкә, тамак, плеврит өстенә бу арада уң як кабырганың тышкы ягына эреннәр чыгып, бик каты җәфалады. Бу мәкаләне шул газаплар эчендә яздым. Үзең карарсың, редколлегиядә укырсыз. Юбилей мәкаләләрендә кабатлаулар булгалый. Анысы табигый эш. Мәкалә басылган мәҗмуга – альманахны миңа җибәрерсең[2]. Бусын ашыгыч почта белән салдым. Үзең бит май 30 дигәнсең. Салынганлык турында телеграм да бирдем. Ничектер, эшегез бик тыгыз килгәнгә ошый. Унъеллыкка хәзерлек ел буенча барган хәлдә, сезгә бу эш бары май 15 ндә генә башланырга бирелгән бугай. Әгәр электәнрәк хәбәр ителсә иде, мин дә авыруга карамастан, иске әдәби әсәрләрдән берәрсен актарып яки, чама килсә, яңадан оештырып җибәргән булыр идем. Һәрнә хәерле булсын, башка нәрсә өлгертергә һич бер җай калмады.

Үземдә хәлләр бер төрле. Быел язга таба борчуларым байтак арта төште, каты түзем, каты чыдам белән барам. Менә бәла бит. Кешеләр бер төрле үпкә туберкулезы белән генә еллар буенча авырыйлар. Миндә үпкәгә тамак, аңа эренле плеврит кушылды.

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 75), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 158–159) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Кави Нәҗми ул вакытта Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясенә җитәкчелек итә, «Атака» (хәзерге «Казан утлары») журналының баш мөхәррире була.

[2] *Мәкалә басылган мәҗмуга – альманахны миңа җибәрерсең* – бу хат 1930 елның җәендә Татарстан АССР төзелүгә ун ел тулу бәйрәме уңае белән нәшер ителәчәк әдәби җыентык өчен «Ерактан сәлам» дигән мәкаләсен җибәү өчен язылган. «Ун ел» дип аталган җыентык: Un jьl ecndə tatar matur ədəbiatь (1920–1930) / Tөzyceləre: Qəvi Nəçmi, Ƣ. Niƣməti, Ƣөmər Ƣəli.– Qazan: Tatizdat. 1930.– 471 b. Шул мәҗмугада: Ibrahimof Ƣ. Jraqtan səlam (Tatarstannьŋ un jllьƣьna).– B. 97–104. 27 maj.

Моңа тагын үткән елдан бирле уң кабырга ягыннан тышкы эренле шешләр чыгып (эчке выкачивание эзләреннән) җәзалыйлар. Бары бергә җыелгач, күпкә китә. Шулай да сер бирми, һәммәсенә каршы сугышам. Авыр, җәфалы, газаплы килә, шулай да сугышам. Бу катлаулы җәфа шул чиккә җиткергән чаклары була ки, әгәр менә бу дүрт катлаулы авыру урынына тик өченче стадия үпкә туберкулезы гына булса, мин дөньяда иң бәхетле кеше булыр идем дип уйлап куям.

Мәҗмугагыз, мәкаләләрегез турында, бәлки, бер хат язарсың. Иптәшләргә сәлам әйт.

Галимҗан – Ялты.
1930 – май 27.

## Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмовага[1]

9 июнь 1930 ел

Кадерле Кави һәм Сәрвәр[2] иптәшләр,

Үземнән, Гөлсемнән сәлам соңында сезгә зур үтенеч: үткән хатларымда язган идем, әле дә кабатлыйм, минем уң яктагы плевритым һаман тынычлык бирми, сентябрьдән бирле выкачивание, промывание ясату дәвам итә. Сезнең аркылы Казаннан алган риванол белән берлектә бу операция өчен кокаин даруы кирәк. Сезгә бу хат белән шуның рецептын җибәрәм. Хәзер бу операция миңа 15, 20 көндә бер тапкыр ясалып тора. Шуңа күрә доктор аны күп сорады, бу дару Ялтада бетеп китте. Кайчан килүен белмиләр. Сезне мәшәкатьләүнең сәбәбе дә менә шул.

Алда сорап алган риванол даруы үзенең хезмәтен үтәп килә. Бусы да шул дәрәҗәдә кирәк булып торадыр.

Сәрвәр туган, бунын зуррак мәшәкате Сезгә төшәр инде. Укуыгыз, эшегез өстенә[3] булса да ничек тә бер вакыт табып, башкара күрүегезне бик үтенәм. Иң элек, әлбәттә, Татнаркомздравтан сорарсыз. Булмаса, бәлки, башкача табылыр. Казан баерак бит! Иптәшлек сәламе белән: Галимҗан.

Ялты – [19] 30 ел, июнь 9.

P. S. Кави, синең җавап телеграмыңны алдым, рәхмәт. Мәҗмуга-альманах чыккач, миңа җибәртергә онытма инде.

Г.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 103–104), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 200, б. 159–160) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Сәрвәр* – Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова (1901–1979), язучы, тәрҗемәче; К. Нәҗминең хатыны.

[3] *Сәрвәр туган... Укуыгыз, эшегез өстенә* – бу елларда С. Әдһәмова Совет хокукы һәм төзелеш институтында укый, бер үк вакытта Татарстан Үзәк крестьян йорты каршындагы хокук бүлегенең мөдире булып эшли.

## Кави Нәҗмигә һәм Сәрвәр Әдһәмовага[1]

5 июль, [1930] ел

Кави, Сәрвәр иптәшләр,

Бүген генә сезгә хат салган идем. Шуның яңлыш маркасын ябештерергә онытканнар. Түләп ала күрегез. Белмичә кире китмәсен.

Галимҗан.
Июль 5 [1930], Ялты.

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Фотокүчермәсе беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1967 елгы 3 нче санында (б. 143), тексты Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 160) бастырылган. Елы почта мөһере буенча куелды. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Пролетариат сәнгате һәм культурасында зур уңышларга ирешкән Татарстанга, ТҮБК председателе ип[тәш] Моратхуҗинга[1]

23 июль [1930] ел

Татарстанның X еллык юбилей тантанасына чакыруыгыз өчен зур рәхмәт[2]. Ләкин, кызганычка каршы, сәламәтлегемнең авыр хәлдә булуы бу зур бәйрәмгә үзем кайтып катнашырга мөмкинлек бирми.

Шуның өчен дә, иптәш Моратхуҗин[3], Татарстан Советлар Җөмһүриятенең хезмәт ияләренә минем чын күңелемнән кайнар сәламемне тапшыруыгызны сорыйм.

Татар пролетариат искусствосында булган гаять зур уңышлар, культура төзелешендәге әлегә кадәр күрелмәгән үсүләр, социализм төзелешендәге җиңүләр, иске таркау авыл хуҗалыгын яңача коллективлаш[тыр]у нигезендә төзүдәге уңышлар белән хезмәт ияләрен минем исемнән котлавыгызны үтенәм.

Мондый уңышлар безнең кебек карт буын эшчеләрнең буталчык уйларында хәтта шәүләләнмәгән дә иде.

Яшәсен партиянең ленинча юлбашчылыгы астындагы эшче-крәстиән массасының омтылышлы иҗат көче!

Яшәсен Татарстанның X еллыгы: Галимҗан Ибраһимов.

23 июль, Ялты.

---

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1930 елгы 25 июль санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 160–161) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] *Татарстанның X еллык юбилей тантанасына чакыруыгыз өчен зур рәхмәт* – 1930 елның 25 июлендә Татарстан Республикасы төзелүгә 10 ел тулу бәйрәме үткәрелә. «Кызыл Татарстан» газетасының 1930 елгы 25 июль саны шул юбилейга багышланган.

[3] *Моратхуҗин* – Харис Ибраһим улы Моратхуҗин (1895–1955), 1929–1932 елларда ТҮБК (Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты) Президиумы рәисе була.

## Кави Нәҗмигә[1]

13 август 1930 ел

Кави, Сочи хатыңны алдым. Нык тазар. Үзеңә дә, Сәрвәргә дә теләк шул. Бездә исәнлек, дөресрәге, исәнлек өчен үпкәдәге микробларга каршы туктаусыз көрәшү! Башка юк!

Альманах килде, шәп чыккан. «Кояшлы яңгыр»ны бик яратып укыдым[2]. «Атака»[3] чыккан, гәзиттә аның турында Мөбарның зур мәкаләсе басылды[4].

Сочидан Ялта аркылы кайтып, безгә керсәгез, күңелле булыр. Гөлсем дә Сәрвәрне бик сагынып көтә.

Туры безгә төшегез! Сыярбыз, ачыкмабыз. Кудаш[5] белән Булат[6] андалар икән, үзләренә сәлам әйт. Ялтага килсеннәр! Кудашның бик күптән хат-хәбәре дә юк. Хәзергә башка нәрсә яза алмыйм, үзегезне Ялтага көтеп калам[7].

Сәлам белән: Галимҗан.
1930, 13.VIII. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы (б. 75–76), аннан соң «Казан утлары» журналының 1987 елгы 3 нче (б. 76) саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 161) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Кояшлы яңгыр»ны бик яратып укыдым* – Nəçmi Q. Qojaşlь jaŋƣьr / Q. Nəçmi // Un jьl ecndə tatar matur ədəbiatь (1920–1930) / Təzyceləre: Qəvi Nəçmi, Ƣ. Niƣmәti, Ƣөmər Ƣəli.– Qazan: Tatizdat. 1930.– B. 184–251.

[3] *«Атака»* – 1930–1932 елларда Казанда чыккан әдәби-иҗтимагый, Татарстан пролетариат язучылары оешмасының басма органы булган журнал. Аннары «Совет әдәбияты» дип атала, хәзер – «Казан утлары».

[4] *Мөбарның зур мәкаләсе басылды* – Фазыл Мөбарәкша улы Мөбарәкшин (1903–1987) – журналист; «Атака» журналы чыгуы хакында аның мәкаләсе шулай: Mөbar. «Ataka» cqtь / Mөbar // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 7 aug.

[5] *Кудаш* – Сәйфи (Сәйфетдин) Фәттах улы Кудашев (1894–1993), шагыйрь, БАССРның халык шагыйре (1964).

[6] *Булат* – Булат Ишемгол (Габдерахман Закир улы Габдерахманов, 1900–1938), башкорт язучысы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[7] С. Әдһәмованың истәлегеннән күренгәнчә, алар, ягъни ул үзе, К. Нәҗми, С. Кудаш, Б. Ишемгол Сочидан пароходта Ялтага Г. Ибраһимов янына килгәннәр: Әдһәмова С. Таләпчән һәм киң күңелле кеше / С. Әдһәмова // Г. Ибраһимов турында истәлекләр / Төзүче һәм әдәби эшкәртүче Афзал Шамов.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1966.– Б. 273.

## Кави Нәҗмигә[1]

21 декабрь 1930 ел

Кави, сиңа җавап телеграмы биргән идем, адресын саташтырып, яңадан төзәтеп йөределәр, шуңа күрә тагы бер-ике язам: татар телендә массага күп тиражлы әдәби китаплар сериясенә мин кулдан килгәнчә, әлбәттә, катнашырмын. Кәеф баррак чакта каралынып куелган кечкенә хикәяне («Корбан» – колхоз бригадалары тормышыннан) аклап җибәрермен.

Телеграмда да шуны әйттем. Бу масса нәшрияты турында вакыт табып озынрак хат яз әле.

Сәрвәргә, батыр егеткә[2] сәлам.

Галимҗан.
Ялта – 1930. 21. XII.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 76), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 163) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Батыр егеткә* – Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмованың улы Тансык Нәҗметдинов (1927–2008), радиофизик, физика-математика фәннәре кандидаты (1965).

# 1931

## Кави Нәҗмигә[1]

23 гыйнвар 1931 ел

Кадерле Кави!

Хатыңны алдым. Син кузгаткан мәсьәләләргә кыска гына җаваплар биреп үтәм.

1 – «Корбан»ның элек «Атака»да басылып үтүен әйткәнсең[2], мин моңа бик риза. Шулай яхшы булыр, массага тизрәк барып җитәр дип карыйм, ул нәрсәне моңарчы аклап чыгып сезгә җибәргән булыр идем, Рөстәм кызамык чыгарды, аннан колакка авыруы көчте, һич тынычлык бирми; җитмәсә тагы һавалар начарланып, үземне бераз изеп-ватып алдылар. Шулар сәбәпле кичегәм. Ләкин тизләргә тырышырмын.

2 – Иҗат методым уңае белән берәр нәрсә язып җибәрүемне кузгаткансың[3]. Яңа призыв әдәби ударникларга[4] багышлап, шул син әйткән нәрсәгә якын бер әйбер – бер үткәнгә анализ минем башымда бар, буны җибәрермен, карарсың, һәрхәлдә, анда минем берәр нәрсә – берәр әсәрем иҗат методы буенча тикше-

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 76) шактый кыскартылып, аннан соң тулы варианты Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (б. 163–165). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Корбан»ның элек «Атака»да басылып үтүен әйткәнсең* – Г. Ибраһимовның андый әсәре бастырылмаган.

[3] *Иҗат методым уңае белән берәр нәрсә язып җибәрүемне кузгаткансың* – авыруы көчәеп китү сәбәпле, мәкалә язылмаган.

[4] Ул чорларда эшче-ударниклар арасыннан әдәбиятка яшь кадрлар туплау кампаниясе була. Бу мәсьәләгә багышлап, Харьков шәһәрендә махсус конференция уздырыла: Sotsializm өcen kөrəştə prolitariat ədəbiatь ysə həm noꞁьj. Jazuclar safьna udarniklarnьŋ jaŋa kalonnalarь kilə // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 25. Көндәлек матбугатта бик күп мәкаләләр бастырыла. Мәсәлән: Tatar prolitariat ədəbiatьna udarniklar prizьjfь başlandь. Udarniklar prizьjfьn uzdьruda TAAP sikritariatnьŋ өndəmse // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 17–18; Qarataj S. Udarnik! Qulьŋa qələm al! / S. Qarataj // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 19–20. Мәсьәләне хәл итү өчен язучыларны төркемләп, төрле оешмаларга беркеткәннәр: Prolitariat ədəbiatьna udarniklar prizьjfь uzdьru ştabnnan // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 21. Әдәбиятка ударниклар килүе хакында хәбәрләр бастырылган: Eşce-udarniklar kilələr // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 24. Ударниклар туплау хәрбиләр арасында да җәелдерелә: M. Э. Ştьjklь udarniklar matur ədəbiatta // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 28.

рергә – исәп булса, минем үз иҗатларым турында үз анализым сиңа барып җиткәнче кичектерерсең. Яшереп торасы юк, бөтен әдәби дөньяга көн кебек ачык бернәрсә бар: күп еллар буенча туктаусыз өргән Бурнаш-Исәнбәтләр[1], берсе солтангалиевче, берсе кара контр җидегәнче[2] булып ачылулары сәбәбеннән, бу

---

[1] *Исәнбәт* – Әхмәтнәкый Сираҗетдин улы Закиров (1899–1992), ТАССРның халык язучысы (1986), драматург, шагыйрь, тел-әдәбият галиме, фольклорчы.

[2] *…җидегәнче* – 1928 елның җәендә Уфада язучылар һәм шагыйрьләр Н. Исәнбәт, Гадел (Гаделша) Нурмөхәммәт улы Кутуй (Кутуев, 1903–1945), Габдрахман Мөхәммәт улы Минский (Аллаһбирдиев, 1906–1983), Сәгыйть Ишмөхәммәт улы Агиш (Агишев, 1904–1973), Сәйфи (Сәйфетдин) Фәттахетдин улы Кудаш (Кудашев, 1894–1993), Төхфәтулла Гыйззәтулла улы Ченәкәй (Ченәкәев, 1893–1959) тарафыннан оештырылган, пролетариат әдәбиятына дошман булган контрреволюцион оешма дип аерым кешеләр тарафыннан уйлап чыгарылган уйдырма. Татарстан Язучылар оешмасы җыелышының 1930 елгы 2 сентябрь карары белән Г. Минский һәм Г. Кутуй оешмадан чыгарыла: Kontr-revolytsion jəşren «Çidegəncelər» turьnda Tatar Sovit Jazuclar Ojşmasь // Jaŋalif.– 1930.– № 2.– B. 60. Мәсьәлә хәтта ВКП(б) Татарстан Өлкә Комитетында да карала: «Çidegən» turьnda VKP(b) Tatarsatan Ɵlkə Komititьnьŋ 1930 nсь jьl, 26 nсь sintəbrdə cƣarƣan qararь // Jaŋalif.– 1930.– № 5.– B. 69.

Ул елларда көндәлек матбугатта «җидегәнчеләрне фаш итү»гә багышланган байтак мәкаләләр дөнья күрә. Мәсәлән, Mɵbar. «Çidegən»gə qarşь soŋƣь-nьq udar bulsьn / Mɵbar // Jaŋalif.– 1930.– № 2.– B. 66–70; Mosaƣit F. «Çidegən» / F. Mosaƣit // Jaŋalif.– 1930.– № 2.– B. 71–73; Ƣəli Ƣ. «Çidegən»gə qarşь kɵrəş kisken bulrƣa tieş / Ƣ. Ƣəli // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 1–3; «Çidegəncelər»gə bzneŋ protis // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 4–5; Tatarstan prolitariat jazuclarь ojşmasь clnnəreneŋ tulь cilьşьnьŋ (rus, cuaş siksilәre blən brgə)»Çidegən» ismndəge jşren ojşma turndaƣь rizolytsiəse // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 5–6; Donbas tatar prolitariatь «Çidegənce»lərgə qarşь ajausьz otpor biryne sorьj // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 6; «Çidegənce»lərgə bzneŋ protis: Ƣ. Qadir, A. Aliş, D. Mortьj, Ƣ. İndyk, Ƣ. Kəlti, X. Işmurat, Raxmanqulof, Əxmirof, Qutlin // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 6; İdelle Ƣ. «Çidegəncelek» məs’ələsen nьq acqlьq krtrgə, anьŋ blən bol’şeviklarca kɵrəşrgə kirək / Ƣ. İdelle // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 9–11; Prolitariat ədəbiatьna qarşь kɵrəş ɵcen ojştьrlƣan «Çidegəncelər» ojşmasьna qarşь Donbas prolitariatnьŋ protisь // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 11–12; «Tuqcuranlь». «Çidegəncelər»dən berse turnda // Ataka.– 1930.– № 3.– B. 13 (Сәгыйть Агиш хакында); Mɵbar. «Çidegəncelər» ojşmasь (Tatar prolitariat ədəbiatьna qarşь kɵrəşyce jəşren ojşma turnda) / Mɵbar // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 19 aug.; Jurin Mix. Ədəbiat frontьnda sьjnfi uyalqnь kɵcəjtrgə / Mix. Jurin // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 3 sint.

Хат авторының Ф. Бурнаш һәм Н. Исәнбәткә болай ташлануының сәбәбе бар. Аның «Татар шагыйрьләре» китабында Г. Тукайга биргән бәяләмәсе белән килешмичә, Ф. Бурнаш «Безнең юл» журналының 1923 елгы 8–9 кушма санында «Тукай турында тәнкыйтьчеләр», Н. Исәнбәт «Яңа авыл» газетасының 1928 елгы 10, 14 март саннарында «Галимҗан Ибраһимов әдәбияты» дигән мәкаләләрендә Г. Ибраһимовны шактый гына тәнкыйтьлиләр.

ике кара авыз үзләре өрүдән туктаса да, буларның «юлларын» дәвам иттерүче адәмнәр әле Казанда туктаусыз ачык эш алып барулары һәммәгә билгеле. Бу Бурнаш-Исәнбәтләр шайкасын дәвам иттерүчеләр хәзер бөтенләй башка сүзләр белән провокация алып баралар икән, аңа карап эшнең төп үзәге, әлбәттә, бер кешедән дә яшерелеп кала алмый. Сүз-пәрдә төрлечә, төрле сәбәп булырга мөмкин, ләкин буларның артында шул ук җидегәнче – солтангалиевчеләрнең «сызган юллары» бар кешегә дә күренә бит.

Кыскасы, бер төркем бәндәләр анда сүгенергә-провокациягә яңа сылтау эзлиләр, шуны таба алмый аптырыйлар. ТАППның зур исемен, зур лозунгларын шундый начар әйбергә корал итмәсеннәр[1].

3 – Музыкада солтангалиевчелек турында диспутлар[2], әлбәттә, бик яхшы, бик кирәкле. Шуның белән бер уңайдан, бәлки, моңардан да элек җидегәнчелеккә каршы конкрет көрәш турында бер доклад, бер диспут кирәк иде түгелме? Казанда кайберәүләр җидегәнчелекне оныттыру, күләгәдә калдыру, активның вниманиесен икенче әйбергә таба отводить итүгә бик тырышалар. Син бу хакта «Атака»да мәкалә яздың[3], бу мәкалә эш-көрәш программы иде, сине шул үткен куелган конкрет задачалардан башка якка таба зиһенең, дикъкатең чәүрергә теләүчеләр бар: булар өч мең чакрым җир аша ачык күренеп торалар!! Мин гәзиттә гыйльми институт турында ТАПП бригадасының

---

[1] *ТАППның зур исемен, зур лозунгларын шундый начар әйбергә корал итмәсеннәр* – ул вакытта ТАПП рәисе К. Нәҗми булганда Ченәкәйнең шундый китабы бастырыла: Cnəkəj. Matur çrlar, cibər syzlər / Cnəkəj.– Qazan: Tatizdat, 1930.– 80 б. Бу китапка крата тискәре бәяләмә дә дөнья күрә: Bajan N. «Matur çrlar, cibər syzlər» jaki cyp-carlar bəjləme (1930 nсы jьl. Tatizdat basmasь. Cnəkəj əsəre. Bəjəse 60 tien) / N. Bajan // Ataka.– 1930.– № 4–5.– B. 46–47. Бу ТАПП җитәкчелеге җидегәнчеләргә булышлык күрсәтә дигән гайбәтләр таралуга китерә. Биредә сүз шул гайбәтләр хакында бара.

[2] *Музыкада солтангалиевчелек турында диспутлар* – ул диспутлар «габәшичелек» атамасы белән бара: A. P. Tatar muzьkasnda «ƣəbəşicelkkə» qarşь // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 28 nojəbr; Tləş Ƣ. Muzьkada bozьq jullarƣa qarşь / Ƣ. Tləş // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 5 dikəbr.

[3] *Син бу хакта «Атака»да мәкалә яздың* – сүз шушы мәкаләләр хакында бара: Nəçmi Q. Bol'şevizm utь / Q. Nəçmi // Ataka.– 1930.– № 4–5.– B. 1–8; Nəçmi Q. Tatar prolitariatь ədəbiatnda bəjek borьlьş başlandь (Tatarstan Prolitariat Jazucьlarь ojşmasnfa uzdьrlƣan tazartu uŋajь blən / Q. Nəçmi // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 4–9.

бик дөрес карарларын укыган идем[1], моны укыгач: «Менә кайда икән гыйлемдә солтангалиевчелек дип уйладым». Нәтиҗә ни булды, бригада карарлары үттеме?

4 – Татиздаттан бер дә хәбәр-хәтер юк. Кави туган, син бер тапкыр телефон белән шул бишенче томның басылу язмышын белеп үтәргә вакыт тап әле[2]. Ул нәрсә берәр җиргә барып төртелмәдеме? Соңга калса, дәреслек басу заманы керер, тагы калыр.

Үзебездә хәл бик начар түгел, ризык ягын һаман өстерибез. Сәламәтләнү өчен сугышны нык алып барам.

Сәрвәргә, Тансык батырга өчебездән дә сәлам.

Күп сагыну белән: Галимҗан.
1931. 23. I.– Ялта.

---

[1] *Мин гәзиттә гыйльми институт турында ТАПП бригадасының бик дөрес карарларын укыган идем* – ул мәкалә шулай атала: Ƣilmi Tikşery İnstitutьnьŋ tel-ədəbiat bylege burƶua blgeclərе qulnda // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 24 dikəbr (анда Гали Рәхим, Галимҗан Шәрәф һәм Җамал Вәлиди гаепләнә).

[2] *Татиздаттан бер дә хәбәр-хәтер юк... бишенче томның басылу язмышын белеп үтәргә вакыт тап әле* – 20 еллык иҗат юбилее уңае белән Г. Ибраһимов әсәрләренең җиде томын нәшер итү планлаштырыла. Бишенче томы 1931 елда бастырыла: Ƣalimçan İbrahimof əsərlərе.– Qazan: Jaŋalif, 1931.– tum V.– 198 b.

## Кави Нәҗмигә[1]

17 февраль 1931 ел

Кави

Бу хатны сиңа хәл белү өчен генә язам.

Февраль башыннан алып бераз кәефсезләнеп торам. Ангина булды, үзе үтсә дә, хәзер шуның нәтиҗәсе бара: бик нык хәлсезлек, ватык, изелгеч бер настроение эчендәмен. «Атака»да басылган «Әдәби түгәрәкләр програмы»[2] турында сезгә дип кайбер төзәтмә-тәкъдимнәр язган идем. Бу кәефсезлек аркасында бетерә алмадым[3]. Иҗат методы белән «Корбан» да шулай яталар. Бик күңелләләнеп барганда, бу җәфа бераз изде.

Сәрвәргә, Тансыкка күп сәлам. 8—9 нчы саннан бирле «Атака» килгәне юк. 6 нчы саннан бирле «Яңалиф» тә юк.

Хуш. Галимҗан.
1931.17.II – Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары»ның 1967 елгы 3 нче санында (б. 145), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 165) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Атака»да басылган «Әдәби түгәрәкләр програмы»* – сүз шул хакта бара: Zavot-fabriklərdəge başlanƣьc ədəbi tygərəkəlr өcen program // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 21–22.

[3] *Бу кәефсезлек аркасында бетерә алмадым* – «Әдәби түгәрәкләр програмы» турында мәкаләсен 27 февральдә язып тәмамлый һәм ул бастырыла: İbrahimof Ƣ. Ədəbi program turnda / Ƣ. İbrahimof // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 65–68. «Кәефсезлек аркасында» дигәндә, авыруына тагын бер сәбәп өстәлә. Чөнки бу программаны ни рәвешле гамәлгә ашыру турында түгәрәк җитәкчеләренә ТАППның кадрлар һәм түгәрәкләр секторы тарафыннан җиткерелгән күрсәтмәдә 10 нчы пункт болай: Ƣ. İbrahimof blən F. Səjfi jalƣьşlarь turnda Tatobkom qərarlarь // Ataka.– 1930.– № 8–9.– B. 23.

## Кави Нәҗмигә[1]

4 май 1931 ел

Кадерле Кави!

«Әдәби тарихыбызның кадерле битләрен таптамау» турында бер мәкалә җибәрдем[2]. Бу – «Кызыл Татарстан» гәзите өчен. Ләкин монда ТАППка бик якыннан кагылган мәсьәләләр бар[3]. Шуңа күрә синең аркылы үтүен тиеш таптым. Син иренмичә карап чыга күр. Аннан соң, риза булсаң, гәзиткә җибәрерсең. Бунын тизрәк чыгуы да, киңрәк актив һәм масса укуы да аеруча кирәк булды. Гәзиткә дип уйлавым шул яктан.

Ләкин андагы хәлләр сезгә ачыграк. Исхак Еникеев[4] яки аның урынбасары Кушай иптәшләр белән сөйләшерсез. Ахыргы нәтиҗәне, әлбәттә, сезгә тапшырам. Һәрхәлдә, бу башкага түгел, җә «Кызыл Татарстан», җә «Атака»ның икесенең берсенә.

Галимҗан Ибраһимов.

Ялта, 4.V.1931.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 104), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 166–167) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Әдәби тарихыбызның кадерле битләрен таптамау» турында бер мәкалә җибәрдем* – Фәхрелислам Агиев 1925 елда Гафур Коләхмәтов хакында шундый китап бастырып чыгара: Гафур Коләхмәтов мәҗмугасы.– М.: С. С. С. Р. халыкларының үзәк нәшрияты, 1925.– 28 б.; Газиз Гобәйдуллин 1930 елда матбугатта үзенең объектив эчтәлекле истәлекләрен бастыра: Ƣөbəjdullin Ƣ. Ƣafur xaqnda istəlklərem / Ƣ. Ƣөbəjdullin // Jaŋalif.– 1930.– № 6.– B. 51–58. Г. Ибраһимов аларны тәнкыйтьләп мәкалә яза һәм ул «Яңалиф» журналында бастырыла: İbrahimof Ƣ. Ədəbi tarixьbьznьŋ qədrle bitləre bolaj taptalmasьn ide / Ƣ. İbrahimof // Jaŋalif.– 1931.– № 5–6.– B. 96–103.

[3] *ТАППка бик якыннан кагылган мәсьәләләр бар* – Г. Ибраһимов үзенең мәкаләсендә Г. Коләхмәтовның мирасын туплап академик басмасын әзерләп бастыру эшен ТАПП җитәкчелегендә Татарстан Фәнни-тикшеренү институты башкарырга тиешлеге мәсьәләсен дә күтәрә.

[4] *Исхак Еникиев* – Исхак Усман улы Еникиев (1900–1937), журналист, бу вакытта «Кызыл Татарстан» газетасы мөхәррире.

## Сәрвәр Әдһәмовага[1]

4 май 1931 ел

Сәрвәр туган!

Телеграм, хатларыгызны үз көннәрендә тапшырдылар. Тормышның иң авыр, трагедияле сәгатьләрендә чын күңелдән дуслык-иптәшлек күрсәтеп, тирән кыйгыбызны уртаклаштыгыз. Миннән һәм Гөлсемнән моның өчен күп-күп рәхмәт.

Хәзергә артык яза алмыйм. Рөстәмнең күмеләсе көндә алынган актык рәсемен җибәрәм[2].

Сәлам белән Галимҗан Ибраһимов.

1931 – май 4 – Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамовада саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 76), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 167) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] 1926 елның 5 ноябрендә туган уллары Рөстәм бу дөньяда нибары 4 ел 4 ай 16 көн яшәп, каты авырудан соң 1931 елның 21 мартында вафат була, 23 март көнне җирләнә. Хәзерге вакытта аның кабере билгеле түгел, үлеме хакында шәһадәтнамә күчермәсе генә сакланган: «Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых» (Казань, 2012, с. 297).

## Кави Нәҗмигә[1]

1.VI – 31.

Кадерле Кави!

Бер айлар элек теге Агиев-Гобәйдуллиннарның Колəхмитов турындагы бозыклыкларын күрсәтеп, мәкалә-тәнкыйть җибәргән идем[2]. Телеграмың килде, ләкин мәкалә һаман юк. Редакция дә җавап бирми. Бераз гаҗәпләнеп калдым. Әллә булса партиябез тарафыннан бирелгән лозунг буенча коммунистларның эшләрен, ялгышларын рәхимсез тәнкыйть алып барылган хәзерге чорда, Агиев-Гобәйдуллиннарның ялгышларын, бозыкларын күрсәтү ярамый дигән берәр мөгез чыгаручылар табылдымы, ягъни Казанда идән астында яшәп килгән астыртын әдәби-тарихи группаларның берәрсе шул бозык-ялгыш нәрсәне тәнкыйтькә каршы идән астыннан ут-интрига йөртергә азапланамы? Яки башка сәбәп бармы? Аптырабрак торам.

Үзем бу арада «Крас[ный] крест» санаториясенә кердем. Гөлсемне Севастопольгә Инс[титут] мет. физ[ический] леч[ение]гә җибәрдем. Нервлары бик харап булган иде, бәлки, бераз файда алыр, бераз тынычланыр.

Миндә дә хәзер осложнение белән көрәшү бара. Газап өстенә газап, трагедия өстенә трагедия, үлем өстенә үлем – менә бу 4–5 ел эчендә безнең язмыш шуңа әйләнде бит. Барлыгы җыелып, бу ел яз мине тагы җәфалый башладылар. Ләкин үткән тәҗрибә буенча тиз җиңүемә ышанам.

Сәрвәр туганга, Тансыкка сәлам.

Барыгызны да сагынып: Галимҗан. Ялта.

P. S. Адресым элеккечә.

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамовада саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 104–105), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 167–168) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Агиев-Гобәйдуллиннарның Колəхмитов турындагы бозыклыкларын күрсәтеп, мәкалә-тәнкыйть җибәргән идем* – ул мәкаләнең язмышы хакында әйтелде.

## Мәҗит Гафурига[1]

5 ноябрь 1931 ел

Кадерле Мәҗит агай!

Син Сухумга барып чыккансың икән. Мин 1926 нчы елда өч ай анда «Гульрипши» дигән санаторийада яткан идем. Ул шәһәрдән ун чакрымнар чамасы читтә. Зур бер тау буенда агачка бай матур урындадыр. Әмма элек –1914 [ел]да мин шәһәрнең үзендә бүлмә алып тордым. Шәһәр бакчасына каршы җирдә. Мин «Аң»ны ташлагач, зур иҗади дәрт белән шунда барып, «Безнең көннәр»не язып алып кайткан идем, ләкин ул чакта чыгару насыйп булмады, 2 табагы басылгач, цензор туктатты. Гомумән, мин Сухум-каланы яратам, Ялтадан соң ул, әлбәттә, иң яхшы курорт инде. Ләкин иң алдагысы, шиксез, Ялта. Мин уйлыйм, сиңа докторлар Сухумга киңәшләре башка сәбәптән булмас, бары Уфага алынган урыннар эчендә Ялта ул чакта кулларында булмау кебек берәр тышкы хәлдәндер. Ләкин Сухум да бик әйбәт, бик күңелле җир инде. Тик син җирле халык торган уйсу якка барма, анда малярия бик яман була.

Үзем шул Ялтада, шул үзең күргән квартирда, шул ук хәлдә яшәп-дәваланып ятам. Рөстәм вафаты соңында бераз кире киттем, җәй көне авыру көчәйде, ике ай санторийага кереп яттым. Көз килү белән тагы төзәләм инде. Дәрт бик зур булса да, һәммәгезне бик сагынсам да, бу ел җәй кайта алмавым шуннан булды.

Бу ел монда Уфадан күп килделәр. Әле соңгы айларда гына Дәүләтшин Гобәй[2], Афзал Таһир[3], Сарим[4], Амантайлар[5] булды-

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында (б. 55–56), аннан соң «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче санында (б. 173–174) рус теленә тәрҗемәсе, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында оригиналда (Казан, 2000, б. 168–169) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Дәүләтшин Гобәй* – Гобәйдулла Әхмәткирәй улы Дәүләтшин (1893–1938), башкорт совет партия-дәүләт эшлеклесе, язучы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Афзал Таһир* – Афзал Мөхиэтдин улы Таһиров (1890–1938), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[4] *Сарим* – Фәхри Сарим (1900–1933), журналист.

[5] *Амантай* – Габдулла Сахибгәрәй улы Амантаев (1907–1938 яки 1939/1944), башкорт язучысы, филолог. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

лар. Алардан мин синең Ялтага килү ихтималыңны ишетеп, көткән идем. Хәерле булсын!

Мин синең китапларың – тулы җыелмаңны һаман көтәм. Шуның чыгуын ашыктыру чарасын күрмисең бугай. Бәлки, полиграфия ягыннан тыгызлык сәбәптер инде. Чыккач, миңа җибәрергә онытма.

Син 20-сенәчә торам дигәнсең, бу хат, шаять, тапшырылыр. Алгач, озын итеп яз әле. Андый ял иткән чакта вакыт күп була ул.

Гөлсем исән. Ул хәзер, музейны ташлап, техникумда урыс, татар телләре дәресләре бирергә кереште.

Ялтада ризык әйберләре бик кыйммәт. Шулай да дәвалану методларына кимчелек китермәскә тырышып, көрәшеп барам. Хәлем начар түгел.

Сиңа икебездән дә күп сәлам. Нык тазар. Кәефлән. Иҗат көчләрең кайнасын. Теләк шул. Хат яз.

Хуш! Галимҗан – Ялта.<br>1931. 5. XI.

## 1932
## Кави Нәҗмигә[1]

1 февраль 1932 ел

Кадерле Кави!

Сиңа җавап-хат язган идем. Анда сүз арасында гына IV нче том турында әйтеп Ө[лкә] К[омитетына] культпроп Вәлиев иптәшкә телеграм һәм хат язганымны да сөйләгән идем бугай. Чөнки IV нче 1905 [ел] кебек, партиянең көрәш моментларыннан иң җаваплыларының берсенә туктала. Шуңа күрә культпроп[тан] яңадан каратуын үтенгән идем, бер битнең яңадан формулировкасын да җибәрдем. Бәлки, конференция чоры булгангадыр, бу турыда бер дә хәбәр ала алмыйм. Үтенеч шул: син бу турыда культпропка кереп, бер сөйләшеп үтсәнә. Бу момент аеруча кирәк иде. Мәсьәлә ничек тора икән.

Үземнең хәл шул бер төрле бара. Начар түгел. Ләкин суык тидердем бугай, бер ятып, бер торып, кәефсезләнү бар.

Сәрвәр туганга, Тансык батырга күп сәлам.

Сагыну белән Галимҗан.
1. II. 1932 – Ялта.

[1] Төп нөсхә Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында (б. 77), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 170) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Гайшә Шәриповага[1]

1932. 4. II.– Ялта

Кадерле Гайшә иптәш!

Мин якын арада Шамил[2] аркылы Сезнең адресны алдым. Ул ачык язмаган, хатым җитәрме, юкмы, белмим. Җитсә, җавап языгыз, Сезнең белән хатлашып, тәрҗемәләрегез турында сөйләшеп үтәсе берничә мәсьәлә бар. Сез бик кирәкле хезмәт алып барасыз. Китап сайлавыгыз, тәрҗемәнең качествосындагы кайбер моментлар турында Сезгә, бәлки, төрле сүзләр ишетергә туры килә булыр. Ләкин нигез буенча, Сезнең хезмәтегез совет, пролетариат әдәби хәрәкәтендә СССР халыкларының бер-беренә танышуы ягыннан шиксез – бик зур файдалы урын тотарлар. Сез арада минем дә кайбер әсәрләремне чыгардыгыз[3]. Алар хакында да язышасы бар. Шуңа күрә, миңа җавап язып, ачык адресны сорарга кирәк таптым.

Ком[мунистлык] сәлам белән Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 10). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 138), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 170) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Шамил* – сүз язучы Шамил Усманов (Госманов) хакында бара. 1931 елда Г. Шәрипова аның «Кәрим агай» хикәясен рус теленә тәрҗемә итеп, «Татарские рассказы» дигән җыентыкта бастырып чыгара: Усманов Ш. Карим агай / Ш. Усманов // Татарские рассказы. Перевод Гайши Шариповой.– М.: Акц. изд. О-во «Огонёк», 1931.– С. 35–38.

[3] *Сез арада минем дә кайбер әсәрләремне чыгардыгыз* – сүз шушы хакта бара: Ибрагимов Г. Утро в степи. Перевела с татарского Гайша Шарипова // Альманах художественной литературы тюркских народов СССР. Под редакцией И. Н. Бороздина, Али Назима, Н. Васильева-Шубоссини, Уйгура, А. Чачикова и Гайши Шариповой. Вступительная статья И. Н. Бороздина.– Л.: Изд-е «Красной газеты», [1930].– С. 16–18.

## Гайшә Шәриповага[1]

19 февраль 1932 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Бик күп вакытлар үтеп китте. Шуннан бирле Сезгә җавап язу һәр көн иртә-кич күңелемнән чыкмады. Шулай да кичегә барды. Сәбәбен сорамагыз инде.

Сез бик кирәкле берничә мәсьәлә кузгатасыз. Башкалары алдагы хатларга калсын, бу юлы бары берсенә генә тукталам.

Тәрҗемәләрнең качествосы турында дигәнсез.

Минем карашым болай:

Татар теле белән рус теленең структурасында бер-беренә капма-каршы диярлек дәрәҗәдә башкалык, аермалык бар. Шуңа күрә бездә тәрҗемә эшендә төрле тәрҗемәчеләрнең төрле алымнары (прием) булачак. Бездә тәрҗемә эшенең зур киләчәге булганга, бу турыда үзенә күрә төрле «агым»нар туарга мөмкин.

Арада Сезнең тәрҗемә стилендә торкан алымыгызны мин төп нигез буенча туры һәм дөрес дип табам. Менә бу – бер момент.

Сез әсәрдә яки кисәктә булган төп эчтәлекне, баш фабуланы – нигез вакыйганы бозмыйча, җимермичә бирә аласыз. Әсәрнең үзәк фикере, эчке логикасы, факт материаллары Сездә авторныкыча бөтен, тулы чыга. Менә бу – Сезнең тәрҗемәләрнең икенче яхшы, кыйммәтле моменты. Бу әйткән ике момент – Сезнең зур, кадерле уңышларыгыз.

Тагы өченче момент бар. Сез үзегезнең алга алган эшегезгә тоткарлык ясамыйсыз, Сез туктаусыз үсә барасыз. Сезнең эшегез СССР халыкларының үзара танышу-якынлашу процессында бик кирәкле, файдалы, киләчәкле бер эш булганга, мин бу өченче моментка да кагылып үтәргә тиеш табам.

Сез бөтенләй диярлек әдәби (худож[ественный]) тәрҗемәче юлын алдыгыз. Әлбәттә, шулай аерым өлкәне алу – бик яхшы да. Сез беләсез, әдәби әсәрдә художественная деталь, яки кечкенә, нечкә бер намек, яки чак сизелгән бер нәзек оттеноклар була. Болар кайбер урыннарда бик аз, бик кечкенә штрих белән бөтен типны җанландырып җибәрәләр, бөтен вакыйганы яктыртып

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 7). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 138–139), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 171–172) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

куялар, бөтен фикернең, бөтен протсисның мәгънәсен яңа төстә ачып ташлыйлар. Художник-писатель өчен менә мондый кечкенә оттеноклар, намеклар, детальләр, штрихлар урыны-урыны белән бик кыйммәтле рольне уйныйлар. Сездәге өченче момент менә шуңа баглана: Сез менә шул чак сизелә торган кечкенә деталь-оттенок-намек-штрихларны кайбер вакыт аша атлыйсыз, кайбер вакыт шулар Сезнең тәрҗемәдә югалып калалар[1]. Өченче момент дигәнем – шул инде. Әмма Ленинградта басылган альманах өчен ясалган «Казакъ кызы» кисәгендә Сез бу кимчелектән бөтенләй котылгансыз. Сезнең ул кечкенә кисәк тәрҗемәгездә бу өченче момент бөтенләй яхшы җанлы, күңелле бирелгән.

Тәрҗемә качествосы турында хәзергә әйтәчәгем менә шулар. Алда, бәлки, сүз уңае саен конкрет урыннарга тукталырмын.

Гомумән, мин Сезнең эшләрегезнең уңышлы баруы өчен зур теләктәшмен. Әгәр Ялтада торган авыру мөхәррирнең, авыру коммунис[т] язучының кулыннан килә торган булса, мин Сезгә һәртөрле иптәшчә ярдәмләшергә әзер икәнемне әйтеп үтәргә тиеш табам. Чөнки Сезнең хезмәтегезне пролетариат революциясе фронтларыннан берсендә бик кирәкле файдалы хезмәт дип карыйм. Бу зур җаваплы эшкә, нечкә квалификация сорый торган хезмәттә Сезнең кебек кадрлар җитештерүнең җиңел түгел икәнен ачы тәҗрибәләр буенча беләм.

Сәламәт булыгыз, уңыш белән үз хезмәтегездә алга барыгыз. Әгәр отпуска айларыгызда диңгез буйларын күрергә теләсәгез, Ялтага килегез. Хат көтәм.

Иптәшчә сәлам белән: Галимҗан.

1932.19. II. Ялта.

## Якуп Мусанифка
## Мектюб[1]

(Гендисине, чыкъаджкъ Альманахкъа иштирак этмеси огъ-рунда язылгъан мектюбге, Алимджан Ибраимов аркъ[адаш] язгъан къыйметли джевабы)

21 апрель 1932 сәнә

Къыйметли Мусаниф аркъадаш!

Къырым АПП иле бирликде Къырым девлет нешрияты тарафындан чыкъарылаҗакъ альманах ичюн эдебий материал сораб язгъан мектюбинъни алдым.

Бу кунъде санъа ёллайджакъ киби азырленген бир парчам ёкъ, теэссюфге къаршы аджеле тарзда санъа бу арада бир парча да ёлламагъа элимден кельми. Факъат илериде чыкъаджакъ альманахларын ичюн бир парча бере билирим деген дамам бар. Билесинъ, Альм бешсенедир Ялтада тедави олунмакъдаман. Къатты азаплы къоркъунч хасталыгъым магъа Къырым турмушына иштирак этмеге ич бир тюрлю мумкюнлик бермеди, факъат шимди мен артыкъ яваш-яваш селяметленмекдемен, шуньинъле берабер инкъилябнынъ Къырым фронты бильгиси иле аз-аз таныша барам. Мен бунъа къадар партиянынъ Къазан-татаргъа къаратылгъан фронтында чалышдым, бир тамам бунынъле иктифа этмедим. Мен башкъырт массасы турмушындан «Башкъырт къызы Гульбике» һ.б. хикяе яхуд типлер, шойлеликле Къазакъыстан «Къазакъ къызы» киби романлар бердим.

Энди, эгер яхшы селяметлене алсам, бельки, Къырым массасынинъ ерли курешинден ичтимаий турмушындан да белли бир эсер бере билирим деб умют этем. Мен Къырымны пек зияде севдим, Къырым меним ичюн дюньянынъ энъ дюльбер, энъ маналы, энъ дерин дуйгъулар уяткъан янъы эдебий ветаным

---

[1] Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Большевик ёлы» журналының 1932 елгы 6–7 кушма санында (б. 41) кырымтатар телендә, аннан соң татар телендә «Совет әдәбияты» журналының 1967 елгы 3 нче санында (б. 145), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 172–173) урнаштырылган. Текст фотокүчермәдән алынды һәм беренче мәртәбә гамәлдәге кырымтатар хәрефләрендә бастырыла.

*Якуб Мусаниф (1900–1938)* – публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе. Хат язылган вакытларда партия нәшрияты мөдире була.

олуб китди. Меним бу дуйгъуларым – къалемимни Къырым хусусында язмагъа меджбур этелер. Селяметлигим илери кьаргъан сайын мен озюмнинъ бу умютимни амельге кечирюв ичюн чарелер кореджекмен, Къырымнынъ ильмий-эдебий фронтында коммунистлик борджымны эда этмеге тырышаджакъман. Альманахларгъа материал джиберюв иши де иште шу умютлер иле бир сафда тура.

Ком[мунистлик] селямиле: Алимджан Ибраимов.

Ялта, 21 апрель, 1932 с.

## Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмовага[1]

31 июль 1932 ел

Кави, Сәрвәр туганнар!

Байтактан хат-хәбәрегез юк. Кави, синең беренче том күптән чыккан булыр[2] – аны да җибәрмисең. Мин күп сорауларым соңында IV нче том кулъязмасын алдым. Карыйм. Яңарта торган урыннарым бар. Хәзер шунда утырам. Күп тотмый җибәрәчәкмен.

Мәскәүгә күчү[3], «Гарнизон»ны тәмамлау ничек тора?[4]

Хат көтәм. Үзем тазарам, үлчәү һаман арта бара. Миндә хәзер абзый кунак булып ята[5], ай булачак.

Ком[мунистлык] сәлам: Галимҗан.

Ялта, 31. VII. 1932.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 77), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 174) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *…синең беренче томың күптән чыккан булыр* – сүз шушы басма хакында барса кирәк: Nəçmi Q. Xikəjələr / Q. Nəçmi.– Qazan: Tatizdat, 1932.– 336 b.

[3] *Мәскәүгә күчү* – К. Нәҗми Мәскәүгә күченеп китми.

[4] *«Гарниозон»ны тәмамлау ничек тора?* – К. Нәҗми аны егерменче еллар ахырында яза башлый. Соңыннан исеме «Язгы җилләр»гә үзгәртелеп бастырыла: Нәҗми К. Язгы җилләр: Роман / К. Нәҗми.– Казан: Таткосиздат, 1949.– 412 б.

[5] *Миндә хәзер абзый кунак булып ята* – сүз бертуган абзыйсы Шакирҗан хакында бара.

## Мәҗит Гафурига[1]

18 август 1932 ел

Мәҗит агай!

Хатыңны алдым. Ялтага килүең, әлбәттә, бик яхшы.

Мин монда сиңа урын турында чара күрергә дип чыккан идем, Ишемгуловны[2] очраттым. Ул әйтте: «Ике айга табылды», – диде. Сиңа хәбәр иткән булыр. «Беренче сентябрьдән башлана», – диде.

Минем хәлем яхшы. Бу ел нык алга киттем, һичбер төрле кабатлану авыруда булмады.

Үзең киләчәк булганга, шуның белән бетерәм. Хәзергә хуш. Гаиләңә сәлам сөйлә.

Галимҗан.
1932. 18. VIII. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 100), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 174) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Ишемгулов* – Булат Ишемгулов (Габдрахман Закир улы Габдрахманов, 1900–1938), башкорт язучысы. Шәхес чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## Мохтар Ибраһимовка[1]

5 октябрь 1932 ел

Кадерле Мохтар!

Үзеңә, Мөкәррәмәгә[2], Җиһанга[3], Хөснуллага[4] һәм балаларга күп сәлам.

Әйберләр, хатларыгыз тапшырылды. Рәхмәт. Минем хәлне Җиһан сөйләгән булыр. Авыруым кинәтрәк булды. Гадәттән тыш каты, куркыныч төс алып китте, ничә еллар буенча үлем куркынычы баш очымда торды. Хәзер яхшы инде: бу җәй, бу яз бик әйбәт кичтеләр. Инде акрынлап эшләп тә куйгалыйм. Беләсең, күп еллар буенча «Безнең көннәр» трилогиясе минем алдымда тора. Аның беренчесе генә чыкты, инде хәзер нәүбәт калган ике томга җитте. Шулар өстендә акрынлап эшләштерәм, боларга башка «Ялчылар», «Корбан», «Яз килә»[5] дигән кебек берничә кечерәк хикәяләрем бар. Шуларны да кузгатып куйгалыйм. Гомумән, Ялта мине үлемнән алып калды. Мәскәү, Казан совет хөкүмәтләренең туктаусыз ярдәм һәм пенсияләре – бу озак дәвалана алу эшендә миңа нигез шарт булдылар. Соңгы заманда көтелмәгән бер рәвештә Үзбәкстанның да яхшы катнашы булды[6]. Нәтиҗәдә мин инде, аякка басып, баш очымдагы үлемне күз

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 105–106), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 174–176) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Мөкәррәмә* – Мөкәррәмә Гафур кызы Ибраһимова (1892–1970), укытучы-педагог, Мохтар Ибраһимовның (1885–1969) хатыны.

[3] *Җиһан* – Җиһан Гафур кызы Тулунгузина (1896–1973), укытучы-педагог, Г. Ибраһимовның икетуганы (Гыйрфан белән Җиһанның әнисе бертуган). Г. Ибраһимовның икетуганы Габделхак Газизҗан улы Ибраһимов (1905–1980) мәгълүматына күрә, Җиһан әнисенең исеме Өммекамал.

[4] *Хөснулла* – Хөснулла Хәйрулла улы Тулунгузин (1884–1965), укытучы-педагог, Җ. Тулунгузинаның ире.

[5] *«Ялчылар», «Корбан», «Яз килә»* – Г. Ибраһимовның андый хикәяләре бастырылмаган, кулъязмалары да мәгълүм түгел.

[6] *Үзбәкстанның да яхшы катнашы булды* – «Үзбәкстан дәүләт нәшриятының директоры Корбан Биригин 1932 елның июль-август айларында булырга кирәк, Кырымга барып, ял итеп кайтты. Шунда ул, Галимҗан ага Ибраһимов белән очрашып, аның белән утырдаш булган һәм күп мәртәбәләр әдәбият мәсьәләләре турында мөзакәрә кылган. Корбан Биригин, Кырымнан кайткач та, Галимҗан ага Ибраһимовка

алдымнан бераз куа алдым. Бу хәлгә килүемә үзем бик шатмын. 50–60% эш көчем кайтачак, элекке кебек, тәүлегенә 15–20 сәгать эшләп булмас булуын, шулай да материалы җыелган, планы, фикере төзелгән байтак гыйльми-әдәби нәрсәләрне эшли алырга хәлем җитәр дип өмет итәм. Шул өмет өчен яшим, шуның өчен үлемгә каршы сугышам.

Синең белән очрашмаганга күп заман үтте. Ул чакта Олугбәк[1] әле Мөкәррәмәнең кулыннан күп төшми иде. Инде ул хәзер җиткән егет булып бара икән. Әйдә, үссеннәр инде. Киләчәк тормыш алар кулында булачак.

Син Кырымны күргәнең юк бугай. Бер килеп китәргә кирәк. Гаҗәп дәрәҗәдә матур, күңелле бер җир бу! Ялта аеруча гүзәл. Мин СССРның һәммә курорт урыннарында булдым. Ләкин Ялтага җиткәнен тапмадым. Ялта минем өчен икенче ватан булды. Рәхәтләнеп, иркәләнеп яратам бу Ялтаны. Шуңа күрә сине дә Ялтага чакырам. Монда әле хәзерге көндә тамак ягы Ташкенттан ким булыр. Бу як белән кайбер чакларда нык авырлыклар да мөмкин. Ләкин бу, әлбәттә, вакытлы бер хәл генә, бу үтәчәк.

Минем өчен Ялта-Кырым совет-партия органнары нык булышлык иттеләр, итәләр. Дәвалануга моның зур ярдәме тия. Башкаларны Җиһан сөйләп төгәлләр инде[2].

Хәзергә хуш.

Мине сораган дус-ишкә сәлам әйт. Хат яза тор. Җеп өзелмәсен.

Барыгызны сагынып: Галимҗан,
1932. 5. X.– Ялта.

---

ярдәм тарикасында өч мең сум акча җибәрде. Мин ул вакытта Үзбәкстан дәүләт нәшриятының әсаси хезмәтчеләреннән берсе (әдәби тәрҗеман) идем. Миңа Корбан Биригин бик якын булганга, бу эшне ачык беләм. 1962 ел, 21 май». Бу мәгълүматны журналист Сәхи Рәхмәт (1894–1979) А. Шамовка хат белән белдергән.

[1] *Олугбәк* – Олугбәк Мохтар улы Ибраһимов (1916–1979).

[2] *Башкаларны Җиһан сөйләп төгәлләр* – Җ. Тулунгузина 1932 елда (димәк, бу хат язылганнан алда) Ялтада Г. Ибраһимовта кунакта була, хатирә фотосы да бар.

## Мәҗит Гафурига[1]

11 октябрь 1932 ел

Мәҗит агай!

Хатыңны алдым. Сиңа Ялтадан сәлам. Бу арада Мөхәммәт Бикбулат[2] килеп китте. У[л] синдә булган бугай. Ул бик ошады миңа. Бик егет кеше икән. Үзе чын мәгънәсе белән хәзерге совет редакторы булып пешеп җиткәнгә ошый.

Миндә исәннек. Аяк сызлавын бетердем. Шулай да Тубинститут кебек ераграк җиргә чыгарга батырлык итә алмый торам. Сине 19/X да көтәм. Куна кил[3]. Әгәр көне чибәррәк булса, аңарчы үзем дә барырга тырышам.

Хуш. Нык тазар.

Сәлам: Галимҗан.
Ялта
1932. 11. X.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 101), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 176) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Мөхәммәт Бикбулат* – Мөхәммәт Әхмәт улы Бикбулатов (1899–1961), журналист, Уфада татар телендә нәшер ителә торган «Коммуна» (хәзерге «Кызыл таң») газетасының 1932–1938 елларда баш мөхәррире була.

[3] *Куна кил* – ул вакытта М. Гафури Ялтадагы Тубинститутта дәвалануда була.

## Кайбер әдәби мәсьәләләр[1]

Декабрь 1932 ел

Кадерле иптәшләр!

Хатыгызны алдым. Укучылар белән язучы арасында бәйләнеш ничаклы нык барса, һәр ике як өчен шулчаклы файдалы булачак. Шуңа күрә хатыгыз өчен рәхмәттән башка сүзем юк. Ләкин сез минем турыда зур сүзләр әйтәсез, минем аз, кечкенә хезмәтемне бик артык югары күтәрәсез. Белегез, иптәшләр, мин партиянең әдәби фронтында, кулдан килгәнчә, көч җиткәнчә тырышып, эш-көрәш алып барган бер хезмәтчемен. Партиянең әдәби хезмәтчесе дигән сүзне мин – үз Совет илебездә, бөтен җир йөзендә дә капитализмга каршы социализм өчен, Маркс-Ленин байрагы астында эшләп баручысы дигән мәгънәдә аңлыйм. Сез әдәби сәнгать дисез, әдәби техника дисез, мин боларның һәммәсенә капитал коллыгында изелгән дөньяның, хезмәт массасының азатлыгы өчен пролетариат диктатурасы аша коммунизмга бару өчен көрәш фронтының бер коралы дип

[1] Беренче мәртәбә Уфада татар телендә нәшер ителгән «Коммуна» (хәзерге «Кызыл таң») газетасының 1933 елгы 22 октябрь, аннан соң кыскартылып «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче (б. 57–62), «Совет Татарстаны» газетасының 1957 елгы 12 март, «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче санында (б. 175–179) рус телендә, «Язучылык хезмәте турында» дигән китапта (Казан, 1958, б. 121–125), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 5 нче томында (Казан, 1978, б. 520–527), тулы килеш Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 177–186) бастырылган. Текст «Коммуна» газетасыннан тулы килеш алынды.

Хатның төп нөсхәсе хакында «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында (б. 57) болай диелгән: «Журнал редакциясенә Галимҗан Ибраһимовның укучыларга аз билгеле булган бу хатын Сәйфи Кудаш һәм Афзал Кудаш иптәшләр тапшырды». Хәзер аның кайдалыгы, кызганыч ки, билгеле түгел. Язылу датасы да төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелгән. «Совет әдәбияты» журналында һәм «Совет Татарстаны» газетасында «Ялта, декабрь, 1932 ел», әдип «Әсәрләр»енең 9 нчы томында «1932 ел, 23 ноябрь, Ялта» дип куелган. «Коммуна» газетасында исә ул бөтенләй күрсәтелмәгән. Димәк, төп нөсхәнең үз вакытында «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә булуын истә тотып, андагы датаны күрсәтү мәгъкуль күрелде.

Бу хат 1932 елда Башкортстан педагогия институтының тел-әдәбият бүлеге III курс студентлары Афзал Кудашев (1912–1981), Зәйнәп Зөбәирова (1905–1980), Зәкиҗан Локманов (1912–1959) әдәбият мәсьәләләре һәм Г. Ибраһимовның иҗаты хакында үзләрен кызыксындырган сораулар белән әдипкә мөрәҗәгатьләренә җавап итеп язылган.

карыйм. Шунлыктан Г. И. дип, әдип дип зурлаулар минем хәзерге психологиям өчен ничектер бераз ятрак нәрсәләр кебек булып тоелалар.

Инде киләм хатыгыздагы конкрет мәсьәләләргә.

Сез җиде моментны аласыз. Уңайлык өчен, сезнең санау тәртибен үзгәртебрәк, берәм-берәм тукталыйм.

Беренче мәсьәлә. Мин натурализмга каршы. Тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп, дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк. Минемчә, әдәби әсәрләр: тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына социалистик реализмга ирешеп булачак. Бер җидегәнче контрреволюционер качандыр бер заман Уфа «Яңа авыл»[1] гәзетендә «Адәмнәр» турында «Мәргән»[2] дип кул куеп язылган мәкаләсендә шул натурализмны сыларга көчәнгәне исемдә[3]. Бу аның үзенеке түгел. Аңардан күп элек Җамал Вәлиди дә шул фикерне җоттырырга азапланып караган иде[4]. Ләкин татар, рус марксист тәнкыйть мәйданында җидегәнченең[5] дә, Вәлидинең дә ул үрдәге очып китә алмады, җыгылып кире үзләренә төште.

Икенче мәсьәлә: типлар турында.

Җиденче мәсьәлә: хатын-кыз типлары турында.

Бу ике моментка сез сораган дәрәҗәдә киң анализ бирү өчен җавап хаты түгел, том-китап язарга кирәк булачак. Бу хакта рус, татар телләрендә йөздән артык мәкалә язылган. Башкорт те-

---

[1] *«Яңа авыл»* – кара: «Коммуна».

[2] *Мәргән* – Н. Исәнбәтнең әдәби тәхәллүсе.

[3] *«Адәмнәр» турында «Мәргән» дип кул куеп язылган мәкаләсендә шул натурализмны сыларга көчәнгәне исемдә* – мәкалә газета «Башкортстан» дип аталган вакытта бастырыла: Мәргән. Адәмнәр // Башкортстан.– 1924.– 16 гыйнв.

[4] *Аңардан күп элек Җамал Вәлиди дә шул фикерне җоттырырга азапланып караган иде* – Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди арасында әдәбият мәсьәләләре хакында бәхәс беренчесенең шундый мәкаләсе бастырылганнан соң башланып китә: Ибраһимов Г. Тарихи кыңгыравык өзелде (Рәшит бабай үлде) / Г. Ибраһимов // Татарстан хәб.– 1922.– 1 март. Аннары икесенең бер-бер артлы шундый мәкаләләре дөнья күрә: Вәлиди Җ. Әдәби мөсахәбә / Җ. Вәлиди // Татарстан хәб.– 1922.– 5 март; Ибраһимов Г. Аңларга тырышыгыз!! / Г. Ибраһимов // Татарстан хәб.– 1922.– 7 март; Вәлиди Җ. Аңларга тырыштык, аңлый алмадык / Җ. Вәлиди // Татарстан хәб.– 1922.– 10 март; Ибраһимов Г. Татарның соңгы тарихында өч дәвер (Эпоха) («Аңлау юллары») / Г. Ибраһимов // Татарстан хәб.– 1922.– 20 март.

[5] *...җидегәнченең...* – сүз Н. Исәнбәт хакында бара.

лендә дә бөтенләй юк түгел, хәтеремдә яңлыш калмаган булса, Даут Юлтый иптәшнең дә Уфа «Башкортстан» гәзетәсендә Г. И. турында (1928 ел, март 2, № 27) бер анализы булып үткән иде. Бу мәкалә ахырдан «Аймак»та да басылды[1]. Сезнең үз кулыгызга якын булганга, мин моны телгә алдым. Әмма башка җирләрдә гәзет-журнал, русча, татарча аерым мәҗмугаләрдә Г. И. әсәрләрендәге типлар — ир типлары, хатын типлары, яшьләр типлары, эшче типлары, крестьян типлары, тагын әллә нинди типлар турында күп тикшеренеп яздылар. Болар эчендә дөресе дә бар. Ялганы да бар, кирәге, кирәкмәсе дә күп. Бу материалларның кайда басылганлыгы, исемлекләре турында Мәскәү — Комакадемиянең «Литературная энциклопедия»сенең 4 нче томында 384, 385, 386, 387 нче битләрендә кайбер нәрсә бар[2]. Дәхи Казанда 1928 елда русча чыккан «Вестник научного общества татароведение» журналының 8 нче санында[3], шулай ук русча Мәскәүдә, РАПП[4], Фадеев карамагында басылган «Альманах тат[арской] литературы»ның мәҗмугасендә[5] Тарханов тарафыннан язылган сүз башында[6], тагын Казанда Татарстанның унъеллык бәйрә-

---

[1] *Бу мәкалә ахырдан «Аймак»та да басылды* – сүз шушы мәкалә турында бара: Юлтый Д. Ғалимҗан Ибраһимов (20 йыллыҡ әҙәби хеҙмәте айҡанлы) / Д. Юлтый // Башҡорт аймағы.– 1928.– № 6.– Б. 1–7.

*«Аймак»* – Башкортстанны өйрәнү җәмгыятенең фәнни хезмәтләр җыентыгы. 1925 елның октябреннән 1929 елның августына кадәр «Башкорт аймагы», 1930 елның гыйнварыннан 1931 елның августына кадәр янә «Аймак» исеме белән нәшер ителгән.

[2] *Комакадемиянең «Литературная энциклопедия»сенең 4 нче томында 384, 385, 386, 387 нче битләрендә кайбер нәрсә бар* – Аршаруни А. Ибрагимов Галимджан (1887) – современный крупнейший татарский писатель, научный работник и общественный деятель, член РКП(б) / А. Аршаруни // Литературная энциклопедия.– Изд-во коммунистической академии, 1930.– Т. 4.– С. 384–387.

[3] *«Вестник научного общества татароведение» журналының 8 нче санында* – журналның бу саны Г. Ибраһимовның иҗат эшчәнлегенең 20 еллык юбилеена багышлап чыгарылган.

[4] *РАПП* – Российская ассоциация пролетарских писателей, 1925 елның гыйнварында төзелгән совет әдәби оешмасы.

[5] *«Альманах тат[арской] литературы»ның мәҗмугасында* – Альманах татарской литературы. Под ред. татарской секции МАПП. Общая редакция А. Фадеева и Э. Багрицкого. С предисловием О. Тарханова.– М.: Госиздат РСФСР «Московский рабочий», 1930.– 183 с.

[6] *...Тарханов тарафыннан язылган сүз башында* – Тарханов О. О современной татарской литературе / О. Тарханов // Альманах татарской литературы. Под ред. татарской секции МАПП. Общая редакция А. Фадеева и Э. Багрицкого. С предисло-

менә чыгарылган әдәби альманахның ахырында библиография бүлегендә бераз исемлек бар[1]. Боларда төрле фикер, төрле караш үткәрелә. Мин үз турымда булган ул әдәби анализларның кыйммәтенә керешмим, шулай ук күп әсәрләремдә чәчелгән күп типларымны тикшереп торырга да, алда әйтелгәнчә, мондый хатта мөмкин түгел. Мин бу җирдә сезгә бары шуны гына әйтеп үтәргә кирәк табам! Энгельсның әле күптән түгел русча, Мәскәү «Литературное наследие» мәҗмугасендә игълан кылынган мәкаләсеннән алынган ул формула «Типичное обстоятельство, типичные характеры» дигән сүз реализм нигезендәге әдәбиятта, әдәби сәнгатьтә төп лозунга икәнендә шик булырга ярамый. Ансыз әдәбият та юк, әдәби сәнгать тә юк. Ләкин сез ни өчендер ул формуланың Энгельстан алынган икәнен әйтергә онытканcыз. Мин үземнең бөтен әдәби иҗат юлыма – ул формуланы маякларның берсе, ерактан күренә торганы итеп куйганмын. Ымтылыш шуңа. Әмма күпме дәрәҗәдә ирешеп булa – бусына үзем анализга керешә алмыйм, аны тәнкыйтьчеләр тикшерерләр. Кайдан нәрсәләр табарга мөмкин икәнен югарыда әз-мәз күрсәттем.

Алтынчы мәсьәлә: Комсомол турында. Бу сүзегез дөрес. Моны өстемә алам: комсомолның сугыш фронтында һәм хәзерге бөек социализм гигантларында күрсәткән гадәттән тыш зур, чиксез өлкән батырлыклары, ялкынлы көрәшләре минем әсәрләремдә тиешенчә күрсәтелә алганнары юк әле. Ләкин комсомолны бөтенләй язмыйсың диелсә, ул да дөрес түгел булып бетмәс. Эшче, ярлы крестьян яшьләр, укучылар күп бирелә. «Тирән тамырлар»да Мәдинә, курсант Шәяхмәт, үтерелгән Бирәхмәтләр – болар комсомолның алгы сафларына омтылучылар бит. Шулай да ачык әйтәм: алда әсәрләремдә бу моментны тутырасы бар. Хәтергә төшерүегезгә рәхмәт.

Дүртенче мәсьәлә: «Большевик типларның үлүләре, хәтта югалулары», әмма «чит элементларның һәрвакыт тере калулары» турында. Моңа мисал итеп сез «Кызыл чәчәкләр» белән «Тирән тамырлар»ны алгансыз. Әйдәгез, сезнең белән бергәләп, шул

вием О. Тарханова.– М.: Госиздат РСФСР «Московский рабочий», 1930.– С. 14–17.

[1] *Татарстанның унъеллык бәйрәменә чыгарылган әдәби альманахның ахырында библиография бүлегендә бераз исемлек бар* – Un jьl ecndə tatar matur ədəbiatь (1920–1930) / Təzycelərе: Qəvi Nəçmi, Ƣ. Niƣməti, Ƣөmər Ƣəli.– Qazan: Tatizdat. 1930.– B. 454, 468–469.

ике әсәр эченә керик тә, үлгән, тере калган, атылган типларны үз күзебез белән карап чыгыйк.

«Кызыл чәчәкләр»дә чит элемент, актив контрреволюцион бай җегет Гали бармы? Бу тере каламы? Юк. Тере калмый. Колчак җиңелгәч, өмит өзеп, үзен үзе үтерә. Чит элемент Хәлил мулла бармы? Тере каламы? – Юк. Качак булып йөрегән җирдә үлә. Аның остабикәсе акылдан шаша.

Инде әйдәгез «Тирән тамырлар»га керик. Сәнәк фетнәсендә җитәкче чит элемент, күкрәге калайлы, кулак, старшина бармы? Бу тере каламы? Юк. Аны большевик Вильданов крестьяннар алдында аттырып үтертә. Чит элемент, колчакчы ишан Габдулла хәзрәт бармы? Бу тере каламы? Юк. Моны полиграфис[т] метранпаж эшче большевик Гайнетдинов волбашкарманың коймасына терәп, контрреволюционерлыгы өчен атып үтерә.

Тагы кирәкме? Баш «каһарманнар»ның берсе тиречe бай Вәли Хәсәнов чит элементмы? Бу тере каламы? Юк: аны пролетариат революциясенең хөкеме, массаның теләве буенча, караңгы төндә урманга чыгарып аталар, чөнки ул явыз вредитель.

Моңа, иптәшләр, инде нәтиҗәне үзегез чыгарыгыз. «Чит элементлар һәрвакыт тере калалар»мы? Әллә юкмы? Сез бу момент өчен ул китапларны яңадан бер кат карап чыксагыз, зарар итмәссез, дип беләм.

– «Большевикларның югалулары, үлүләре» турында. Бер заманнар бу турыда Уфа – «Октябрь» журналында да бер мәкаләдә шулайрак дип язганнары хәтеремдә. Сезнең хата бер сүз бар. Сез Ленинның «Теория отражения действительности» дигән дөрес, тирән, кыйммәтле сүзен китерәсез. Бу мәсьәләне аңлауда Ленинның ана шул сүзе сезгә бик зур ярдәм бирер. Гражданнар сугышында большевиклар үлдеме, эшчеләр корбан булдымы? Әллә бу үлем тик акларны гына кырып, кызылларга тимәдеме? Беләсез: партия бик зур корбаннар бирде, безнең һәммә фронтларыбыз, һәммә җиңүләребез күп кыйммәтле корбаннар аркылы алынды. Сез мәшһүр коммунист язучы Фадеев иптәшнең «Разгром»[1] атлы, яхшы һәм дөрес язылган әсәрен, әлбәттә, укыгансыз. Монда Левинсон кул астында меңләп партизанлы отряд бар. Каты сугыш соңында күпме кала? «Унтугыз» дигән аерым баб бар. Чөнки бу большевиклар дошманга каршы шулай каты сугышып, фронт ярып чыгалар ки, ахырда барлыгы меңле отрядтан

[1] *«Разгром»* – Фадеев А. Разгром: Роман. 2-е изд. / А. Фадеев.– Л.: Прибой, [1926].– 218 с.

19 (унтугыз) кеше кала. Иптәшләр, фронт авыр булды, партия, эшче-крәстиән күп корбаннар бирде. Әдәбият боларны яшереп калдырсынмыни? Әгәр яшерсә, Ленинның югарыда әйтелгән теориясенә каршы нәрсә биргән булачак. Киресенчә, бу корбаннар, бу газаплар, бу үлемнәр яшь буынны ялкынландыра торган рәвештә кискен тасвирларда күрсәтелергә тиеш. Болар яшьләргә ялкын бирә, болар көрәшкә, сугышка, дошманны җиңгәнчә сугышка чакырып, зур, тирән тәрбия бирәләр. Бу моментны нык уйларга кирәк.

Инде конкрет мисалга – Шаһбазга килик.

Чынын әйтим, Шаһбаз минем өчен язганда да, әле дә кадерле каһарман. Ул ярлы батрак, көтүче крәстиәннән эшчегә әйләнә, нык кискен большевик була. Ул югалдымы? Һич тә юк. Эш шунда гына: Шаһбазның якын дусты Солтан байтак заманнар Шаһбаз турында бер хәбәр белми, аны «югалтып» тора. Хәбәрсез тора. Ләкин бу большевикның бөтенләй югалуы түгел. Китап буенча, аның кайда, ни эшләп йөргәне һәммә укучыга бик мәгълүм: ул контрреволюциягә каршы Ленинградта сугыша, аннан Донда, Кубаньда сугыша. Аннан Кавказда сугыша. Аннан Төркстанга барып сугыша. Басмачылар аның башы өчен алтын вәгъдә кыла. Ул шундый куркыныч кызыл көрәшче була. Ахырда нәрсә? Басмачылар Шаһбазны тотып алалар да, ут ягып, ялкын өстендә газап белән яндырып үтерәләр. 1917–1920 нче елларда мондый ерткычлыклар күп булды. Большевиклар, эшче-крәстиәннәр, совет өчен, Октябрь өчен, социализм өчен күп газап күрделәр, күп кан түктеләр. Башкалар белән бергә татар эшчеләре, татар ярлы-урта-батрак крәстиәннәре дә каһарманча сугыштылар. Газапсыз, үлемсез булмады. Боларны язмаскамы? «Разгром»да Фадеев иптәш[кә] меңнәрчә партизаннарның һәлакәтен язарга мөмкин һәм кирәк булган кебек, татар совет әдәбияты да каты фронтларның каһарманнарын яшермәскә тиешле. Киресенчә, яшь буынны тәрбияләрлек, көрәшкә, сугышка чакырырлык итеп кискен тасвирларда да язарга кирәк. Шулай иткәндә генә әдәбият безгә көрәш коралы була алачак, шулай иткәндә генә безнең әдәбият Ленинның теория отражения действительности принцибы нигезендә үсә алачак.

Өченче мәсьәлә. Революцияне аңлау турында.

Ачык әйтим, сезнең хатта бу мәсьәләнең куелуына мин бераз гаҗәпсендем. Үткән ел Уфада, Башобком органы «Коммуна»[1]

[1] *«Коммуна»* – татар телендә нәшер ителә торган газета Башкортстан Вакытлы

газетендә «Бөек Октябрьнең беренче елларында» дигән мәкалә басылып чыкты (1932 е[л], ноябрь 5, № 328). Бу мәкалә уйлап укыганда авторның буржуазиягә, капитализмга каршы, социализм өчен, коммунизм өчен пролетариат диктатурасы аркылы бару байрагы астында көрәшүе бик ачык күренеп тора ич. Әгәр бу гына җитмәсә, соңгы унбиш ел буенча чыккан мәкаләләрдә дә, публицист китаплардан, тарихи, гыйльми әсәрләреннән авторның Совет өчен, Октябрь өчен, пролетариат революциясе өчен кулыннан килгәнчә сугышып, эшләп барганын ачарлык күп материаллар бар. Теләгән кеше әдәби әсәрләрдән мисал эзләсә, 1920 елны чыккан «Яңа кешеләр»[1] драмасында да массаның совет һәм пролетариат революциясе юлында капитализмны җимерү өчен, социализм өчен, алпавытка, буржуага каршы каты рәхимсез көрәш моментларын табар. Әмма соңгы «Тирән тамырлар»да[2] моны әдәби сурәтләр, вакыйгалар аркылы гына түгел, туп-туры сүз белән: «Пролетариат диктатурасы аркылы коммунизмга бару» дип татарча ап-ачык әйтелгән җирләр дә күп (Беренче басманың 48, икенче басманың 53 нче битләрен карарга мөмкин).

Бу фронтта эшләгәндә кайбер мәсьәләләрдә яңлышулар булды дип куелса, анысы башка мәсьәлә. Анысы революцияне буржуазно-демократическая дип аңлап түгел, бәлки пролетариат революциясе өчен эшләп барганда кайбер аерым тармакларда, аерым конкрет мәсьәләләрдә аяк таю, хатага китү дигән сүз була. Болар булгалап үтте. Ләкин алар да партия оешмасы тарафыннан тиешле карар чыгу белән төзәтү чарасына керешелде. Сезгә, яшь

---

Революцион Советы карары нигезендә Оренбург шәһәрендә оештырыла һәм аның беренче саны 1918 елның 1 мартында «Башкортстан» исеме белән дөнья күрә. 1919 елның 14 сентябрендә газета Башкортстан Совет Республикасы хәрби-революцион комитеты һәм Хәрби комиссариатның сәяси бүлеге органы буларак, Кече Башкортстанның башкаласы Стәрлетамак шәһәрендә «Башкортстан хәбәрләре» исеме астында нәшер ителә башлый. 1922 елның җәендә газета редакциясе Уфа шәһәренә күчерелә һәм 26 ноябрьдән янә «Башкортстан» исеме белән чыгарыла. 1924 елның 22 августында газетаның исеме «Яңа авыл»га, 1929 елның 29 декабрендә «Коммуна»га алыштырыла. Газета 1944 елның 12 мартыннан башлап «Кызыл таң» дип атала.

[1] *1920 елны чыккан «Яңа кешеләр»* – Ибраһимов Г. Яңа кешеләр: Драма өч пәрдәдә (Вакыйга 18–1919 нчы елларда Идел-Урал тупрагында) / Г. Ибраһимов.– Казанда «Өмид» матбагасы, 1920.– 60 б.

[2] *Әмма соңгы «Тирән тамырлар»да* – Ибраһимов Г. Тирән тамырлар (Тугры сүз): Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1928.– 198 б.

большевикларга, пролетариат революциясе белән кайбер аерым конкрет моменттагы яңлышуларны, әлбиттә, ачык аера белергә кирәк. Юкса буталчык чыгачак.

Күптән түгел, Казан «Яңалиф»[1] журналында шундый буржуазный демократик революция дип карау турында бер сүз булып үтте. Ләкин андагы сүз Октябрьгә түгел, 1905 нче ел революциясенә карап әйтелгән. Сез яхшы беләсез, Ленин 1905 нче ел революциясен мөндәриҗәсе буенча буржуазно-демократическая, әмма көрәш методлары буенча пролетарская дип өйрәтә.

Дөньяда төрле революция бар. Революцияләр үзләренең методлары буенча да, мөндәриҗәләре, нәтиҗәләре буенча да бербереннән тирән аерылалар. Бу турыда Ленин, Сталин әсәрләрендә безгә ачык юл күрсәткән урыннар җитәрлек.

Сез «пролетариат революциясеме, әллә буржуазно-демократическиймы» дип аңлау мәсьәләсен куйганда, сүз кайсы революция турында икәнен әйтергә оныткансыз. Сүз 1905 нче ел турында булса, мин бөтене белән Ленинның югары сүзенә кушылам. Әгәр сүз Октябрь революциясе турында булса, мин Октябрьне пролетариат революциясе дип аңлап, пролетариат диктатурасы аркылы коммунизмга бару өчен көрәш фронтында көче җиткәнче, кулыннан килгәнче эшләргә тырышкан коммунистларның берсе инде шунда. Мона Галимҗанны шулай дип белегез.

Бишенче мәсьәлә. Әсәрләрдә партиянең җитәкчелек ролен ничек чагылдыру турында, сүзне кирәк җирдән алгансыз. Совет әдәби хәрәкәтен караганда бу момент, әлбәттә, беренче урында торырга тиеш. Ләкин татарлар да, башкортлар, руслар, башка язучылар да бу зур бурычны тиешенчә үти алганыбыз юк шул әле. Тәҗрибәләр булды, уңышлы чыкканы күп түгел, русчада Исбах[2] («Крушение»)[3], Горбатов[4] («Наш город»)[5] кебекләр бөтенләй начар, уңышсыз чыкты. Либединский[6] да канәгатьләнерлек ача

[1] *«Яңалиф»* – «Яңалиф» җәмгыяте Советының рәсемле иҗтимагый-сәяси, әдәби журнал. 1927 елның февраленнән 1930 елның май аена кадәр нәшер ителгән, барлыгы 14 саны дөнья күргән.

[2] *Исбах* – Исбах Александр (Исаак Абрамович Бахрах) (1904–1977), рус язучысы.

[3] *(«Крушение»)* – Исбах А. Крушение: Повесть / А. Исбах.– М.-Л.: Госиздат, 1930.– 280 с.

[4] *Горбатов* – Борис Леонтьевич Горбатов (1908–1954), рус язучысы.

[5] *«Наш город»* – Горбатов Б. Наш город: Роман / Б. Горбатов.– М.: Госиздат, 1930.– 299 с.

[6] *Либединский* – Юрий Николаевич Либединский (1898–1959), рус язучысы.

алмады. Олы ата Серафимовичның[1] «Железный поток»[2] кебек кыйммәтле әсәрләрендә дә бу момент бөтенләй аз. Панфёровның[3] «Бруски»сы[4], Шолоховның[5] «Тихий Дон»[6] кебек кадерле, зур, яхшы совет романнары да партиянең җитәкчелеген укучыга ачуда тулы нәтиҗә бирә алудан ерак торалар. Бу юлда аеруча уңышлы әсәрләрнең берсе, бәлки, беренчесе Фадеевның «Разгром» атлы китабы булды. Ләкин бу мөхәррир дә икенче романы «Последний из Удегэ»[7] исемле әсәрендә партиянең авангардлык моментын тасвирлауда нык аксый. Гомумән, пролетариат революциясе көрәшләрендә партиябезнең юлбашчылык роле, партия оешмаларының эчке тормышлары, зур кыенлыкларга каршы җиңү моментлары кебек зур җаваплы тема әле бездә тиешенчә югары дәрәҗәдә бөтен тулылыгы белән тасвир кылынып, биреп җителә алган әсәрләр бик-бик азлар. Бу момент коммунис[т] язучылар алдында, әлбиттә, төп нигез, зур бурычларның алдынгысы булып тора. Мин үзем бу турыда күп уйлыйм, күп материал җыям, алдынгы темаларның берсе итеп иҗат механизмасы үзәгенә утыртканмын. Унбиш ел буенча миңа пролетариат революциясе фронтларында өзлексез кайнарга туры килгәнгә, Бөек Октябрьнең беренче елларында революциянең Ленинград, Мәскәү кебек үзәкләрендә, советның үзәк органнарында, партия, совет җитәкчелегенең якын эш системаларында катнашып эшләп үткән бер мөхәррир-коммунис[т] булганга, аннан 1921–1926 нче елларда Казан, Татарстан активы эчендә хезмәт итеп килгәнгә, бу мәсьәләләргә багланышлы бик кыйммәтле материаллар, вакыйгалар дөньяга чыгарга сорап йөриләр. Болар өчен хәзерлек бара. Ләкин болар алдагы көн, киләчәк көн эшләре. Әмма үткән әсәрләрдә бу момент күңелем канәгатьләнә

[1] *Серафимович* – Александр Серафимович (Попов) Серафимович (1863–1949), рус язучысы.

[2] *«Железный поток»* – Серафимович А. Железный поток: Эпопея / А. Серафимович.– М.: Мосполиграф, 1924.– 163 с.

[3] *Панфёров* – Фёдор Иванович Панфёров (1896–1960), рус язучысы.

[4] *«Бруски»* – Панферов Ф. Бруски: Роман / Ф. Панферов.– М.-Л.: Мосполиграф, [1928].– 360 с.

[5] *Шолохов* – Михаил Александрович Шолохов (1905–1984), рус язучысы.

[6] *«Тихий Дон»* – Шолохов М. Тихий Дон: Роман. Кн. 1. / М. Шолохов.– М.-Л.: Мосполиграф, [1928].– 464 с.; Кн. 2.– 1929.– 414 с. (Романның 1932 елга, ягъни бу хат язылганга кадәр 6 басмасы дөнья күрә).

[7] *«Последний из Удегэ»* – Фадеев А. Последний из удэге: Роман / А. Фадеев.– М.: Московский рабочий, 1930.– Ч. 1.– 207 с. (Тәмамланмаган әсәр).

алырлык чагыла алмады. Ләкин бөтенләй юк түгел. Мәсәлән, «Тирән тамырлар»да партия әгъзаларының көрәшләре, партия конференцияләре кебек моментлар бирелде. Шулай да мин үзем болар белән канәгатьләнүдән ерак, күңел тулганчы үтәү алдагы эш планында тора. Мин моны үземә караган дип кенә түгел, бөтен СССРда төрле телләрдә яза торган коммунис[т] язучыларның уртак бурычлары итеп карыйм. Үзем шул зур коллектив эчендә бер хезмәтче булып эшләүне күз алдымда тотам. Өмид шунда.

Куйган җиде мәсьәләгез турында шуның белән сүземне бетерәм. Ләкин, иптәшләр, рөхсәт итегез, мин үз тарафымнан сезгә конкрет, практик бер тәкъдим ясыйм:

– Башпедвуз III нче курс тел-әдәбият бүлеге студентлары эчендә әле күптән түгел Мәскәүдә булып үткән беренче әдәби пленумның бөтен хезмәтләрен, материалларын ныклап тикшереп өйрәнеп чыгарга кирәк!

Моның сәбәбе шул:

Сез, әлбиттә, беләсез, партия Үзәк Комитетының әдәбият мәсьәләсендә 1932 нче ел, 23 апрель карары чыкты. Гадәттән тыш зур әһәмиятле бу тарихи карар безнең әдәби хәрәкәт үсүләребездә бик зур роль уйнады, уйнап бара һәм барачак. Мәскәүдә 1932 нче елның октябрь 29, ноябрьнең 4 арасында бөтен СССР совет язучыларының Оргкомитетының беренче пленумы чакырылып, Үзәк Комитетның 23 нче апрель карары нигезендә зур эш алып барды. Әдәбиятның бик күп мәсьәләләренә яңа нигезләр салынды, зур, мөһим юллар сызылды. Сез боларны, әлбәттә, газетләр аркылы укыгансыз. «Правда»[1], «Известия»дә[2], бигрәк тә «Литературная газета»да[3] тулы докладлар чыкты. Ләкин әдәбият дөньябызда зур яңалыклар тудырган, зур үсүләргә юл ачкан бу карарны, бу пленум хезмәтләрен гәзет мәкаләсе укыган кебек укып үтү һич тә җитми. Сезнең кебек булачак әдәбият специалистларына бу карарның, пленум хезмәтләренең һәр мәсьәләсен аерып алып нечкәләп тикшереп, өйрәнеп үтәргә кирәк.

---

[1] *«Правда»* – В. И. Ленин тарафыннан 1912 елда нигезләнгән, КПСС ҮК органы булган көндәлек газета.

[2] *«Известия»* – СССР Югары Советы тарафыннан чыгарылган көндәлек гомумсәяси газета. Беренче саны Петроградта 1917 елның 28 февралендә (13 мартында) чыга.

[3] *«Литературная газета»* – СССР Язучылар берлеге идарәсе органы, 1929 елның апреленнән чыга.

Программадагы башка дәресләрне тыгызлап, пленум докладларына аерым урын бирергә кирәк. Аеруча Гронскийның[1] карашларына, Кирпотин[2] докладларына, шулай ук Субоцкийга[3] да аерым моментлар калкытып тикшерү тиешле. Һәм башка сөйләүчеләрне дә.

Сезгә моны кат-кат әйтүемнең сәбәбе бар.

Хатыгызның кайбер урыннары бераз гына, кечкенә генә иске әйберләрне хәтергә төшерә. Ягъни партия Үзәк Комитетының 23 апрель карарынча булган, 1932 елгы әдәби пленумгача дәвам иткән кайбер иске хата гадәтләрнең, иске яңлыш методларның ташланып җитмәгәнлеген хәтерләткән чаткылар бар. Мин монда «иске» дигән сүзне революциягәчә дигән мәгънәдә түгел, партия Үзәк Комитетының 1932 ел, апрель карарына һәм 1932 елгы әдәби пленумгача дигән мәгънәдә алам. Мона шул мәгънәдәге кайбер иске яңлышларның чаткыларын бөтенләй кырып, себереп түгеп, яңача әдәби кораллануга минем тәкъдимем ярдәм итәр. Сезгә яңа дөрес көрәш коралы бирер. Сезнең, әлбиттә, хәтерегездә булыр, Сәлах Җамалиев иптәш 1930 нчы ел, 4 октябрьдә чыккан мәкаләсендә[4] Уфа «Коммуна» гәзетендә (№ 118) мона болай язган иде:

«Мәскәүдән килгән РАПП вәкиле иптәш Юрин Исәнбәт турында үзенең докладында[5] «иң оятсыз, иң хәйләкәр, иң пычрак бер интригант», ди. Чынлап та, моны бик күп документлар белән күрсәтергә мөмкин. «ВАПП, җидегәнчеләрне тикшереп... Исәнбәтләрне сөргән вакытында, «Исәнбәтнең ВАППка алы-

---

[1] *Гронскийның* – Иван Михайлович Гронский (чын фамилиясе Федулов (1894–1985), җәмәгать эшлеклесе, журналист, әдәбият белгече. 1931–1934 елларда «Известия ЦИК СССР и ВЦИК»ның баш мөхәррире вазифасын башкара.

[2] *Кирпотин* – Валерий Яковлевич Кирпотин (1898–1997), әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Ул пленумда «Советская литература к XV летию Октября» дигән темага доклад укыган.

[3] *Субоцкий* – Лев Матвеевич Субоцкий (1900–1959), әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Ул пленумда «О ходе реализации решения ЦК АКП(б) от 23 апреля» дигән темага доклад укыган.

[4] *Сәлах Җамалиев иптәш 1930 нчы ел, 4 октябрьдә чыккан мәкаләсендә* – кара: Camalief S. Matur ədəbiət frontьnda kontьr rivalytsiə ojşmasь «çidegəncelər» həm alarnьŋ kөrəşe // S. Camalief // Kommuna.– 1930.– 4 yktəber.

[5] *«Мәскәүдән килгән РАПП вәкиле иптәш Юрин Исәнбәт турында үзенең докладында...»* – кара: Jurin Mix.Ədəbiat frontьnda sьjnfi uyalqnь kөcəjtrgə / Mix. Jurin // Qzьl Tatarstan.– 1930.– 3 sint.

*Юрин Михаил Петрович (1895–1851)* – шагыйрь һәм прозаик.

нуы сәяси хата булган», – дип карар чыгарды[1]. Шулай итеп, Уфа әдәбиятчылары үз араларыннан бер хәйләкәр сәяси йөзе бик ачык булган җидегәнчеләрдән бер контрны тиешле бәясен биреп чыгарып ташладылар», – ди Сәлах Җамалиев, «Коммуна»да мона шулай язды. Бу дөрес сүз икәнен сез яхшы беләсез. Ләкин Исәнбәтләр үзләренең кара сөремнәрен кайбер вакыт кызыл буяу астында таратырга көчәнделәр. Җамалиев иптәш әйткәнчә, җидегәнче, Исәнбәтләрне әдәбиятчылар үз араларыннан чыгарып ташласалар да, кайбер җүешрәк, караңгырак почмакларда, бәлки, шундый кара сөремнәрнең калган булуы мөмкин.

Сез быел III курсны бетерәсез. Сезгә, дөньяга чыгып, партия карары нигезендә мондый сөремнәргә каршы каты көрәшергә туры киләчәк. Мона сезгә шул алдагы көрәшләрегездә иң файдалы коралларның берсе – ана шул Үзәк Комитет карары нигезендә кичкән пленум материаллары булыр. Ул гына түгел, әдәби фронтның һәммә тармагында сезгә ул материаллар нык ярдәмче, яңа җитәкче, яңа корал булыр. Сезгә ныклап аңлатырга, исбат итергә тырышкан конкрет тәкъдимем мона шулар, иптәшләр.

Укуларыгызга, эшләрегезгә уңышлар телим.

Коммунистлык сәлам белән:

Галимҗан Ибраһимов.

[1] *«ВАПП... карар чыгарды»* – кара: Pralitartjat jađьuvsьlarь ojoşmahьnda «jedegənse»lərgə urьn juq // Yktəber. – 1930. – № 9–10. – B. 79.

## Мөхәммәт Бикбулатовка[1]

25 ноябрь 1932 ел

Кадерле Мөхәммәт!

Хатыңны алдым. Мәкаләне укыдым[2]. Басылу техникасы начар түгел. Син, 129 да төзәтмә бирдек[3], дигәнсең. Мин аны тапмадым. «Коммуна»ның ул саны миңа килми калган, югалган булса кирәк. Син аны миңа җибәрергә онытма әле.

Ялта аяз, кояшлы, матур, якты көннәрдән яңгырларга күчте. Берничә көн бик каты салкыннар да булып үтте. Минем үз хәлем яхшы, кәефем төзек, акрынлап эшли баруым күңелне тагы күтәрә, шатлык бирә.

Син гыйнвар 21 – траур көне[4] өчен мәкалә турында әйткәнсең. Ул тема үземнең дә башымнан чыкмый. Инде күп уйлана торгач, Ленин, Сталин турында бөтен бер китап[5] төсенә кертү планы кузгалды. Әгәр күңелем канәгатьләнерлек бернәрсә туса, сиңа, һич булмаганда, шуның үзәк моментларыннан берсен җибәрергә тырышырмын. Ләкин бу кисеп вәгъдә түгел, бу бары теләкне, өметне, дәртне аңлату гына. Янәби[6] дуст ни хәлдә? Аңа сәлам әйт. Мин, бәлки, якын арада сезнең икегез каравына бернәрсә җибәрермен[7] дип торам. Үзегезнең хәл ничек? Октябрь XV еллык бәйрәмгә нинди китаплар чыкты? Берсен дә алганым юк әле.

Сездә әдәбият мәсьәләләре бик нык тикшерелү өстендә булса кирәк: якын арада Башпедвуз. III курс тел-әдәбият факультеты студентларыннан озын хат алдым. Җиде мәсьәлә турын-

[1] Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 107), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 186) бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[2] *Мәкаләне укыдым* – İbrahimof Ƣ. Bөjek Oktəbrneŋ brence jllarьnda (Ytelgən ber basqьc turnda materiallar çiu eşe) / Ƣ. İbrahimof // Kommuna.– 1932.– 5 nojəbr.

[3] *129 да төзәтмә бирдек* – басылмаган булса кирәк.

[4] *…гыйнвар 21 – траур көне* – сүз В. И. Ленин үлгән көн турында бара.

[5] *Ленин, Сталин турында бөтен бер китап* – Г. Ибраһимовның андый китабы басылмаган.

[6] *Янәби* – Төхфәт Янәби (Төхфәтулла Кәлимулла улы Кәлимуллин, 1894–1939), башкорт язучысы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң аклан-ган.

[7] *Сезнең икегез каравына бернәрсә җибәрермен* – газетада андый мәкаләсе юк.

да сүз кузгаталар. Кыскарак җавап язып, Локманов, Зәбирова иптәшләр исеменә 23/XI дә почтага салдым. Анда синең «Коммуна» гәзитәсе дә сүзгә керә, бәлки, алдырып карарсың.

Мәҗит агай ни хәлдә? Авыруы җиңеләйгәндер, әлбәттә. Аңа миннән сәлам әйт. Хат көтәм.

Ком[мунистлык] сәлам белән: Галимҗан.

Ялта, 25. XI. 1932.

## Гайшә Шәриповага[1]

1932.11. XII. Ялта

Кадерле Гайшә!

Сезгә бу хатны бер үтенеч белән язам. Әгәр мөмкин булса, Сез миңа бер-ике табак әйберне татарчадан урысчага тәрҗемә кылып бирегез. Яки, бер сәбәп белән үзегез тәрҗемә итә алмасагыз, аннан үзегез кебек яхшы тәрҗемәче табып бирегез. Мин табагына ике йөз сомнар[2] түләрмен. Бу аз булса, арттырырга мөмкин. Кыен әйберләр түгел, гәзетләрдә басылган мәкаләләр. Җавап көтәм.

Ком[мунистлык] сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.

## Мәҗит Гафурига[3]

1932. 19/ XII

Мәҗит агай!

Синең Мәскәүдән язган хатыңны алган идем. Шуннан соң бер дә хәбәр-хәтерең юк. Ахрысы, Уфага кайту белән эшкә чумдың!

Сәламәтлегең ничек? Кәеф әйбәттер бит? Минем хәлем бик яхшы. Ләкин якын дус-иш арасында үлем күп. Тубинститутта синең заманда яткан Яруновны[4] күмдек. Запевский[5] дигәнне күмдек. Инде тагы безнең язучылар секретаре Сковородников[6] үләргә якын. Тагы башкалар. Ялтада хәлләр искечә. Әмма кыш матур килә.

Иптәшләргә сәлам. Зөһрә[7] иптәшкә күп сәлам: Галимҗан.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 26). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 139), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 188) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Сомнар* – төп нөсхәдә шулай язылган, дөресе: *сумнар.*

[3] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 101), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 188) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[4] *Ярунов* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[5] *Запевский* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[6] *Сковородников* – бу кеше хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[7] *Зөһрә* – Зөһрә Камалетдин кызы Насыйрова (1892–1938), М. Гафуриның хатыны.

## Мөхәммәт Бикбулатовка[1]

26 декабрь 1932 ел

Мөхәммәт!

Миндә исәнлек-саулык. Хатыңны үз вакытында алган идем.

Бернәрсәгә эчем пошып тора: Уфа Башпедвуз III нче курс студентларының сорауларына каршы язып җибәргән җавабым барганнык турында хәбәр-хәтер юк, адрес яңлыш булмадымы дигән шигем бар.

Андагы иптәшләргә, аеруча Мәҗит агайга сәлам әйт. Аның исәнлеге ничек? Нигәдер күптән хаты юк. Хуш!

Ком[мунистлык] сәлам белән: Галимҗан.
1932, 26. XII. Ялта.

P. S. Мәскәү ВЦИК Президиумы тарафыннан миңа тапшырылу өчен якын арада бер документ – Хезмәт Каһарманлыгы турында грамота килгән иде. Шуны декабрь 22 дә Ялта райпрофсоветы миңа рәсми акт белән тапшырды. Фотограф шуңардан бик кечерәйтеп копия ясаган. Бер экземплярын сиңа җибәрәм. Ленин милли сәясәтенең, партия әдәби сәясәтенең ачык конкрет нәтиҗәсе булган мондый вакыйгалар белән таныша тору зыян итми ич!

Г.

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1963 елгы 1 нче санында (б. 114), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 188–189) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Гайшә Шәриповага[1]

28 декабрь 1932 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Хатыгызны алдым. Тәрҗемә өчен планга куелган мәкаләләрдән икесен бу хат белән Сезгә җибәрәм. Боларның, бик кичекми тәрҗемә ителеп, миңа тизлектә кайтарылуларын үтенәм. Җибәрелгән мәкаләләр: 1) «Бөек Октябрьнең беренче елларында», 2) «Әдәби Октябрь».

Шуларга охшаш тагы җибәрәчәк материалларым бар.

Сез миңа Мәскәүдә тәрҗемәнең уртача гонорары турында язгыз. Яки туп-туры үз каравыгыз белән тәрҗемәгә хак куегыз. «Казакъ кызы» басарга кабул ителгән дип яздылар[2]. Үзләре – ГИХЛ[3] – ике тапкыр хәбәр итте. Ләкин договор җибәргәннәре юк әле. Ленинградта чыккан мәҗмугада ул әсәрдән Сезнең тәрҗемә белән кергән кисәкне карадым[4]. Шуның буенча әйтәм: мин үзем «Казакъ кызы» романының тәрҗемәсе Сезгә бирелергә тиеш дип карыйм[5]. Сез үзегезнең тәрҗемәләрегез турында үткән бер хатымда өч моментны хәтерлисездер. Сез инде минем стильгә гадәтләнеп киләсез. Әлбәттә, һәр кеше туктаусыз үсәргә тиеш. Сезнең тәрҗемәдә кай якларны төзәтү хакында мин өченче моментымда әйттем. Мин нык ышанам, Сез тәрҗемәдәге сыйфатны тагы югарырак күтәрәчәксез һәм «К[азакъ] кызы»

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 8). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 139–140), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 189–190) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Бу хакта Г. Ибраһимовның туганнан туган кардәше Мохтар Ибраһимовка 1933 елның 22 февралендә язган хатында да шундый мәгълүмат бар: «Казак кызы» романын урысчага тәрҗемә итеп, бу ел Мәскәүдә басалар».

[3] *ГИХЛ* – Государственное издательство художественной литературы.

[4] *Ленинградта чыккан мәҗмугада* – сүз шушы хакта бара: Ибрагимов Г. Утро в степи. Перевела с татарского Гайша Шарипова // Альманах художественной литературы тюркских народов СССР. Под редакцией И. Н. Бороздина, Али Назима, Н. Васильева-Шубоссини, Уйгура, А. Чачикова и Гайши Шариповой. Вступительная статья И. Н. Бороздина.– Л.: Изд-е «Красной газеты», [1930].– С. 16–18.

[5] *«Казакъ кызы» романының Г. Шәрипова тәрҗемәсендәге рус телендәге басмасы 1934 елда Мәскәүдә нәшер ителә*: Ибрагимов Г. Дочь степи: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1934.– 130 с.

романыннан, әгәр теләсәгез, үрнәк тәрҗемә бирә алачаксыз. Бу турыда Сезгә берничә конкрет ярдәмче материал белән киңәшем бар. «К[азакъ] кызы» тәрҗемәсен алгач, ул турыда аерып күрсәтеп язармын.

Сез ГИХЛда Ерикеев[1] яки Жемчужина[2] иптәшләрне беләсез. «К[азакъ] к[ызы]» тәрҗемәсен Сезгә бирү турында минем теләгемне әйтеп, алар белән сөйләшегез. Җавап язарсыз.

Сәлам белән: Г. Ибраһимов.

1932. 28. XII.

---

[1] *Ерикеев* – Әхмәт Ерикәй (Әхмәт Фазыл улы Ерикиев) (1902–1967), шагыйрь.

[2] *Жемчужина* – шул чорда ГИХЛ хезмәткәре. Аның хакында әлегә мәгълүматыбыз юк.

## 1933
## Мәҗит Гафурига[1]

4 февраль 1933 ел

Мәҗит агай!

Хатыңны алганга байтак булды. Халит[2] куркыныч авырудан котыла алган икән, моның өчен бик шатландым, чөнки шул яшькәчә тәрбияләп үстергәч, баланың кадере-кыйммәте аеруча арта. Зөһрә иптәш өчен бигрәк тә куандым. Аналар йөрәге мондый чакта әйтеп бетерә алмаслык көенүчән булалар.

Үземнең хәл яхшы. Син күргәндәгечә, шул ук шартларда яшим. Үлчәвем һаман да азлап арта тора. Моңа бик куанам. Февральнең дүрте бүген, шуңача кышны аксатмый, кризисламый алып киләм, алда да шулай дәвам итә торса, бик яхшы инде.

Яруновтан соң тагы бер якын иптәшем үлде: Сковородников. Бусы Ленинградтан килгән эшче, коммунист әдип иде. Бик тиз үлеп китте. Инде шул арада Уфа гәзитләре Сарим турында кайгылы хәбәр китерделәр[3]. Казан комвузында укыган чагында, ул миңа бераз шәкерт булды. Үткән ел Ялтада Ливадиягә килгән чагында, миңа кереп, байтак утырган иде. Сурәте әле дә күз алдымда. Сарим инде юктыр дип һичбер төрле башыма сыйдыра алмыйм. Нык үсеп барган коммунист журналист иде ул. Аның турында Гозәирнең язганын яратып укыдым[4].

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 101–102), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 190) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Халит (1919–1935)* – М. Гафуриның икенче улы. Хатларда нишләптер беренче улы Әнвәр (1910–1977) телгә алынмый.

[3] *…Сарим турында кайгылы хәбәр китерделәр* – сүз журналист Сарим Фәхринең (1900 елда туган) 1933 елның 19 гыйнварында үпкә авыруыннан вафаты хакында «Коммуна» газетасының 1933 елгы 24 гыйнвар санында басылган хәбәр хакында бара.

[4] *…Гозәирнең язганын яратып укыдым* – сүз журналист Гыйндулла Мөхәммәтвәли улы Гозәировның (1907–2002) «Коммуна» газетасының 1933 елгы 24 гыйнвар санында басылган «Арабыздан вакытсыз югалган дус һәм иптәш» дип аталган мәкаләсе хакында бара.

Үзеңдә ниләр бар? Хат көтәм синнән. Казанда «Сайланма»ң чыккан икән[1]. Шуны җибәрергә онытма әле. Уфада әсәрләреӊ тулы җыелмасын басу ничек тора?[2] Әле керештеләрме, юкмы?

Уф[а] – Башкортстан мәйданнарында нинди әдәби, шигъри яңа әйберләр чыкты? Һәммәсе турында да иренми яз әле. Күңел тутырып укырлык булсын.

Зөһрә иптәшкә, Халиткә, сораган иптәшләргә күп сәлам әйт.

Исәнлек теләп: Галимҗан.

1933. 4. II.

---

[1] *Казанда «Сайланма»ң чыккан икән* – Ƣafuri M. Sajlanma əsərləre / M. Ƣafuri.– Qazan: Tatgosizdat, 1932.– 252 b.

[2] *Уфада әсәрләреӊ тулы җыелмасын басу ничек тора?* – М. Гафуриның тулы җыелмасы (шигырьләр) Уфада беренче мәртәбә 1934 елда нәшер ителә: Ƣəfүri M. Şiƣьrđar / M. Ƣəfүri.– Өfө: Başgiz, 1934.– 109 b.

## Гайшә Шәриповага[1]

10 февраль 1933 ел

Гайшә иптәш!

Сезгә мин гәзетләрдә татарча басылып чыккан (Октябрь революциясенең XV еллык бәйрәме уңае белән Уфа «Коммуна»[2] һәм Кырым «Яңа дөнья»[3] гәзетләрендәге) ике мәкаләмне урысча тәрҗемә өчен җибәргән идем. Тапшырылганын белдерер өчен открытка да куйган идем. Сездән һичбер хәбәр юк. Хальбуки, Сез тәрҗемә итеп тизлектә җибәрергә вәгъдә иткән идегез.

Җавап көтәм[4].

Сәлам белән: Галимҗан.
Ялта, 1933. 10. II.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 23). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 140), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 191) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Сүз Г. Ибраһимовның «Коммуна» газетасының 1932 елгы 5 ноябрь санында басылган «Бөек Октябрьнең беренче елларында» дигән мәкаләсе хакында бара.

[3] *«Яңа дөнья»* – РКП(б)ның Кырым Өлкә комитеты каршындагы мөселман бюросы органы буларак, 1920 елның 26 ноябреннән 1938 елның 8 июненә кадәр Кырымда Акмәчет (Симферополь) шәһәрендә кырымтатар телендә нәшер ителгән «Еньи дунья» дигән газета. Сүз анда басылган «Әдәби Октябрь» дигән мәкалә хакында бара. Ләкин аның кайсы санда нәшер ителүе турында әлегә мәгълүматыбыз юк.

[4] *Җавап көтәм* – Г. Ибраһимовның 1933 елның 7 апрелендә язган хатын кара.

## Гайшә Шәриповага[1]

21 февраль 1933 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Хатыгызны алдым. Җибәргән китабыгыз һәм мәкалә тәрҗемәсе килде. Һәммәсе өчен дә Сезгә бик рәхмәт.

Бу хатымда бары тик бер практик мәсьәләгә генә туктыйм: «Казакъ кызы»на.

1. «Казакъ кызы» романының Сезгә тапшырылуына мин бик яхшы карыйм. Ышанам, Сез бу әсәрне үрнәк була алырлык рәвештә тәрҗемә итәрсез.

2. Беренче (1924, Мәскәү) басмасында типография яңлышы бик күп. Сез аннан түгел, бәлки Казан-1929-«Яңалиф» басмасы буенча (том 2)[2] тәрҗемә итегез. Сүз башы[3], әлбәттә, керсен.

3. Китапның һичбер җирендә һичбер төрле кыскарту-төшерү ярамый[4]. Тулы тәрҗемә – беренче шарт. Әгәр бу турыда аңлашылмау чыкса – миңа язарсыз.

4. Әсәрдә казакъның специфик моментлары бик күп. Боларны мөмкин кадәрле сакларга кирәк. Сез бу якка аеруча әһәмият бирерсез дип беләм.

5. Китапта Сезгә мәгълүм булмаган бик күп нәрсәләр, сүзләр очрар. Боларны җиңү, аңлау өчен ике нәрсә шарт: а) әлбәттә, шул тәрҗемә вакытында Мәскәүдә берәр укучы-студент казакъ белән танышыгыз. Сүзләрнең мәгънәсен аңлатуда моның кирәге булыр. б) Иске заманда Семенов-Тянь-Шанский редакциясендә чыккан «Россия» атлы зур гыйльми хезмәтнең[5] 19 (XIX) нчы

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 13). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 140–141), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 191–192) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Ƣalimcan İbrahimof əsərləre.– Qazan: Jaŋalif, 1929.– II т.– 470 b.

[3] *Сүз башы…* – алда күрсәтелгән китаптагы әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Галимҗан Нигъмәтинең сүз башы рус телендәге басмага кертелмәгән.

[4] *Китапның һичбер җирендә һичбер төрле кыскарту-төшерү ярамый* – Г. Ибраһимовның бу хакта искәртүе 1935 елның 3 ноябрендә Ә. Ерикәйгә язган хатында да күзәтелә. Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана торган «Глубокие корни» (М., 1931) әсәренең бер нөсхәсеннән күренгәнчә, Г. Шәрипова аны бик җентекләп төзәтеп чыккан.

[5] *Семенов-Тянь-Шанский редакциясендә чыккан «Россия» атлы зур гыйльми хезмәтнең…* – сүз атаклы рус географы П. П. Семенов-Тянь-Шанский (1827–1914)

томында бугай казакълар турында Бөкәйхановның бугай бик кирәкле мәкаләсе бар[1]. Анда барлык бытовое яклар, сүзләрнең урысчасы да, казакъчасы да китерелгән. Бу – Сезгә бик ярдәмче булыр. Бу китап зур гыйльми китапханәләрдә бар. Табарсыз.

Минем әле договор алганым юк.

Хатыгызны көтәм.

Ком[мунистлык] сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.

Ялта 21. II. 1933.

P. S. Мин Сезгә үземнең хатларымнан берсендә «К[азакъ] кызы» тәрҗемәсе турында язып үттем бугай. «К[азакъ] кызы»[2] кисәген телгә алуым шул исемдәге роман уңае белән генәдер.

Г[алимҗан].

---

һәм рус тарихчысы В. И. Ламанскийның (1833–1914) гомуми редакциясендә нәшер ителгән 19 томлык «Россия. Полное географическое описание нашего отечества. Настольная и дорожная книга русских людей» (1899–1914) дигән хезмәтнең Казакъстанга багышланган 17 нче томы (1903) хакында бара.

[1] … *Бөкәйхановның бугай бик кирәкле мәкаләсе бар* – казакъ халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист, этнограф, мәгърифәтче галиме Әлихан Нурмөхәммәт улы Бөкәйхановның (1875–1935) алда күрсәтелгән хезмәттә басылган «Историческая судьба Киргизского края и культурные его успехи» дигән мәкаләсе.

[2] «Казакъ кызы» романы Г. Шәрипова тәрҗемәсендә 1934 елда нәшер ителә: Ибрагимов Г. Дочь степи: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1934.– 130 с.

## Мохтар Ибраһимовка[1]

22 февраль 1933 ел

Мохтар!

Сиңа хат язмаганга байтак булды. Шулай туры килде инде. Үзең дә бик сирәк язасың.

Миндә исәнлек. Элеккечә Ялтада сәла[мә]тлек туплап, заман күтәргәнчә, азрак укып-язып, яшәп киләм. Хәлем яхшы, кәефем урынында. Бу араларда, суык тидереп аз гына чирләп алдым исә дә, ул вакытлы нәрсә булып, үтте.

Мөкәррәмәгә, Җиһанга, Хөснуллага миннән күп сәлам әйт. Җибәргән посылкаларны үз вакытында ала килдем. Алар өчен бик рәхмәт. Туганнарга әллә ничаклы мәшәкать булды инде ул посылкаларны җибәрү. Шулай ук чыгым да булган, әлбәттә.

Солтанмораттан хәбәр алгалыйм. Хәкимнең улы Фирдәвеснең[2] уң кулы параличланган икән, анда, авылда дәвалый алмаганга, шәһәрдә тотарга акчалары булмаганга, монда миңа җибәргәннәр. Фирдәвес хәзер миндә яши, электр белән дәвалыйлар үзен. Бераз гына төзәлә төшкән күренә. Ни булыр инде, әгәр бөтенләй төзәлә алмаса, малайга бәхетсезлек була инде. Мин монда мөмкин чараларның һәммәсен эшләргә тырышам инде.

Ялтада бу ел кыш йомшак. Бер-ике тапкыр аз-маз кар төште дә эреп бетте. Сездә ни хәлләр бар? Озынрак хат языгыз. Анда минем «Тирән тамырлар» үзбәкчә басылып ята дигәннәр иде[3], чыктымы-юкмы, белмим. «Казакъ кызы» романын, урысчага

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 106–107), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 192–193) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *…Хәкимнең улы Фирдәвеснең…* – сүз Г. Ибраһимовның бертуган энесе Габделхәкимнең улы Фирдәвес Ибраһимов (1919–1942) хакында бара. Ул рус теле укытучысы булып эшләгән.

[3] *«Тирән тамырлар» үзбәкчә басылып ята дигәннәр иде* – Г. Ибраһимовның бу романы Абдулла Уразаев (1904–1985 елдан соң) тәрҗемәсендә үзбәк телендә бары тик 1961 елда гына нәшер ителә: Иброҳимов О. Теран томирлар (Ҳақ гап): Роман. Татарчадан Абдулла Ўразаев таржимаси / О. Иброҳимов. – Тошкент: ЎзССР Давлат бадиий адабиёт нашриёти, 1961–275 б.

тәрҗемә итеп, бу ел Мәскәүдә басалар[1]. Якын арада бу турыда хәбәр алдым.

Хәзергә хуш. Балаларга, мине сораганнарга сәлам әйт.

Сагынулы сәлам белән: Галимҗан.

1933. 22. II. Ялта.

P. S. Сиңа бер документның копиясен җибәрәм[2].

Г.

---

[1] *«Казакъ кызы» романын, урысчага тәрҗемә итеп, бу ел Мәскәүдә басалар* – инде бер әйтелгәнчә, «Казакъ кызы» романы рус телендә 1933 елда түгел, ә 1934 елда басыла.

[2] *Сиңа бер документның копиясен җибәрәм* – сүз Г. Ибраһимовның Хезмәт Батыры грамотасының күчермәсе турында барса кирәк.

## Гайшә Шәриповага[1]

1 апрель 1933 ел

Гайшә иптәш!

Сезгә булган бурычымны һичбер минут хәтердән чыгарганым юк. Ләкин алачак гонорарларымны ала алмый торганга җибәрә алмадым. Калганын тагы шулай бурычларымны алу белән җибәрермен.

Сәлам белән: Г. Ибраһимов.
1933. 2. IV. Ялта.

## Гайшә Шәриповага[2]

7 апрель 1933 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Җибәргән хатларыгыз белән бергә тәрҗемә-мәкаләләрне алдым[3]. Тәрҗемә өчен тиешле ике йөз сомны[4] Сезгә тизрәк җибәрү – һәр көн хәтеремдә тора. Ләкин алачагым булган нәшрият һәм башка учреждениеләр бирми – түли алмый торалар. Шулар кулымны бәйли. Шуның аркасында һаман кичегә. Беренче мөмкинлек булу белән көнен-сәгатен җибәрәчәкмен.

ГИХЛдән бу арада хәбәр юк. Якын арада Мәскәүгә китәчәк иптәшләр бар. Бәлки, шулар белешеп кайтырлар.

Сәлам белән: Галимҗан.
1933. 7. IV. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 30). Акча күчерү талонына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 193–194) бастырылган. Анда 9 апрель дип ялгыш куелган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Талонның икенче ягында шулай язылган: «Талон к переводу по почте на сто руб.– коп. от Галимджана Ибрагимова. Адрес Ялта ул. Халтурина, № 5. Ялта почтасы мөһерендәге число: 2. 6. 33».

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 22). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 193) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва 53 Скорняжный пер. д. 9, кв. 5 Тов. Гайше Шариповой».

[3] *...тәрҗемә-мәкаләләрне алдым* – сүз алда әйтелгән «Бөек Октябрьнең беренче елларында» һәм «Әдәби Октябрь» дип аталган мәкаләләр хакында бара.

[4] *Сомны* – төп нөсхәдә шулай язылган, дөресе: *сумны*.

## Мәҗит Гафурига[1]

14 апрель 1933 ел

Кадерле Мәҗит агай!

Хатыңны алдым. Җибәргән китапларың килеп җитмәделәр әле. Юлда булырлар.

Синең Казанда басылган «Сайланма»ңны миңа үз вакытында җибәргәннәр иде[2]. Бераз вакыт элек аның турында бер тәкъриз[3] язып, Казанга юллаган идем. Ибрай Газидан[4] аны «Бөек чор»[5] журналының (элекке «Атака» урынына чыга башлаган яңа журнал) 3 нче санына керәчәк, дип җавап алдым[6]. Бу журнал синең үзеңә килми булыр, син № 3 не андагы иптәшләрдән таптырып, алып укы әле. Гомерем буенча синең турыда киңәеп, рәхәтләнеп бер язарга туры килә алмады. Бу тәкъриз дә кыска, шулай да зур мәкаләне көткәнче дип, хәзергә шуны яздым әле.

Күргәнсеңдер, Мәскәү урысча «Литературная газета»ның 5 нче апрель, 1933, № 16, татар әдәбиятына каратып, аерым, 2 нче битен багышлады[7]. Бик яхшы мәкаләләр бар, татар совет

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында (б. 56), аннан соң «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче санында (б. 174) рус телендә, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 194–195) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Синең Казанда басылган «Сайланма»ңны миңа үз вакытында җибәргәннәр иде* – Ƣafuri M. Sajlanma əsərləre / M. Ƣafuri.– Qazan: Tatgosizdat, 1932.– 252 b.

[3] *Тәкъриз* – бәяләмә.

[4] *Ибрай Гази* – сүз Ибраһим Гази хакында бара.

[5] *«Бөек чор»* – дөресе: «Яңа чор» һәм ул 1933 елның гыйнварыннан Казанда барлыгы ике саны чыккан әдәби, сәяси, сәнгать журналы. И. Гази аның җаваплы мөхәррире була.

[6] *Бераз вакыт элек аның турында бер тәкъриз язып, Казанга юллаган идем. Ибрай Газидан аны «Бөек чор» журналының (элекке «Атака» урынына чыга башлаган яңа журнал) 3 нче санына керәчәк, дип җавап алдым* – Г. Ибраһимовның ул бәяләмәсе басыла: İbrahimof Ƣ. Qart şagirneŋ jaxşь sajlanmasь / Ƣ. İbrahimof // Sovet ədəbiatь.– 1933.– № 2–3.– B. 116–117.

[7] *«Литературная газета»ның 5 нче апрель, 1933, № 16, татар әдәбиятына каратып, аерым, 2 нче битен багышлады* – анда Б. Абдуллинның «За большевизацию художественной литературы Татарии»; М. Ягудинның «Литература Советской Татарии к новым успехам»; К. Нәҗминең «Усилим классовую бдительность» дигән мәкаләләре; Г. Ибраһимовның иҗаты хакында кыска белешмә белән аның «Тирән тамырлар» романыннан «Черное и красное» исеме белән өзек; Х. Туфанның А. Ча-

язучыларының һәммәсе диярлек телгә алынып үтелгәннәр. Әгәр күрмәгән булсаң, алдырып кара, чөнки урысча совет матбугат битендә татар әдәби хәрәкәтенең болай тулы, яхшы чагыл[уы], әлбәттә, бик зур, файдалы эш. Чөнки бу СССР халыклары арасында туганлык җепләрен сузуга ярдәм итә.

Минем хәл шул син күргәнчә, яхшы барды. Гыйнвар беткәнче, үлчәвем дә арта торды, ләкин февраль-март айлары бик кәефсез үтте, апрель башында уң як кабыргада – элекке урында туберкулез шеше калыкты, бер атна бик газаплады – аннан соң докторлар ярдылар, хәзер менә шул җәфа белән авырыбрак өйдә ятам. Инде кризисы үтте, хәзер төзәлү башланды. Мин, әлбәттә, бу фронтны тиз ликвидировать итәчәкмен. Шулай да бу миңа бер куркыныч, бер җәфа, бер мәшәкать булып кичте. Инде хәзер аны җиңеп менә барам. Туберкулез дигән каһәрнең адәмгә тынгы бирмәве менә шундый була икән.

Мәскәү-Казан-Уфа якларына, үзебезнең Солтанморат, «Урак» колхозына таба да кайтып килү беренче планымда тора.

Бик сагындым инде. Алты ел тула бит! Тик котым очып торам: бу яңа осложнение – яңа фронтның ликвидациясе сузылып, юлга чыгуга киртә була күрмәсен инде. Синең кымызга бару планың, әлбәттә, бик әйбәт. Син бәхетле кеше, сиңа кымыз ярый. Менә миңа бит, кан килүгә мәел булганга – кымыз ярамый. Кымыз эчә алсам, минем кан составы бик тиз яңарыр иде. Ләкин ярамый.

Сиңа тазару теләп калам.

Зөһрә иптәшкә, Халиткә күп сәлам әйт. Мине сораган иптәшләргә сәлам сөйләрсең.

Сагынып: Галимҗан.
1933. 14. IV. Ялта.

---

чиков тәрҗемәсендә «Ванька» дигән шигыре бастырылган.

Ш. Камал, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, Т. Гыйззәт, К. Тинчурин, Х. Туфан, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Әмир, Татарстан Совет язучылары союзы оештыру комитеты рәисе Г. Ризвановларның фотолары урнаштырылган.

Яхшы пьесаларга конкурс игълан ителү уңае белән Ш. Камал, Ф. Сәйфи-Казанлы, Зөлкарнәевләр анда катнашачаклары турында белдерү белән чыкканнар.

*Бари Абдулла улы Абдуллин (1899–1937)* – дәүләт эшлеклесе; ул вакытта ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре була. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

*Мидхәт Абайдулла улы Яһүдин (1904–1982)* – дәүләт эшлеклесе; ул вакытта ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты рәисе була.

## Гайшә Шәриповага[1]

15 апрель 1933 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Хатыгызны алдым. «Казакъ кызы»ның Ф. К[2]. тәрҗемәгә бирелүенә ышанып җитү дә авыр. Шулай да мин ГИХЛга һәм Агишка[3] хат язып әйттем: аңа бирмәгез, ул «татар-төрек» телендә оста яза, әмма урысчада юк дидем, тәҗрибәле кешегә бирергә куштым. Сез миңа исем-фамилиясен ачык куеп, ГИХЛ-татар бүлегендә кем эшләвен белдерегез.

Җавап көтәм.

Сәлам: Галимҗан – Ялта.
1933. 15. IV.

## Мәҗит Гафурига[4]

Мәҗит агай! 1933. 10.V.

Хатыңны алдым. Китапларың килде. Рәхмәт.

Башта ук ачык әйтим, мин[ем] май 20 гә чаклы Уфага барып өлгерү ихтималым юк. Моңа авыруымның хәзерге дәрәҗәсе ирек бирми. Мөмкин була калып, Уфага бара алсам, синең белән очрашу ягы, әлбәттә, җиңел эш: син бит шул Агыйдел, Дим буеннан ерак китмисең инде.

Синнән бер үтенеч: мин өч атна элек Гозәиров Батырга[5] Башгиз аркылы телеграм белән сары май өчен 125 сом акча салган идем. Һичбер хәбәр юк. Май бик кирәк. Син шуны белешеп миңа ике сүз яза күр әле. Зөһрә иптәшкә, Халиткә сәлам.

Галимҗан.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 24). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 141), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 195) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Ф. К.* – сүз Фатыйх Кәрими хакында бара. 1925 елдан Мәскәүдә СССР халыклары Үзәк нәшриятында тәрҗемәче булып эшли. Бу очракта аның социаль чыгышы да берникадәр роль уйнагандыр.

[3] *Агиш* – сүз Фәхрелислам Агиев хакында бара.

[4] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 102), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 196) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[5] *Гозәеров Батырга* – Батыр Мөхәммәтвәли улы Гозәеров (1896–1983), нәшрият эшчесе, Г. Ибраһимовның якын танышы.

## Гайшә Шәриповага[1]

1933. 25. X. Ялта

Кадерле Гайшә иптәш!

Ялтага исән-сау кайттым[2]. Бу хатны тәрҗемә эшенә карата язам. Рябинина иптәш Сезнең белән договорны ашыктырмакчы, эшкә башлауны тизләтмәкче иде[3]. Сез инде мин әйткән урысча китапны[4] тизлектә табып күздән кичерә күрегез. Башкача уңайсызлык чыкса, миңа хәбәр итегез. Һичбер яктан тоткарлык булмаска тиеш.

Сез анда «Татар хатыны [ниләр күрми]» тәрҗемәсе[5] турында әйткән идегез. Бу эш тәмам булсын. Моны бетергәч, аңа күчәрбез. Барысы берьюлы килеп тыгылмасын.

Бу хатны алгач, «К[азакъ] кызы» тәрҗемә эшенең ни чамада торганын ачык әйтеп языгыз.

Сәлам белән: Г. Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[a] – 19). Ачык хат карточкасына язылган. Дата 29 октябрь дип ялгыш куелган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 141), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 203) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Ялтага исән-сау кайттым* – Г. Ибраһимов 1933 елның көзендә Татарстан хезмәт ияләренең чакыруы буенча Казанда булып, 1 октябрьдә колхозчы-ударникларның икенче съездында чыгыш ясый. Сүз шуннан әйләнеп кайту хакында бара.

[3] *…эшкә башлауны тизләтмәкче иде* – Г. Ибраһимов Казаннан Ялтага кайтышлый Мәскәүдә туктала һәм ГИХЛга кереп, «Казакъ кызы» романын рус теленә тәрҗемә итү эшен Г. Шәриповага тапшыру өчен А. П. Рябинина белән сөйләшеп хәл итә.

[4] *…урысча китапны…* – сүз П. П. Семенов-Тянь-Шанский һәм В. И. Ламанскийның гомуми редакциясендә нәшер ителгән 19 томлык «Россия. Полное географическое описание нашего отечества. Настольная и дорожная книга русских людей» (1899–1914) хезмәте хакында бара.

[5] *«Татар хатыны [ниләр күрми]» тәрҗемәсе…* – Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре (1910) 1935 елда Мәскәүдә Г. Шәрипова тәрҗемәсендә «Татарка» исеме белән нәшер ителә: Ибрагимов Г. Татарка: Роман / Перевод с татарского Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: Гос. изд-во «Художественная литература», 1935.– 174 с.

## Мәҗит Гафурига[1]

18 ноябрь 1933 ел

Кадерле Мәҗит агай!

Синнән хат-хәбәр алмаганга да, үзем язмаганга да бик күп вакытлар үтеп китте. Көтмәгәндә зур сәяхәт ясап алдым. Аннан кайткач, санаторийага урынлашу эше белән мәшгуль булдым. Шулай хатым кичекте дә кичекте. Бу арада Гали Исхак[2] кереп чыккан иде, синең турыда озак сөйләшеп утырдык. Ул синең сәламәтлегеңнең яхшыра баруын әйтте. Бу мәктүпне шуның шатлыгы астында язам.

Үземнең кәеф начар түгел. Күңел күтәренке чак. Беләсең, Казанга, Мәскәүгә йөреп кайттым. Ударник-колхозчылар съездына чакырылган идем, ул бик күп материал бирде. Казанда, Татарстандагы төзелешләр, мин күптән күргән колхозлар («Арча» районына бардым) минем күңелне бик күтәрделәр. Гомумән, Казан, Татарстан бик нык үзгәргән, танымаслык булган. Докторлар минем сәфәргә каршы булганнар иде. Алай зарар килмәде. Үпкә хәзер нык табыла, бу ягы бик шатлыклы. Бары тик плевритта авыру бар. Шуның сәбәбеннән хәзер «Пирогов санаторийасы»на кердем. Квартирамда Кавиларны калдырдым. Үзем барып киләм.

Шулай итеп, Мәҗит агай, аз-маз эшләгән хәлдә, авыруга каршы көрәшне дәвам иттерәбез инде. Бөтенләй бетеп җитмәвенә ачу килә килүен, шулай да үлем якасыннан ычкынып, хәзерге хәлгә килүгә дә шатланасың.

Зөһрә иптәшкә, Халиткә күп сәлам.

Үзеңә исәнлек һәм эшләреңә уңыш телим: Галимҗан.

1933. 18. XI.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә.А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче (б. 57), аннан соң «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче (б. 174–175) саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 203–204) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Гали Исхак* – Гали Исхаков (1885–1959), Уфада эшләгән полиграфия эшчесе, М. Гафуриның якын дусларыннан берсе.

## Гайшә Шәриповага[1]

2 декабрь 1933 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Сезне «Казакъ кызы» өстендә эшлисездер дип беләм. Мәскәүдән килгән телеграм миңа шулай хәбәр бирде, договор төзелде, диде[2].

Тәрҗемәләрдән зарлану бер модага кереп китте, ләкин мин ышанам, Сез инде үрнәк бер тәрҗемә бирерсез. Чөнки үзегез бу әсәрне эшләргә күптән тели идегез. Ничек, мин әйткән әсәрләрне – урысчада казакъ тормышына караган зур хезмәтләрне таптыгызмы? Яңа язучыларның казакъ, кыргыз турында урысча әсәрләре чыкты – һәммәсе Сезгә ярдәм итәрләр. Мин кабатларга мәҗбүрмен: Сезгә кайбер сүзләрне, җөмләләрне дөрес бирү өчен, әлбәттә, казакъ иптәшләрдән берәрсе белән танышу-файдалану кирәк булыр. Эше бик тыгыз булмаса, бәлки, Мокaнов[3] иптәш ярдәм күрсәтер. Кирәк урында, алдан карап, миннән сорарсыз.

Сез тәрҗемәләрегездә фактларны, вакыйгаларны дөрес бирәсез. Ләкин кечкенә детальләр калгалап куйган урыннар бар. Әдәби тәрҗемәдә бу бик кирәк. Ленинград мәҗмугасында чыккан кисәк[4] – Сезнең тәрҗемә – миңа ошаган иде. Ышанам, Сез бөтен әсәрне шулай яхшы эшләрсез. Бу якларга нык тукталуым шуның өчен: бу әсәрне яраталар, бу – бер. Күп талаш белән элеккe тәрҗемәне ташлаттык. Инде нык әһәмият бирү шуннан килә.

Җавап көтәм: Галимҗан.

1933. 4. XII. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 9). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 141–142), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 204–205) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Бу Г. Ибраһимов Мәскәүдә ГИХЛда Рябинина белән шәхси очрашып сөйләшү нәтиҗәсе булса кирәк. Телеграмма аңардан булырга тиеш.

[3] *Мокaнов* – Сабит Мокан улы Мокaнов (1900–1973), казакъ халкының күренекле язучысы, җәмәгать эшлеклесе, Казакъстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы. Ул вакытта Мәскәүдә Кызыл профессура институтында укый. Аның белән Г. Ибраһимов беренче мәртәбә 1932 елда «Националь» кунакханәсендә казакъ совет әдәбиятын нигезләүчеләрнең берсе Сәкен (Сәгъдевәккас) Сәйфуллин (1894–1938) янында таныша.

[4] Сүз шушы хакта бара: Ибрагимов Г. Утро в степи. Перевела с татарского Гайша Шарипова // Альманах художественной литературы тюркских народов СССР. Под редакцией И. Н. Бороздина, Али Назима, Н. Васильева-Шубоссини, Уйгура, А. Чачикова и Гайши Шариповой. Вступительная статья И. Н. Бороздина. – Л.: Изд-е «Красной газеты», [1930]. – С. 16–18.

## Гайшә Шәриповага[1]

17 декабрь 1933 ел

Гайшә иптәш!

Мин ГИХЛдан хат алдым. Алар, Сезнең белән договор ясадык, диләр. Әсәр күптән Сездә тәрҗемәдә дип әйтәләр. Сездән һичбер хәбәр юк. Вакыт бик аз калып бара. Әлбәттә, күргәнсез булыр, «Лит[ература] газ[ета]»да «К[азакъ] кызы» романы съездга чыга торган китаплар эчендә саналды[2]. Ашык-пошык чыгарырга туры килмәсен өчен, Сез алдан һәммә турыда минем белән хәбәрләшә барыгыз. Юкса тагы бер тоткарлыкка очрар.

Эшегездә уңыш телим: Галимҗан.

Ялта. 1933. 17. XII.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 25). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 142), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 205) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай язылган: «Москва – 53, Скорняжный пер. д. 9, кв. 2 Тов. Г. Шариповой». Хатны җибәрү почтасы мөһерендә «Массандра Крым 17. 12. 33, Мәскәү почтасы мөһерендә «Москва 53 Сокольнический 20. 12. 33. 21 час» дип куелган.

[2] *«Лит[ературная] газ[ета]»да «К[азакъ] кызы» романы съездга чыга торган китаплар эчендә саналды…* – дөрестән дә, «Литературная газета»ның 1933 елгы 29 ноябрь санында «В крупнейшем издательстве художественной литературы» дигән белешмәдә болай диелгән: «К съезду выйдут также: большой роман башкирского писателя С. Тагирова «Солдаты», роман татарского писателя Ибрагимова «Дочь казака»…».

## 1934
## Гайшә Шәриповага[1]

1 февраль 1934 ел

Кадерле Гайшә иптәш!

Хатыгызны алганга күп вакыт үтте, җавабым кичекте, гафу итегез.

Минем плевритта каты осложнение булды, шул сәбәпле Ялта хирургия больницасына керергә туры килде.

Сезнең хакта бик яхшы бер момент – казакъ иптәшләр белән мөнәсәбәткә керүегездер[2]. Әгәр алар ярдәм итсәләр, тәрҗемәнең яхшыруына шиксез зур өмет арта. Сабит Муканов иптәшкә минем чын күңелдән сәламемне әйтегез. Һәм аның бу эшкә ярдәмен өмет итүемне белдерегез.

Сез миңа шул арада тәрҗемәләрдән 5–10 бит җибәрегез, ятқан җирдән акрынлап карармын.

Сезнең тәрҗемәне урыс стилисты карап чыгарга тиеш иде, ул ничек тора?

ГИХЛ белән сөйләшеп, бу турыда да миңа бер сүз әйтегез.

Гомумән китапның съездга чыгуы[3] өчен бөтен чараны күрергә кирәк.

Бу турыда Сезгә бик күп эш баглана.

Җавап көтеп калам: Галимҗан.
1934. 1. II.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 11). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 142), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 206) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *...казакъ иптәшләр белән мөнәсәбәткә керүегездер* – сүз Г. Шәрипованың ул вакытта Мәскәүдә яшәгән казакъ язучылары С. Муканов, С. Сәйфуллин белән бәйләнешкә керүе хакында бара.

[3] *… китапның съездга чыгуы…* – сүз «Казакъ кызы» романының рус теленә тәрҗемәсе совет язучыларының 1934 елның 17 августыннан 1 сентябренә кадәр эшләгән Беренче Бөтенсоюз съезды ачылуга өлгертү кирәклеге хакында бара. Әсәр типографиягә җыярга 1934 елның 21 маенда, ә басарга 1934 елның 9 июнендә тапшырыла.

## Гайшә Шәриповага[1]

1934. 28. II

Гайшә иптәш!

Хатыгызны, 22 бит тәрҗемәгезне алдым[2]. Ләкин мин һаман больницадамын. Бик ябыгып, бик хәлсезмен. Укып, отзыв-оценка бирә алырга көчем юк. Беренче битне карадым. Өч замечание:

1 – эпиграф-стихны[3] бөтенләй ташлагыз, ул кермәсен;

2 – беренче, икенче битләрдә китапның исеменнән соң: «Из жизни дореволюционного Казакстана»[4] дип куегыз;

3 – беренче фраза начар төзелгән, шуны, әлбәттә, төзәтегез.

Хәзер мәсьәлә болай куела:

Мин үзем карап чыгып оценка бирүгә авыруым ирек бирмәгәнгә, хәзер бөтен җаваплылыкны тәрҗемәчегә һәм ГИХ[Лга] тапшырам. Минем карарга физически мөмкинлегем юк. Һәм минем тарафтан ахырдан претензия булмас. Җавап көтәм: Галимҗан.

98 нче биттәге шигырьнең мәгънәсе болай:

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 16). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 143), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 206–207) бастырылган. Томда дата 22 февраль дип ялгыш куелган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Конверт тышында адресат шулай язылган: «Москва, 10, Скорняжный переул. 9, кв. 5 т. Гайше Шариповой»; Г. Ибраһимовның адресы: «Ялта, у. Халтурина 5, Г. Ибрагимов». Конвертның өске өлешендә бер штемпельдә 574 саны куелган, икенчесендә «Спешная почта» дип язылган.

Ялта почтасының мөһере кисеп алынган. Мәскәүдәге почта мөһерендә «Москва 53, Сокольничный 3. 3. 34. 21 час.» дип куелган.

[2] *22 бит тәрҗемәгезне алдым* – сүз «Казакъ кызы» романының рус теленә тәрҗемәсе хакында бара.

[3] *Эпиграф-стихны...* – сүз оригиналда бер казакъ шагыйренең эпиграф итеп китерелгән әсәрен русча тәрҗемәдә төшереп калдыру кирәклеге хакында бара. Г. Ибраһимов әсәрләренең 1929 елда нәшер ителгән икенче томында (5 бит) шигырь шулай:

Kiŋ dala, kyrəseŋ, oꞁuj, anav çatqan,
Çebektəj çasel ceptə biten çaqqan.
Asqar tav, baldaj tatlь suvlarь bar,
Ana şul anam ide mine tapqan.

[4] *«Из жизни дореволюционного Казакстана»* – бу фраза русча басманың аннотациясендә куелган.

Атның яхшысын сорасаң – Андижан, Хукандадыр,
Ирнең яхшысын сорасаң – Кырым белән Казандадыр,
Тунның яхшысын киярсең Хива белән Бохарада[1].

Мондый урыннар булса, казакъ иптәшләрдән сорарга кирәк. Тәрҗемә бөтен бирелсен, кыскарту ярамый.

[1] Г. Ибраһимов әсәрләренең 1929 елда нәшер ителгән икенче томында ул казакъ шигыре шулай (б. 98):

At çaqsьjsьn sorasaŋ, Andiçan min Quqanda,
Ir çaqsьjsьn kyrəsən, Qьrьjm minən Qazanda,
Tun çaqsьjsьn kijərsin Xьjva minən Boxarada.

## Кави Нәҗмигә[1]

1934. 8. IV. Ялта

Кадерле Кави!

Хатым бик кыска булыр. Чөнки һаман да больницадан язам. Ләкин тиздән чыгармын дип өметләнәм.

Синең хатыңның озын булуы күңелне тутырды, сиңа карата йөрәктә җыелган әче сүзләр коелдылар.

Антология өчен яхшы рәсем дигәнсең. 1932 нче елда Ялтада Мәҗитләр белән төшкәннән кисеп җибәрәм. Бу – минем тазарган чагымда алынган иде. 1934 нче елның ахырында тагы шул хәлгә кайтачакмын.

Сәрвәргә бик рәхмәт һәм сәлам, мамык тапшырылды. Телеграмың килде. Ялтада яз, кояш. Хуш.

Сәлам белән: Галимҗан.

## Мәҗит Гафурига[2]

24 май 1934 ел

Кадерле Мәҗит абзый!

Хатларыңны үз вакытында алган идем, хәлемнең бик авыр чагы, кәефемнең начар көннәре иде, шуңа күрә җавабым кичекте.

Больницада 3 ½ ай [ятып] чыктым, әмма зур нәтиҗә булмады, хәзер һәр көн доктор килеп дәвалап йөри, калган барлык мәшәкатем – өйдә хатыным өстенә төшә инде.

Үзем әле һаман ятудамын, тик бүлмә эчендә йөрештерәм.

Озын яза алмыйм, гафу ит.

Сәламәтлек теләп калам: Галимҗан.

1934. 24. V.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 77), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 208) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 102), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 209) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Гайшә Шәриповага[1]

25 май 1934 ел

Гайшә Шәрипова иптәш,

Сезнең Галимҗан Ибраһимовка язган хатыгыз килде. Ләкин ул каты авыру, шул сәбәпле түбәнгә[2] ике мәсьәлә турында аның тапшыруы буенча мин Сезгә җавап язам. «Татар хатыны ниләр күрми» китабын тәрҗемә итеп нәшриятларга тәкъдим кылу сезгә рөхсәт. Ләкин бер шарт бар: тәрҗемәче белән бергә автор белән дә договор ясасыннар. Каты авырулыгы сәбәбеннән Сезнең переводларга тулы отзов язарга хәзерге вакытта аның көче, хәле юк, шуны әйтергә кушты.

Сәлам белән: Хәдичә Әпсәләмова.
Ялта, 1934 е. 25 май.

## Гайшә Шәриповага[3]

24 июль 1934 ел

Гайшә иптәш!

ГИХЛның договоры килгән иде, кул куеп кайтардым. Рябинина бу тәрҗемәне Сезгә бирәм дигән[4]. Мин, әлбәттә, ризамын, яхшы чыгарырсыз дип калам. Казанда яңа арада «Безнең көннәр»нең яңа редакциядә икенче басмасы чыкты[5]. 1935 нең ГИХЛ планына шуның тәрҗемәсен кертәсе иде. 25–30 табак. Беренче революция (1905) темасы. Сөйләшеп карагыз.

Сәлам: Галимҗан.
1934. 24. VII. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә (машинкада язылган) Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 4). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 143) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Хат авторының стиле, орфографиясе сакланылды.

[3] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 4). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 143), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 209) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Конверт тышына адресат шулай күрсәтелгән: «Москва, 10 Скорняжный переул. д. 9, кв. 5 т. Шариповой Гайше». Әмма 10 саны кызыл карандаш белән сызылып, 53 кә төзәтелгән. Г. Ибраһимовның адресы: «Ялта, Халтурина 5. Г. Г. Ибрагимов».

Конверт артында Мәскәү почтасының бер мөһерендә «Москва-53 Сокольнический 27. 7.34. 17 час», икенчесендә «Москва-53 Сокольнический 29. 7. 34. 9 час.» дип куелган.

[4] *Рябинина бу тәрҗемәне Сезгә бирәм дигән* – сүз «Татар хатыны ниләр күрми» повестен рус теленә тәрҗемә итү хакында бара.

[5] İbrahimьf Ƣ. Sajlanma əsərlər. Bezneŋ kønnər. Roman / Çəvaplь redaktor Ƣөmər Ƣəli / Ƣ. İbrahimьf.– Qazan: Tatgosizdat, 1934.– Өcence həm dyrtence kitap.– 482 b.

## Гайшә Шәриповага[1]

1934. 24. 8

Ялта

Гайшә иптәш!

Сездән бер үтенеч: «Дочь степи» романын миңа налож[енный] платеж буенча 25 нөсхә җибәртү чарасын күрегез әле. Башкача алдырырга һич юл тапмадым. Килгән нөсхәләрне иптәшләр талап бетерде.

Җавап көтеп: Г. Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 27). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 144), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 210) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва 53 Скорняжный переулок 9 кв. 5 Т. Шариповой Гайше». Мәскәүдәге почта мөһерендә «Москва 53, Сокольнический 27. 8.14 час» дип куелган. Ялта почтасы мөһереннән күренгәнчә, хат аннан 25 августта җибәрелгән.

## Мәҗит Гафурига[1]

12 сентябрь 1934 ел

Кадерле Мәҗит агай!

Хатыңны алдым. Минем хәл авыр әле, плевритны җиңеп бетерә алмыйм, күп газаплый, җәфалый.

Син, Ялтага киләм, дигәнсең. Бу – әлбәттә, дөрес фикер.

Мин бу ашыгыч хатымда шул турыда синең сораганнарыңа практик җаваплар язам:

Санаторийага кермәс булсаң, сиңа, әлбәттә, бер ярдәмче кеше белән килергә кирәк. Зөһрә иптәш, әлбәттә, иң уңайлы юлдаш булыр, башка кеше кирәгенчә ярдәм итә алмас, чөнки үзең йөремәгәч, һәммә эшең аңа йөкләнер.

Аерым бүлмә табу эше тик мондагы властьның нык ярдәме белән генә мөмкин. Бу хакта Башкортстан хөкүмәтенең аерым мөрәҗәгате кирәк. Алдан телеграф белән булса, бигрәк яхшы.

Расход зур булыр: гонорар белән һәм хөкүмәттән ярдәм белән финанс ягын нык тәэмин ит.

Ашау-эчү мәсьәләсендә дә шулай ук аерым мөрәҗәгать белән ябык кибеткә һәм санаторийадан өйгә алуга беркеттерәсе булыр.

Гомумән, шәкертчә бер төенчек, бер хат күтәреп кенә килергә ярамый, алдан андагы хөкүмәт аркылы хәбәрләштереп, төп кирәкләрне (бүлмә, ашау, доктор) рәсми тәэмин өчен вәгъдә алу кирәк. Шулай итмәгәндә, борчу күп булыр.

Әгәр кыен димәсәң, башта номерда торырга мөмкин. Номерларда бүлмә, әлбәттә, табылыр, бераз кыйбатка.

Тамакны дәвалау өчен Ялта бик уңай булачак. Килүдән файда итәрсең.

Күп сәлам белән: Галимҗан.
1934.12.IX. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 102–103), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 210–211) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Гайшә Шәриповага[1]

18 сентябрь 1934 ел

Гайшә иптәш, хатыгызны алдым.

«Д[очь] с[тепи]»нең табылмавы гаҗәп. Уфага да бармаган, Казанга да юк. Кырымга 2 килде. Съездда да юк – кая озаталар аны? Тиешле урыннарга юк.

Тәрҗемә турында фикеремне сорагансыз.

«Д[очь] с[тепи]»нең тәрҗемәсе Сезнең моңарчы чыкканнардан һәммәсеннән алда. Мин тәрҗемәне әйбәт таптым. Ләкин масаймагыз, алдагы тәрҗемәләрне тагы да югарырак дәрәҗәгә мендерегез, чөнки качество моменты һаман ныграк сорала бит.

«Татар хатыны»н миңа җибәрерсез. Хәлем бар чак булса, карармын.

«Б[езнең] к[өннәр]» турында кичә «Лит[ературная] газ[ета]»да х[әбәр] бар[2], 34 елның ахырында чыга дигән. Бу яңлыш булса кирәк, «Т[атар] х[атыны] [ниләр күрми]» белән бутаганнар булыр[3].

«Б[езнең] к[өннәр]» турында договор ясау эшен йоклатмагыз. Ул зур әсәр, аны яхшы эшләп чыгару күп вакыт, күп хезмәт сорар.

Хата булмасын, иске басма түгел, Казанда бу ел чыккан яңа икенче басманы алыгыз. Әгәр моны тәрҗемәгә нәүбәт җитсә, миңа хәбәр итәрсез. Ул хакта минем киңәшләрем булыр.

Эшләрнең барышы турында миңа белдерә торыгыз.

Сәлам белән: Галимҗан.

1934.18.9.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 14). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 144), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 211) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды. Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва, 53 Скорняжный 9, кв. 5. т. Г. Шариповой». Җибәрелгән адрес: «Ялта, у. Халтурина, 5. Г. Ибрагимов». Өстәге штемпельдә «Спешная почта» дип куелган.

[2] *«Б[езнең] к[өннәр]» турында кичә «Лит[ературная] газ[ета]»да х[әбәр] бар* – «Литературная газета»ның 1934 елгы 14 сентябрь санында басылган хәбәрдә «Безнең көннәр» романы милли язучылар әсәрләренең 1935 елда тәрҗемә ителәчәк планына кертелүе хакында белдерелә.

[3] *«Т[атар] х[атыны] [ниләр күрми]» белән бутаганнар булыр* – бу әсәрне («Татар хатыны ниләр күрми») тәрҗемә итү мәсьәләсе 1934 елда хәл ителгән булса кирәк. Бу хакта Х. Әпсәләмованың алда китерелгән хатыннан ачык аңлашыла. Роман 1935 елда Г. Шәрипова тәрҗемәсендә «Татарка» исеме белән басылып чыга: Ибрагимов Г. Татарка: Роман / Перевод с татарского Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: Гос. изд-во «Художественная литература», 1935.– 174 с.

## Мәҗит Гафурига[1]

7 октябрь 1934 ел

Кадерле Мәҗит агай!

Сиңа сентябрь 13 ндә җавап хат салган идем. Әминнең[2] әйтүе буенча, син тиз килер дип көткән идек, көннәр дә гаҗәп дәрәҗәдә матур иде бу араларда. Нигәдер кичектең. Минем хатны алдыңмы, юкмы? Мин синең сорауларга тулырак җавап бирергә тырышкан идем. Әмин дә, ике хат язып, шул турыда ачыграк мәгълүмат биргән иде.

Синнән һичбер җавап килмәде. Бәлки, бүген, иртәгә киләм, дип торганга язмаган булырсың.

Үземнең хәл бик шәптән түгел әле. Плевритны җиңә алмый газапланам. Озаккарак сузылуы байтак борчый үземне, ләкин ни эшлисең? Кулдан килгән бөтен чараларны күреп, бу яман авыруга каршы сугышып ятам. Инде бүлмәдә, йортка чыгып йөри башладым. Алда ни булыр тагы?

Сиңа җибәрәсе берничә китабым бар иде. Үзең килеп чыгарсың дип җибәрми торам.

Зөһрә иптәшкә, балаларга сәлам әйт. Башка мәсьәләләр турында үткән хатымда язган булганга кабатлыйм.

Ялтага көтеп калабыз.

Күп сәлам белән: Галимҗан.
1934. 7. 10. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә.А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 103), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 211–212) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Әмин* – Әмин Фәхретдин улы Зөбәиров (1891–1964), РСФСРның һәм БАССРның халык артисты.

# 1935

## Кави Нәҗмигә[1]

1935. 1. I. Ялта

Кадерле Кави,

Посылка алынгач, сиңа (Самитов белән бергә) җавап хат салган идем, шаять, алгансыңдыр. Иҗади отпусканы үткәрергә ике айга Ялтага барам, дигәч, мин үзеңне көттем. Ләкин байтак көннәр үтсә дә, син һаман юк. Исхак килгән иде, ул да бернәрсә дә әйтә алмады. Кичектеңме, әллә бөтенләй ваз кичеп, Казанда гына үткәрергә булдыңмы? Минемчә, читкә китеп, ике айны бөтенләй бикләнеп эшләү – иҗади нәтиҗә ягыннан зур файда итәр иде.

Матбугат аркылы Шәриф Камал юбилеен карап бардым. Бу – бик күңелле бәйрәмгә әйләнде, бик яратып калдым. Татарчада минем телеграмның уртасын бозыбрак тәрҗемә иткәннәр. «Кр[асная] Тат[ария]» декабрьдә килмәде, анда ничек чыккандыр, күрмәдем.

Дәвалану шартларын яхшырту турыдагы ӨК күчерелмәсе килде. Бу эштә синең, әлбәттә, күп хезмәтең булды инде. Моның өчен иптәшчә рәхмәт инде. Ул карарның практик үткәрү ягы Кыям[2] иптәшкә йөкләтелгән икән. Ул, шаять, хәтердән чыгармастыр. Декабрь ае минем чир өчен аеруча кыенлыклар китерде, шулай да артык бирешми кичтем инде бугай.

Бөтенсоюз әдәби съездның стенография китабы чыкты, дип язылганга ике [ай] үтте, күп якка сугылдым, таба алмыйм. Әллә булмаса, игъланнары иртәрәк булдымы?

Ялтада әзрәк суык, кар. Ләкин кояш күп. Диңгез. Килә калсаң, иҗади настроение ягыннан нык канатланырсың дип беләм.

Хәдичә белән икебездән Сәрвәр туганга күп сәлам. Хат көтеп калам.

Эшләреңә, аеруча иҗатларыңа, аеруча «Гарнизон»га уңыш телим: Галимҗан.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында (б. 77–78), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 213) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Кыям* – Кыям Галимбәк улы Абрамов (Хәсәнов) (1897–1938), дәүләт эшлеклесе. 1930–1937 елларда ТАССР Халык комиссарлары Советы рәисе; СССР Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы әгъзасы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## Гайшә Шәриповага[1]

15 февраль 1935 ел

Гайшә иптәш!

«Татар хатыны...» китабын бастыру өчен совет агентствосы белән договор ясауга карата булган эшләр телеграм белән кыска үтәлде[2]. Хәзер миңа ул хакта тулы информация язygыз инде. Кем кузгатты, нинди шартлар буенча бара? Дәхи нигә «Т[атар] х[атыныниләр күрми]» китабын «Казакъ кызы» белән алмаштыру мөмкин түгел иде?

Мин алдагы хатларның берничәсендә тәрҗемәгезнең беренче табагын, әлбәттә, җибәрегез дигән идем – тагы кабатлыйм. Чөнки бөтенләй сукыр көенчә басарга ихтыяр итә алмыйм мин. Гомумән, Сезгә автор белән нык контакт кирәк. Эшкә башлаудан элек аның белән киңәшләшергә кирәк. Юкса һәрвакыт уңайсыз ягы килеп чыгарга мөмкин. Әле ул Гослитиздат белән булган мәсьәләгез ни хәлдә?[3] Сезнең белән договор ясыйлармы, юкмы? Минем кәефем бик начар булды, әле аларга хат язганым юк. Сездән һәммәсе турында тулы хәбәр алгач, язармын дип торам.

Хатыгызны көтеп калам.

Сәлам белән: Г. Ибраһимов.
1935. 15. II.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 15). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 144), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 214) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай язылган: «Заказное. Москва 53. Скорняжный переул. д. № 9, кв. 5 тов. Гайше Шариповой».

Җибәрелгән адрес: «Ялта, Халтурина 5, Г.Г. Ибрагимов». Мәскәүдәге почтаның ике мөһере бар. Берсендә «Москва 53, Сокольнический узел 18. 3. 35. 14 [час]», икенчесендә «Сокольнический узел 18. 3. 35. 15 час» дип куелган.

[2] *«Татар хатыны...» китабын бастыру өчен совет агентствосы белән договор ясауга карата булган эшләр телеграм белән кыска үтәлде* – М. Хәсәнов һәм И. Абдуллин аңлатмасында язылганча, Г. Шәрипова «Татар хатыныниләр күрми» әсәрен чит илдә чыгару хакында «Литературное агентство» акционер җәмгыяте белән сөйләшүләр башлый.

[3] *Әле ул Гослитиздат белән булган мәсьәләгез ни хәлдә?* – сүз «Безнең көннәр» романын рус теленә тәрҗемә итү өчен Гослитиздат планына кертү хакында бара.

## Гайшә Шәриповага[1]

19 февраль 1935 ел

Гайшә Шәрипова иптәш!

Сезгә кул куеп җибәрдем[2].

«Татар х[атыныниләр күрми]» урынына «Казакъ кызы» романын тәкъдим итәргә кирәк иде. Болай итмәү хата булган, чөнки «К[азакъ] к[ызы]», әлбәттә, үтәр иде. Әгәр аз гына мөмкинлек булса, шулай эшләгез. «Т[атар] х[атыны ниләр күрми]» турындагы эшегез ГИХЛ белән җиңеләйтелгән икән. Ярый анысы. Хат языгыз.

Сәлам белән: Галимҗан.
1935. 19. II.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 3). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 145), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 214) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Спешное. Москва 53 Скорняжный пер. 9, кв. 5 тов. Г. Шариповой».

Җибәрелгән адрес: Ялта, Халтурина 5. Г. Г. Ибрагимов. Мәскәү почтасында сугылган ике мөһернең берсендә «Москва Сокольнический узел 22. 3. 53 12 час.», икенчесендә «Москва Сокольнический узел 22. 3. 35. 13 час.» дип куелган.

[2] *Сезгә кул куеп җибәрдем* – сүз «Литературное агентство» акционер җәмгыяте белән төзелгән килешү хакында бара.

## Ялтадан хат
## Галимҗан ага Ибраһимов белән сөйләшү[1]

15 март 1935 ел

Ялта шәһәре – Советлар Союзының Кара диңгез буендагы иң матур шәһәрләренең берсе.

Ул бер яктан Кара диңгез, икенче яктан каяланып югары күтәрелгән биек таулар белән чолганган. Ул – санатория шәһәре. Анда һәр ел саен йөзәр, меңәрләгән хезмәт ияләре ял итәләр.

Татарларның атаклы язучысы Галимҗан ага Ибраһимовның да шушы шәһәрдә ял итүен күптәннән ишетеп белә идем. Ул берничә еллардан бирле үпкә авыруыннан дәвалана.

Ялтага ял итәргә баргач, аны күрмичә китәсе килмәде. Галимҗан аганы эзләп таптым, күрешергә рөхсәт сорадым.

– Мөмкин, бик мөмкин, – диде ул. Мин аның бүлмәсенә кергәндә, ул йомшак креслода иптәшенең «Правда» газетасын укуын тыңлап утыра иде. Галимҗан ага миңа утырырга урын күрсәтте һәм, өстәлдән расческасын алып, чал кергән чәчен артка таба тарап куйды да:

– Сез кем буласыз? – диде.

Мин үземнең Башкортстанның бер район газетасы эшчесе икәнемне аңлаттым.

– Бик яхшы, ерак җирдән килеп хәл белергә кергәч.

Без үзара сүзгә башладык. Ул башта миннән Башкортстанда көздән уҗымнарның ничек калуын, көз яңгырларның булу-булмавын, карның ятышын сорады.

– Башкортстанда чәчүгә хәзерлек ничек бара? Безнең монда чәчүне бетереп киләләр инде,– диде.

Соңыннан безнең беседа әдәбият мәсьәләләренә күчте.

– Афзал Таһиров өйдәме, соңгы вакытта яңа китаплары чыканы юкмы?

– Чыкты, «Бишьеллыклар арасында» дигән хикәясе басылды.

– Әйе, ул миңа аның мөндәриҗәсен сөйләп чыккан иде.

[1] «Коммуна» газетасының 1935 елгы 15 апрель санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

– Тагын кемнәрнең китаплары чыкты? Мин аңа соңгы вакытта Башгиз тарафыннан чыгарылган әдәби китапларның үзем белгәннәрен санап чыктым.

Соңыннан ул миңа:

– Үзең күп язучыларны, шагыйрьләрне беләсең, ә соң нинди китаплар укыйсың,– дип сорау бирде. Мин аңа башкорт һәм татар телендә чыккан бөтен әдәби китапларны укып баруымны әйттем.

– Ә рус язучыларын укыйсыңмы?

– Аларын да, башкорт һәм татар теленә тәрҗемә ителгәннәрен укыйм.

– Син тәрҗемәләрне генә түгел, оригиналларын да укы,– диде.

Беседаның азагында мин аның сәламәтлеге турында сорау бирдем.

– Сәламәтлек шәптән түгел, һәрвакыт дип әйтерлек ятып торам. Һәр көн профессор һәм дежурный врач килеп карый. Яхшы көннәрдә генә ишек алларына чыккалыйм.

– Әдәби эш өстендә утырасыңмы?

– Сәламәтлек начарлана төшкәч, эшли алганым юк.

Бер сәгатьтән артыкка сузылган беседадан соң мин урынымнан тордым, ул да торып, мине ишеккә кадәре озатып калды.

Х. Канзафаров.
15 март, 1935 ел.

## Гайшә Шәриповага[1]

1 апрель 1935 ел

Гайшә иптәш,

Соңгы хатыгызны үз вакытында алган идем, кәефсезлек аркасында, җавабым кичекте.

Әдәби агентство өчен «Т[атар] х[атыныниләр күрми]» урынына «Дочь степи» романын тәкъдим итү мөмкин булмавының сәбәбе ачык аңлашылды, бу турыда сүзне бетерәм.

Хатыгызда принципиаль бер момент бар: автор белән контакт һәм әсәрләрне тәрҗемәче тарафыннан төрле нәшриятларга тәкъдим итү инициативасы.

Бөтен ачыклыгы белән әйтим: бу эштә Сезнең инициативагызга мин бик яхшы карыйм, аны бик кирәкле, файдалы саныйм, минем кебек еллар буенча Ялтада торган, шуңа күрә үзе кузгатып йөри алмаган автор өчен Сезнең инициативагыз аеруча кирәк. «Т[атар] х[атыны ниләр күрми]» артыннан «Без[нең] көннәр»не үткәрү эше тора. Әсәрнең тәрҗемәсе, әлбәттә, Сезгә бирелергә тиеш. Бу алдагы елга керсә кирәк, ләкин Сез бу хакта хәзердән үк ГИХЛ белән договор ягын да, тәрҗемә ягын да хәзерли торырсыз дип ышанам. Әгәр кирәк булса, мин авторлык сыйфаты белән, үземнең әсәрләрне тиешле нәшриятларга редакцияләргә үткәрү эшләрендә рәсми вәкаләт биреп куярга мөмкин.

Кыскасы, бу эшләрнең һәммә тармагында Сезнең тулы инициативагызны сорыйм, шуны кирәкле табам.

Кулъязманы алдым[2], тиздән җибәрермен.

Тапшырылганлык турында белдерегез.

Сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.
1935. 1. IV.
Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 29). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 145–146), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 215) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Кулъязманы алдым* – сүз «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең Г. Шәрипова тәрҗемә иткән рус телендәге кулъязмасы хакында бара.

## Кави Нәҗмигә[1]

1935. 16.V. Ялта

Кадерле Кави, күп сәлам җибәрәм. Открыткаңны алдым. Элеккесе дә тапшырылган иде. Боларның һәр икесе мине бик гаҗәпкә калдырды. Чөнки син бары тик Казанда гына практик чишелә торган мәсьәләләрне миннән сорап язасың. Мин, бер хатымда әйткәнчә, ул Кремль больницасына тик Татобком аркылы гына ирешү мөмкин, шуңа күрә син аны миннән түгел, Обкомнан белешәсе иде. Мәгълүм карар килде, ләкин ул бер кәгазь. Әмма аның практик ягы һаман да Казанда гына үтәлә. Син аны, шунда тиешле учреждение белән сөйләшәсе урында, миннән сорыйсың. Мин үзем ул турыларда Казаннан җавап көтәм. Гомумән, соңгы ике хатың миңа күңелсезлек бирде, син элеккечә ачык, туры яз.

Хәдичәдән Сәрвәр белән икегезгә сәлам: Галимҗан.

## Сәрвәр Әдһәмовага[2]

Ялта, 13/VI

Сәрвәр иптәш!

Сезнең 9/VI язган хатыгызны алдык. Рәхмәт. Галимҗан бик әкренлек белән әз генә җиңеләя, бүлмәдә йөрештерә. Ләкин әле бакчага чыгып йөри алмый. Казанга, Симферопольгә язучылар съездына чакырып телеграмнар килде. Бара алмавына бик борчыла.

Үзем инде яңа (Ялта) тормышына тәмам өйрәнеп җиттем. Көненә ике мәртәбә перевязка эшләнә: иртән доктор килеп эшли, кичен үзем эшлим. Шулай яшәп ятабыз. Җибәргән 300 [сум] акча тапшырылды. Артык хәбәр юк. Галимҗаннан сәлам.

Сәлам белән Хәдичә.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 216) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Елы күрсәтелмәгән – почта мөһере буенча куелды. Текст төп нөсхәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## Гайшә Шәриповага[1]

9 сентябрь 1935 ел

Кадерле Гайшә иптәш,

Сездән хат-хәбәр булмаганга бик күп вакытлар үтте. Казагыстаннан да кайттыгыз бугай[2].

Галимҗан Сезгә телеграм да җибәргән иде, аңа да җавабыгыз булмады. Эш болай тора: Рябинина телеграм белән хәбәр итте: «Безнең көннәр»не тәрҗемәгә өченче кварталда керешәбез, дип. Галимҗан бу әсәрнең тәрҗемәсен Сезгә бирергә уйлый. Сез үзегез дә алмакчы идегез. Хәзер инде бу эшкә тотынырга кирәк. Госиздат белән договор да ясарга кирәк. Сез бу турыда берәр чара күрәсезме, юкмы?

Җавап көтеп калабыз.

Галимҗаннан Сезгә күп сәлам. Галимҗан больницада, шуңа күрә мин язам.

Хөрмәт белән: Хәдичә.

Безнең адрес үзгәрде: Ялта, ул. Боуткинская[3], дом № 23. Г. Г. Ибрагимов.

1935 е[л]. 9/IX.

---

[1] Төп нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 5). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 146) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Казагыстаннан да кайттыгыз бугай* – әдәбият галиме Мансур Хәсәнов (1930–2010) һәм тел белгече Искәндәр Абдуллин (1935–1992) язганча, казакъ язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү өчен, Г. Шәрипованы Алматыга чакырган булганнар. Сүз аның шуннан кайтуы хакында бара.

[3] *Боуткинская* – дөресе: Боткинская.

## Татарстан Совет язучылары союзы әгъзаларына[1]

1935 ел

Кадерле язучы иптәшләр!

Ерак Кара диңгез буеннан сезгә бик сагынып күп сәламнәр юллыйм.

Күп еллар инде, каты авыруга каршы көрәш мәҗбүрияте мине сезнең белән бергә эшләүдән, совет әдәбияты өчен бергә көрәшеп бару бәхетеннән мәхрүм итте. Моңа карт язучының йөрәге бик әрни. Ләкин бер хәл мине юата килде һәм әле дә юата: сезнең белән әдәби иптәшлек багланышлары өзелмәде, хәстәлегемнең иң куркыныч чакларында да сез юаныч сүз белән, кирәксә, төрле рәвеш ярдәм белән минем авыр хәлемне җиңеләйтергә ашыктыгыз. Бу рәвеш дусча, иптәшчә мөнәсәбәтләр иң өметсез чакларда да минем күңелемә-йөрәгемә куәт, җаныма көч бирделәр. Озак еллар дәвам иткән бу иптәшлек, булышлык мөнәсәбәтләре минем авыруга каршы сугыша алуымның төп шартларыннан берсе булдылар.

Боларның һәммәсе өчен, кадерле әдип, шагыйрь иптәшләр, сезгә, Союзга тирән күңелемнән зур ихлас белән рәхмәт укыйм. Бу хатны менә шул бурычымны үтәү өчен яздым. Хәлем җиңел түгел. Шулай да яхшыра бара. Ышанам, бу чир бетәр. Мин яңадан сезнең арада, совет әдәбияты фронтында сезнең белән кулга-кул тотынып эшләргә-көрәшергә кайтырмын. Менә мин шул өмет белән яшим.

Сагынып кулларыгызны кысам.

Коммунистлык сәлам белән: Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы 12 нче санында (б. 69), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 216) бастырылган. Хат алдыннан шундый аңлатма урнаштырылган: «Татарстан совет язучылары Галимҗан Ибраһимов иптәшкә саулык-сәламәтлек теләп, хәл сорашып, татар совет әдәбиятының соңгы еллардагы уңышларын әйтеп коллектив хат язганнар иде. Түбәндә без Галимҗан иптәш Ибраһимовның шул хатка каршы язган җавабын басабыз». Текст журналдан алынды.

## 1936
## «Пионер каләме» редакциясенә[1]

14 гыйнвар 1936 ел

Кадерле Л. Гыйльми[2] һәм Н. Мөхит[3] иптәшләр! Хатыгызны алдым. Социализм көрәшләре эчендә туып үскән яшь буын белән һәрвакыт багланышта булуны бик телим. Ләкин бу соңгы ике ел минем авыруымның каты кризислы чаклары булып китте, иҗат эшендә дә, тормышның актив көчләре белән бәйләнешләргә дә бик зур тоткарлык ясалды. Сезнең белән тиешенчә мөнәсәбәт тота алмауның сәбәпләреннән зуры шул булды.

Хәзер инде бик акрын гына төзәлүгә барам бугай. Яңадан эш, көрәш көчләрем кайта дип өметләнәм.

Кулымдагы планы-материалы эшләнгән, караламалары бөтенләй тәмам ителгән әсәрләрем – кулъязмаларым арасында балалар, яшьләр тормышына караган кисәкләр бар. Хәлем төзәлә төшеп, бу язмаларны күңелем канәгатьләнерлек эшли алу белән сезгә җибәрергә вәгъдә итәм. Ләкин бу бер авыруның вәгъдәсе икәнен онытмагыз.

---

[1] Беренче мәртәбә «Пионер каләме» журналының 1936 елгы 2 нче санында (б. 33), аннан соң «Яшь ленинчы» газетасының 1967 елгы 18 гыйнвар, 1977 елның 12 март саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 218) бастырылган. Текст беренчел чыганактан алынды.

*«Пионер каләме» журналында хаттан алда шундый аңлатма урнаштырылган*: «1935 нче елның азагында «Пионер каләме» редакциясе Татарстаннан читтә яшәүче язучыларга, яңа – 1936 нчы ел белән котлап, хатлар җибәргән иде. Бу хатлар аша язучылар 1936 нчы елда «Пионер каләме» журналына актив катнашуга чакырдылар. Түбәндә без Галимҗан ага Ибраһимовның һәм Афзал ага Таһировның җавап хатларын басабыз».

«Яшь ленинчы» газетасында исә Г. Ибраһимовның әлеге хатын редакциягә Афзал Шамов (1901–1990) тапшырганлыгы әйтелә.

*«Пионер каләме»* – 1924–1928 елларда «Кечкенә иптәшләр», 1928–1932 елларда «Октябрь баласы», 1933–1941 елларда «Пионер каләме» (1941–1950 елларда чыкмый), 1951–1957 елларда «Пионер», 1957 елдан «Ялкын» исемнәре белән балалар өчен чыгарыла торган айлык әдәби журнал.

[2] *Л. Гыйльми* – Ләбиб Гыйльман улы Гыйльманов (1906–1947), язучы, 1935–1937 елларда «Пионер каләме» журналы һәм «Яшь ленинчы» газетасының җаваплы мөхәррире. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Н. Мөхит* – Нәбиулла Мөхетдинов (?–?), журналист, «Пионер каләме» журналының җаваплы сәркятибе.

Журналны яратып укыйм. Балалар, яшьләр өчен файдалы, җиңел һәм күңелле табам.

Социализм көрәшләре эчендә туып-үскән бәхетле яшь туганнарга миннән сәлам әйтегез. Хатларыгыз өчен һәркайчан бик шат булачакмын.

Ком[мунистлык] сәлам белән – Галимҗан Ибраһимов.

14/I – 36 ел. Ялта.

## Гайшә Шәриповага[1]

1936 ел

Гайшә Шәрипова иптәш,

мин бу арада үзләренең соравы буенча Гослитиздат – «Альманах народов СССР» редакциясенә «Безнең көннәр»дә[н] беренче җиде главаны җибәрдем[2]. Тәрҗемәсен Сезгә тапшырырга куштым. Сез инде шул уңай белән сөйләшкәндә «Б[езнең] к[өннәр]» өчен договор ясауны кузгатыгыз.

Альманах шул ук Гослитиздат бинасында икән. Секретаре: Жанго Гогоберидзе[3] атлы кеше икән. Шуның белән эш итәргә кирәк. Мин аларга төзәтелгән 52 битне җибәрдем. Хат языгыз.

Сәлам белән: Г. Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 20). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 146–147), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 218) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Хатның язылу датасы куелмаган, Ялта почтасы мөһере буенча китерелде.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва Скорняжный переул. дом. 9. кв. 5 Гайше Шариповой». Мәскәүдәге почтаның ике мөһере басылган. Аларның берсендә «Москва Сокольнический 5. 1. 36. 12 час.», икенчесендә «Москва Сокольнический 5. 1. 36. 13 час.» диелгән.

[2] *…мин бу арада үзләренең соравы буенча Гослитиздат – «Альманах народов СССР» редакциясенә «Безнең көннәр»дә[н] беренче җиде главаны җибәрдем* – Г. Шәриповада сакланып, соңыннан хәзерге Татарстан Республикасы Милли музеена тапшырылган бу бүлекләрдән күренгәнчә, алар әдипнең үз кулы белән төзәтелгән һәм берләштерелеп, тышлыгына шулай язылган: «Гослитиздат, Москва. В редакцию Альманаха творчество Народов СССР. От Галимджана Ибрагимова. Отрывок из романа «Наши дни» под названием: «Кавказлы Герей Султан» семь глав. 52 стр.». Эчке ягында татар телендә язылган: «СССР халыклары иҗаты альманахы өчен Кавказлы Гәрәй Солтан («Безнең көннәр» романыннан) Галимҗан Ибраһимов. Төзәтмәләр кертеп. «Безнең көннәр». Роман. Икенче басмасы; яңа редакциядә. Казан, Татгосиздат, 1934». Ләкин алар рус теленә тәрҗемә дә ителмәгән һәм 1937 елда нәшер ителгән «Творчество народов СССР» дигән альманахта бастырылмаган.

[3] *Жанго Гогоберидзе* – Жанго (Иван) Сергеевич Гогоберидзе (1905–1937), грузин шагыйре. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## Гайшә Шәриповага[1]

1936. 16. II

Хөрмәтле Гайшә иптәш.

Сездән хәбәр юк. Альманах өчен җибәрелгән материалның тәрҗемәсен Сезгә бирергә әйткән идем. Ул ни хәлдә?

Бу хатны бигрәк тә «Татар хатыны» турында язам. «Большевик»[2] журналында «Татарка» романын басылып чыккан әсәрләр арасында яздылар[3]. Ләкин һаман авторга тиешле нөсхәләрне алганым, басманы күргәнем юк. Гослитиздат һаман җибәрми. Сез шуның бер чарасын күрегез әле.

Галимҗан.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 21). Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 147), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 219) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва, 53 Скорняжный пер. д. 9, кв. 5 тов. Гайше Шариповой». Мәскәүдәге почта тарафыннан сугылган ике мөһернең берсендә «Москва Сокольнический узел 19. 3. 36. 14 час.», икенчесендә «Москва Сокольнический узел 19. 3. 36. 15 час.» дип куелган.

[2] *«Большевик»* – РКП(б) Үзәк комитеты Оештыру бюросы карары нигезендә барлыкка китерелгән, 1924–1952 елларда шушы, соңыннан «Коммунист» исеме белән нәшер ителгән теоретик һәм сәяси журнал.

[3] *...«Татарка» романын басылып чыккан әсәрләр арасында яздылар* – Ф. Ибраһимова мәгълүматына күрә, «Татарка»ның басылуы хакында хәбәр «Большевик» журналының 1936 елгы 1 нче санында урнаштырылган. Роман исә 1935 елда нәшер ителә: Ибрагимов Г. Татарка: Роман / Перевод с татарского Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: Гос. изд-во «Художественная литература», 1935.– 174 с.

## Гайшә Шәриповага[1]

7 март 1936 ел

Кадерле Гайшә иптәш.

Хатыгызны алдым. «Татарка» килде. Өстәмә гонорар тапшырылды.

Сезнең язуга караганда, «Без[нең] көннәр» эше дә бераз кузгала бугай[2]. Ләкин бу турыда Сезнең туктаусыз хәтерләтә торуыгыз бик кирәк. Миңа договор җибәрергә онытмасыннар.

Гослитиздатның соравы буенча, мин «Б[езнең] көннәр»нең иң соңгы вакытта карап төзәтелгән нөсхәсен җибәргән идем. Сездә шулмы?[3] Моңа дикъкать итегез, чөнки минем карап төзәткән нөсхә буенча гына тәрҗемә итәргә ярый. Сезгә рәсем җибәрәм. Берсе үзегез өчен, берсе, урысча чыга калса, шуңа кертерсез дип[4]. Соравыгыз шулай түгелме?

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694ª – 2). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 147), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 219–220) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: «Москва, 53 Скорняжный пер. д. № 9, кв. 5 тов. Гайше Шариповой». Җибәрелгән адрес: «Ялта, Боткинская, 23 Г. Г. Ибрагимов».

Ялта почтасының мөһерендә «8. 3. 36», Мәскәү почтасыныкында «11. 3. 36. 8 ч.» дип куелган.

[2] *...«Без[нең] көннәр» эше дә бераз кузгала бугай* – Г. Шәрипованың «Көндәлек битләреннән» дигән мәкаләсендә язылганча, 1935 ел азакларында Мәскәү дәүләт матур әдәбият нәшриятында бу романны («Безнең көннәр») русча бастырып чыгару турында сүз кузгала («Казан утлары», 1967, № 3, б. 129). Бу хакта Г. Шәриповага 1935 елның 9 ноябрендә язган хатында да әйтелә.

[3] *Сездә шулмы?* – сүз 1934 елда «Яңалиф» нәшриятында басылган «Безнең көннәр» романының бер нөсхәсе хакында бара. Ул автор тарафыннан шактый төзәтелгән булган һәм Г. Шәрипованың шәхси архивында сакланып калган. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда сакланган.

Романны тәрҗемә итү эше башланса да, Г. Шәрипова үзе аңлатканча, аның Казакъстанга күченеп китүе сәбәпле, тукталып кала («Казан утлары», 1967, № 3, б. 130). Тәрҗемәнең машинкада басылган 198 битлек нөсхәсе, М. Хәсәнов һәм И. Абдуллин язганча, хәзерге вакытта Казакъстанның Дәүләт тарих архивында сакланаган (1956 ф., 1 тасв., 23 эш).

[4] *Сезгә рәсем җибәрәм. Берсе үзегез өчен, берсе, урысча чыга калса, шуңа кертерсез дип* – бу ике фото да хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694ª – 31, 125694ª – 33).

«Яшь йөрәкләр»не[1] сорагансыз, һичкайдан табып булмый, кулымдагы актык бер нөсхәне бирү мөмкин түгел икәнен үзегез беләсез. Бу әсәрне басарга сорыйлар, карап биреп бастырсам, Сезгә җибәрермен. Урысча да, бәлки, чыгарырга туры килер[2].

Инде актык мәсьәләгә туктыйм. Татарны ташлап, башка берәр әдәбиятны тәрҗемәгә күчү турында сорагансыз[3]. Башта, вакытлыча бу күчүнең файдалы моментлары булыр. Ләкин бу — вакытлы булыр, язучы гына түгел, тәрҗемәченең эше дә — үзенә бер төрле иҗат процессы икәнендә шик юк. Бу процессның үсүе, күтәрелүе дә тиешенчә җимеш бирә алмый. Бу хак[та] нык уйларга кирәк. Сез татарда беренче тәрҗемәче урынын алдыгыз, тәҗрибәләрегез дә зур, шулар белән Союзга үттегез[4]. Кыскасы, татар теленең, тормышының бөтен нечкәлекләре Сезгә табигый хәлдә мәгълүм. Башкада Сез моңардан мәхрүм буласыз, коры, аз җимешле чыгар.

Беләм, татар эчендәге кайбер элементларның туктаусыз интригалары Сезне бик борчый[5]. Ләкин белегез, аз гына алга бара башласагыз, һәркайда болар килеп чыгар. Шуңа күрә болардан качып булмый, эш-көрәш белән боларны җиңү юлын тотарга кирәк. Минем 30 еллык тәҗрибәм шуны сөйли.

---

[1] *«Яшь йөрәкләр»* – әсәр 1912 елда Казанда «Өмид» матбагасында нәшер ителгән.

[2] *Урысча да, бәлки, чыгарырга туры килер* – рус телендә тәрҗемәсе бары тик 1980 елда гына нәшер ителде: Ибрагимов Г. Молодые сердца: Роман и рассказы / Пер. с. татар. Розы Фаткуллиной // Г. Ибрагимов.– Казань: Татар. кн. изд-во, 1980.– 240 с.

[3] *Татарны ташлап, башка берәр әдәбиятны тәрҗемәгә күчү турында сорагансыз* – М. Хәсәнов һәм И. Абдуллин язганча, Г. Шәрипова «Казакъ кызы» романын рус теленә тәрҗемә иткән вакытта, Г. Ибраһимов киңәше буенча, Мәскәүдә укучы казакъ язучылары С. Моканов, С. Сәйфуллин, Ильяс Җансугиров (1894–1938) белән танышып-дуслашып китә. Казакъ язучыларының да әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү өчен, алар аңа Алматыга күченергә тәкъдим итәләр. Ул 1936 елда Алматыга күчә һәм вафатына кадәр шунда яши.

[4] *…шулар белән Союзга үттегез* – Г. Шәрипова, тәрҗемәче буларак, 1934 елда СССР Язучылар берлегенә әгъзалыкка кабул ителә.

[5] *Беләм, татар эчендәге кайбер элементларның туктаусыз интригалары Сезне бик борчый* – М. Хәсәнов һәм И. Абдуллин аңлатмасына күрә, сүз язучы Мәхмүт Галәүнең (1886–1938) «Болганчык еллар» романын русча бастыру эшендәге күңелсезлекләр һ.б. хакында бара.

Һәрхәлдә, бик яхшы үсеп, тәкъдир ителеп барган әдәби хезмәтегезне кисәргә уйлау – үзегезгә дә, татар совет әдәбиятына да зарарлы булачак.

«Татар хатыны [ниләр күрми]» тәрҗемәсен урыслар мактыйлар, монда бик яратып укыйлар. Мәскәүдән парашютистка Яковлева[1] әсәр турында бик мактап озын хат язды.

Сезнең бүләк алуыгызга бик шатландым. Чын күңелдән котлыйм. Бу котлавым кичегүнең сәбәбе – каты авыруым булды.

Хат языгыз.

Хөрмәт белән: Галимҗан.
1936. 7. III.
Ялта.

---

[1] *Яковлева* – Ольга Николаевна Яковлева (1912–?), һава көчләренең махсус конструкторлык бюросы конструкторы, төркемләп сикерүнең югары рекордын куйган өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән атаклы парашютчы, шагыйрь Салих Батталның (1905–1995) беренче хатыны (1948 елда аерылышалар). Аның шундый китаплары да бар: Яковлева О. и Галахов П. Будем летать. Парашютный и планерный кружки на предприятии / О. Яковлева и П. Галахов.– М.: Профиздат, 1935.– 64 с.; Яковлева О. Рассказы парашютистки. Литературная обработка Татьяны Тэсс / О. Яковлева.– М.: Гос. изд-во «Художественной литературы», 1938.– 78 с. С. Баттал үзенең «Баштан үткәннәр» дигән истәлегендә: «Г. Ибраһимов икенче хатында: «Минем китапны син таныш кызларыңа укыткансың, бу бик кызык булды әле!» – дип язган иде. Сүз аның русчага Шәрипова тарафыннан тәрҗемә ителгән «Татарка» исемендә чыккан китабы турында бара. Парашютчы кызлар миннән алып укыдылар да, аны бик яратып, зур эстетик ләззәт биргән өчен, авторына рәхмәт язып, күмәк хат җибәрделәр»,– ди (Баттал С. Сайланма әсәрләр. Проза. Казан, 1974, б. 361).

## Гайшә Шәриповага[1]

20 март, 1936 ел. Ялта

Хөрмәтле Гайшә ханым,

хатыгызны алдым. Договор эшенең һаман тәмам булмавы эчне пошыргыч бер мәсьәләгә әйләнеп бара. Моны тизрәк өзеп, практик эшкә – тәрҗемәгә тотынырга кирәк иде[2]: кыйммәтле вакыт юкка китә бит.

Сез андагы шартлар буенча сатулашырга хаклысыз. Ләкин үзегезне Гослитиздатка каршы куеп, алар белән көрәшү хәленә керүдән сакланырга кирәк. Алар частный нашир түгел, Сез үзегезне шул зур коллективның бер әгъзасы итеп карарга тиешлесез. Шулай каралса, бер урында алар, бер урында Сез уступкага барырга туры килер. Сез аларны үз кешегез, бу тәрҗемә эшләрен үз эшегез итеп уйласагыз, гонорарның бер тип әсәрләрдә артыграк, икенчедә кимрәк булу моментлары – эшне ташлар дәрәҗәдә кискенлеккә алып бармаска тиеш. Сезгә бу очраклы бер эш түгел. Сез – профессиональ тәрҗемәче, Сез – Союз әгъзасы; мондый эшләрдә санап алынган акча белән бер дәрәҗәдә үк моральный авторитетны күз алдында тотарга кирәк. Әдәби мәйданда моральный авторитет – саф алтын ул. Аның аркасында матди файда үзе тагы төплерәк нигезгә утырадыр.

Гонорар өчен сатулашканда, бу моментларны бер дә хәтердән чыгарырга ярамый. Мин үзем ач хәлемдә «Яшь йөрәкләр» кебек зур романны бөтенләй буш бирдем, «Казакъ кызы» өчен «Центриздат» табагына 35 сум түләде. Башка кайбер китапларымның III нче, IV нче басмаларына 400 тәңкә түлиләр. Мондый эш базарга чыгарып мал сату түгел. Хәзер исәпләп карасам, минем буш биргән романым һәм 35 кә биргән «К[азакъ] к[ызы]» романы гомуми нәтиҗәләр буенча миңа матди тәэмин ягыннан да зуррак файда китергәннәр. Кыскасы, бу эшләрдә киңрәк,

---

[1] Төп нөсхә Казакъстан Республикасы Үзәк Дәүләт архивында Г. Шәрипова фондында саклана (1956 ф., 1 тасв., 72 эш). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1977 елгы 3 нче санында (б. 162–163), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 220–221) бастырылган. Текст журналдан алынды.

[2] *...тәрҗемәгә тотынырга кирәк иде* – сүз «Безнең көннәр» әсәрен рус теленә тәрҗемә итү хакында бара.

ераграк уйлап, гомуми нәтиҗә якларын күз алдында тотарга тиешлебез.

Мин бүген Асадуллаев[1] иптәшкә хат язып, Сезгә гонорар эшендә дә чара күрсәттем[2].

Яхшылап аңлашкач, алар анда Сезгә арттырырлар, мин реальный юлны әйттем аларга.

Җавабыгызны тиз языгыз.

Сәлам белән: Галимҗан.

---

[1] *Әсәдуллаев* – Дәүләт матур әдәбият нәшриятының СССР халыклары бүлеге мөхәррире.

[2] *Сезгә гонорар эшендә дә чара күрсәттем* – бу хакта тулырак Г. Ибраһимовның Әсәдуллаевка язган хатында.

## Гайшә Шәриповага[1]

13 апрель 1936 ел

Г. Шәрипова иптәш,

Сезнең хат белән бергәрәк альманах редакциясеннән дә хат килгән иде. Алар: Сезгә ике төрле текст җибәрдек, шул хакта җавап көтәбез һәм үзегезнең төзәтмәләрегезне язып җибәрегез, дигәннәр. Бер үк җавап хатны моның белән Сезгә дә, аларга да салам. Шул урысча хатымда язылганга, монда кабатламыйм. Сезнең тәрҗемә төзәтелгәч, яңадан машинкада басылды. Әгәр урын күп ала дигән сәбәптән кыскарткан булсалар, аерым тәкъдим бирдем: ахыр чиктә баштагы ике глава калыр, өченчедән башлап керер.

Тизлектә җавап языгыз. Сәлам белән: Г. Ибраһимов.

1936. 13. IV.

Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 18). Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 148), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 222) басылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай күрсәтелгән: Спешное. Москва, 53 Скорняжный переул. д. 9, кв. 5 тов. Г. Шариповой.

Җибәрелгән адрес: Ялта, Боткинская 23, Г. Г. Ибрагимов. Мәскәү почтасында сугылган мөһердә «Москва 14 Сокольнический 17. IV. 36. 4 час.» диелгән.

## Редакции «Альманах творчество народов СССР»[1]

13 апрель 1936 ел

Дорогие товарищи.

Получил от Вас через т[оварища] Шариповой два текста отрывка моего романа «Наши дни». Сердечно благодарю за то, что сочли нужным предварительно ознакомить меня с этими материалами. При возвращение их обратно к Вам нахожу нужным сделать как автор несколько замечаний:

1 – Прежнее название отрывка мне не нравится, будем называть: «Первые шаги».

2 – Первый текст, проредактированный, и названный Вами – «несколько сжатыми» меня не удовлетворяет. Тут редакторская работа, главным образом направлена на механическое сокращение текста, чем на исправление недочетов идеологического и стилистического порядка. Местами даже совсем разрываются связи между фразами. В результате таких безцеремонных сокращений отрывок в многих местах превращается в газетно-протокольный очерк о событиях 1905 г.

3 – Второй текст – полный перевод т. Шариповой здесь был просмотрен, проверен с подлинником, проредактирован и сделан в некоторых местах необходимые сокращения. Заново перепечатать этот исправленный текст посылаю Вам для альманаха.

4 – Если сокращение редактора было вызвано соображениями листажа, тогда я предлагаю как крайняя мера, не включить в альманах первые две главы, начать только с третьей главы (Старый жандарм). Это более приемлимо, чем ужасные сокращения в «сжатом» тексте.

Жду ответа.

С ком[мунистическим] приветом: Галимджан Ибрагимов.

1936. 13. IV.

Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 6). Беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемә ителеп Г. Шәрипованың «Көндәлек битләреннән» дигән мәкаләсендә («Казан утлары», 1967, № 3, б.130), аннан соң «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 148), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 223) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

## Кәрим Тинчуринга[1]

1936 ел, 10 май, Ялта

Кадерле дус Кәрим!

Бу 1936 ел эчендә Синең 25 еллык хезмәт бәйрәмнең[2] булачагын беләидем. Якын арада тантананың көнен хәбәр иттеләр. Әсәрләреңнең һәммәсен укып та, сәхнәдә күреп тә беләм. Татар культура хәрәкәтенең элекке авыр чакларыннан алып, хәзерге бәхетле көннәргәчә татар театры өчен каһарманнарча дәвам иттереп килгән бөтен хезмәтең дә күз алдымда. Шуңа күрә Синең бу тиешле хезмәт бәйрәмең өчен бөтен күңеленнән иң нык шатланган дусларыңның берсе мин булырмын.

Яшә, Кәрим туган! Синең бөек бәйрәмең белән бөтен йөрәгемнән котлыйм. Сиңа күп гомер телим, тагы күп кыйммәтле әсәрләр бирүеңә, драмаларың аркылы социализм өчен көрәшүләрең тагы да зур дәрәҗәгә күтәрелүенә нык ышанып калам.

Дуслык һәм котлау сәламе белән: Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 5 нче санында (б. 135), аннан соң «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 9 нчы санында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 223–224) бастырылган. Текст беренчел чыганактан алынды.

«Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 9 нчы санында шундый аңлатма урнаштырылган: «Хат почта кәгазенең ике битенә машинкада яңалиф хәрефләре белән басылган. Галимҗан Ибраһимов кулы белән хатның беренче битендә өстә «Татарстан язучылары Союзына. Копия» дип язылган һәм хатның ахырында яңалифчә «Галимҗан Ибраһимов» дип кул куелган. Хат Заһидә ханым Тинчуринада сакланган».

*Заһидә Шаһбазгәрәй кызы Тинчурина (Әхмәрова) (1893–1988)* – К. Тинчуринның хатыны.

[2] *Синең 25 еллык хезмәт бәйрәмнең* – 1936 елда К. Тинчуринның иҗат эшчәнлегенә 25 ел тула. Бу юбилей 28 майда Татар дәүләт академия театры бинасында тантаналы рәвештә билгеләп үтелә.

## Гайшә Шәриповага[1]

1936 г. 30/VI – Ялта

Г[айшә] Шәрипова иптәш!

Бу хат белән Сезгә тәрҗемәләрегезгә бәйләнешле бер тәкъдим ясыйм. Татгосиздат минем Мәскәүдә урысча басылган әсәрләремне Казанда икенче тапкыр басарга карар иткән[2]. Мин ризалык бирдем.

Безгә шул эшнең хәзерлеген күрә башларга кирәк: ул тәрҗемәләрне яңадан карап, тиешле урыннарын төзәтеп, калган җирләрен һәммәсен тутырып, кытыршы җирләрендә стильне шомартып чыгарга кирәк. Тәрҗемәләр Сезнеке булганга, бу яңа басма өчен хәзерлек эшен дә, әлбәттә, Сез башкарыгыз.

Бу төзәтелгән икенче басма өчен тәрҗемәчегә, әлбәттә, гонорар түләнә. Гадәттә мондый икенче, төзәтелгән тәрҗемәләр өчен табагына күпме түләнгәнен әйтеп язсагыз бигрәк тә яхшы булыр.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 17). Дата кулдан куелган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 149), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 224–225) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Адресат шулай язылган: Москва, 53 Скорняжный переул. д. № 9, кв. 5 тов. Гайше Шариповой.

Җибәрелгән адрес: Ялта, Боткинская 23 Г. Г. Ибрагимов. Мәскәүдәге почтада сугылган мөһердә «Москва, 53 Сокольнический 3. 7. 36. 10 час.» диелгән.

[2] *Татгосиздат минем Мәскәүдә урысча басылган әсәрләремне Казанда икенче тапкыр басарга карар иткән* – сүз шушы әсәрләр хакында бара: Ибрагимов Г. Дети природы (Авторизированный перевод) / Г. Ибрагимов // Сборник татарской литературы (дореволюционный) / Под ред. П. Радимова, с предисловием П. Когана.– М.-Л.: Гос. изд-во худож. лит-ры, 1931.– С. 78–92; *Аныкы ук.* Старый батрак (авторизированный перевод) / Г. Ибрагимов // Сборник татарской литературы (дореволюционный) / Под ред. П. Радимова, с предисловием П. Когана.– М.-Л.: Гос. изд-во худож. лит-ры, 1931.– С. 92–107; *Аныкы ук.* Глубокие корни: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой, вступительная статья И. Бороздина / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1931.– 205 с.; *Аныкы ук.* Дочь степи: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1934.– 130 с.; *Аныкы ук.* Татарка: Роман / Перевод с татарского Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: Гос. изд-во «Художественная литература», 1935.– 174 с. Ләкин ул вакытта алар рус телендә Татарстан дәүләт нәшриятында икенче мәртәбә бастырылмый. Бу эш ул акланганнан соң гына гамәлгә ашырыла.

Сез төзәткәннән соң, мин монда тәҗрибәле урыс редактор белән бергә карап чыгармын һәм Казанга, карап чыккач, үзем җибәрәчәкмен.

Икенче басмаларга да тәрҗемәченең исеме куелачак.

Беренче нәүбәттә «Татарка», «Дочь степи», «Глубокие корни» романнары планга керәләр. Шуларга «Старый батрак» белән «Дети природы» кушылыр. Басылу тәртибе үзгәрергә мөмкин, кайсысын алданрак хәзерләп өлгертсәк, шул китәр.

Минемчә, төзәтәсе урын аз булган әсәр «Казакъ кызы» («Дочь степи») булса кирәк, иң элек «Дочь степи»не эшләп җибәрегез. Бу турыда, әлбәттә, договор ясалып, Сезгә кул куярга җибәреләр, гонорар ачык күрсәтелер. Хат языгыз.

Сәлам белән Г. Ибраһимов.

## Татарстан Совет язучылары союзына[1]

1936. 20. XI. Ялта

Иптәшләр,

Союз аппараты аркылы җибәрелгән «Кызыл Татарстан» (ноябрь 7) номерын алдым. Рәхмәт сезгә.

Бу номерда басылган «Бөек Октябрь турында җыр» кыйммәтле бер әсәр булып чыккан[2]. Монда Бөек Октябрьнең даһи җитәкчеләре, ирешелгән уңышлар җанлы шигъри күренешләрдә бирелгәннәр.

Татар совет шагыйрьләре коллективының бу хезмәтен киң укучы масса эчендә тарату чарасын күрергә кирәк.

Җырда большевик Ямаш[3] белән тимер революционер Вахитов өлешенә бирелгән сүзләрне совет укучылары, шиксез, бик шатланып каршы алырлар. Мәгълүм, троцкийчы[4] шайка татарның бу ике кадерле каһарманы өстенә еллар буенча пычрак атып килүләре массаны бик рәнҗеткән иде.

Ком[мунистлык] сәлам белән: Галимҗан.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Ачык хат карточкасына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында (б. 108), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 225) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Бу номерда басылган «Бөек Октябрь турында җыр» кыйммәтле бер әсәр булып чыккан* – Bөjek Oktəbr turьnda çьr // Qьzьl Tatarstan.– 1936.– 7 nojəbr. Аннары ул «Совет әдәбияты» һәм «Пионер каләме» журналларында бастырыла: Bөjek Oktəbr turьnda çьr // Sovet ədəbiatь.– 1936.– № 9–10.– B. 3–10; Bөjek Oktəbr turьnda çьr. Tatar sovet şaƣirlərenen̡ kollektif əsəre // Pioner qələme.– 1936.– № 11.– B. 4–16. Соңыннан аерым китап итеп бастырыла: Bөek Oktəbr turьnda çьr. Jan̡a basma. Qazan: Tatgosizdat, 1937.– 46 b. Бу коллектив әсәрне иҗат итүчеләр: Әхмәт Фәйзи (1903–1958), Әхмәт Исхак (1905–1991), Фатыйх Кәрим (1909–1945), Галим Мөхәммәтшин (1911–1941), Гадел Кутуй (1903–1945), Нур Баян (1905–1945), Салих Баттал (1905–1995), Шәйхи Маннур (1905–1980), Кави Нәҗми (1901–1957), Хәсән Туфан (1900–1981), Зыя Гәрәй (?–?).

[3] *Ямаш* – Ямашев Хөсәен Минһаҗетдин улы (1882–1912), инкыйлаб хәрәкәте эшлеклесе.

[4] *...троцкийчы* – Россия һәм халыкара коммунистик хәрәкәт, партия һәм дәүләт эшлеклесе Лев Давыдович Троцкий (чын фамилиясе Бронштейн) (1879–1940) исеме белән бәйле. Аның карашлары «марксизм-ленинизмга һәм халыкара коммунистик хәрәкәткә каршы сәяси идеологик вак буржуаз агым» дип игълан ителә. Репрессия елларында совет хакимияте тарафыннан кешеләрне гаепләү өчен киң кулланыла.

## 1937
## Татарстан Совет язучылары союзы альманах редакциясенә[1]

8 гыйнвар 1937 ел

Хатыгызны алдым. Альманах өчен әдәби бер материал җибәрә алырмын дип өметләнәм. Зур әсәрдән берничә табаклык кисәк яки «Фронттан кайткач» атлы хикәя җибәрермен дигән уйдамын[2].

Тик кечкенә бер шарты бар: һәрвакыт тынычсызлып, хәлсезләп торган газаплы авыруымны бик аз булса да җиңеләйтә алуым кирәк. Чөнки җибәрергә өметләнгән материалны күңел теләгән рәвешкә китерү өчен аны бераз эшлисе-аклыйсы бар.

Ком[мунистлык] сәлам белән: Г. Ибраһимов.

1937. 8. I. Ялта.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли архивында саклана (Р-7083 ф., 1 тасв., 50 эш, 97 кәг. Төп нөсхә). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 225) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Фронттан кайткач» атлы хикәя җибәрермен дигән уйдамын* – Г. Ибраһимовның хатыны Х. Фәтхуллина тарафыннан «Кызыл таң» газетасының 1967 елгы 10 март санында бастырылган «Тарих мине онытмас!» исемле мәкаләсендә әдипнең Казанга китап нәшриятына «Солдаттан кайткач» дигән хикәясен җибәрүе хакында мәгълүмат китерелә. Бу, бәлки, «Фронттан кайткач» әсәренең ялгыш аталуы гына да булуы ихтимал. Ләкин шул чорда чыккан альманахларда Г. Ибраһимовның тегеләй дә, болай да аталган әсәре юк.

# ТЕЛЕГРАММАЛАР

## 1918

## Г. Ибраһимовка Уфадан ашыгыч телеграмма[1]

9 июнь 1918 ел

Уфадан ашыгыч телеграм:

«Мәркәз Мөселман комиссариаты әгъзасы иптәш Галимҗан Ибраһимовка.

Кичекмәенчә Уфага килергә чык. Үзәк белән бергә Казандагы милли эшләр комиссариатыннан да бер вәкил ал. Вахитов Казанга кайткан булса, аны да алып кил. Калигаев Уфага килергә чыкмаган булса, аны да килергә өндә. Калигаевның Уфада булуы бик зарур. Әхвать бик җитди.

Уфа милли эшләр комиссары Ягушин».

Бу телеграмны алгач, Галимҗан Ибраһимов һәм Казан милли эшләр комиссары Сәетгалиев[2] иптәшләр Уфага сәфәр иттеләр.

*«Мөхбир»*

---

[1] Беренче мәртәбә «Кояш» газетасының 1918 елгы 9 июнь санында дөнья күрә. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 203» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Сәетгалиев* – Сәетгалиев Сахибгәрәй Сәетгали улы (1894–1939), дәүләт эшлеклесе. 1918–1919 елларда Казанда милләтләр эше буенча комиссар. 1920–1921 елларда – Вакытлы революцион комитет рәисе, соңыннан Татарстан АССРы Халык комиссарлары Советы рәисенең беренче урынбасары.

## 1919
## Телеграмма Г. Ибрагимову о назначении его лектором Восточного поезда[1]

6 февраля 1919 г.

Телеграмма
Срочно Казань Центромусульманколлегии
Галимжану Ибрагимову
Казань. Москвы 60 173 43 6/II 1919 г[ода]

Недели через три отправляется [в] Туркестан особый Восточный поезд, который там пробудет три-четыре месяца точка Вы назначены и утверждены Ц[ентральным] Бюро Комвостока и ЦК РКП(б) лектором точка Будьте готовы по получении вторичной телеграммы срочно выехать [в] Москву 1786 Товпред Цбюро *(подпись неразборчива)*.

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 32 кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитет РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 283). Текст күчермәдән алынды.

## Мирсәит Солтангалиевнең Уфадан Г. Ибраһимовка телеграммасы[1]

19 февраль 1919 ел

Уфадан ашыгыч телеграм.

Галимҗан Ибраһимовка. Февраль 19.

Кичә сәгать унбердә Кечек Башкортстан[2] хөкүмәте белән Шуралар хакимияте арасында килешү булды[3]. Социализм ни-

[1] «Эш» газетасының 1919 елгы 21 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Кечек Башкортстан* – 1917 елның 11 ноябрендә Башкорт үзәк шурасының Ш. Ә. Манатов (1893 яки 1892–1936), Ә.-З. Вәлидов (1890–1970), Ф. Дәүләтшин, Җ. Г. Әмиров, Г. Аетбаев, М. Г. Смаков (1885–?), Г.-Ә. В.-М. Хәсәнов (1894–?), И. И. Мутин (1888–1938), Ш. Бабич (1895–1919) тарафыннан имзаланган 1 нче Фәрманы нигезендә төзелә, 15 ноябрьдә имзаланган 2 нче Фәрман белән аның территориясе билгеләнә, Россия составында башкаласы Темәс авылы булган Башкортстан автономиясе игълан ителә һәм шул ук елның 8–20 декабрендә 3 нче Бөтенбашкорт оештыру корылтаенда раслана. 1918 елның гыйнвар аенда Кече Башкортстан дип атала башлый. 1917 елда 9, 1918 елда 13 кантонны берләштерә.

[3] *Кечек Башкортстан хөкүмәте белән Шуралар хакимияте арасында килешү булды* – сөйләшүдә Уфа революцион комитетыннан – рәис Б. Н. Нимвицкий (1885–1969), Ревком рәисе урынбасары, Россия Коммунистлар (большевиклар) партиясенең Уфа комитеты рәисе В. А. Седенков, 5 нче армия Реввоенсоветыннан – И. Н. Смирнов, Республика Реввоенсоветыннан – В. М. Смирнов, Милләтләр эшләре буенча комиссариаттан – М. Х. Сәетгалиев (1892–1940), Башкорт хөкүмәтеннән – хөкүмәт рәисе М. А. Кулаев (1873–1959), Башкорт үзәк шурасы әгъзасы М. Д. Халиков (1894–1937), башкорт гаскәрләре сардары адъютанты Ә. И. Бикбауов (1896–?) һәм сәркятип сыйфатында Георгий Карангачев катнаша.

Шул ук көнне В. А. Седенков, И. Н. Смирнов, М. Х. Солтангалиев, М. А. Кулаев, М. Д. Халиков, Ә. И. Бикбауов, Г. Карангачев катнашында тагын бер сөйләшү була.

19 февральдә ике арада Килешүгә кул куелырга планлаштырылган булса да, ул булмый. Сөйләшүне Сембер шәһәрендә дәвам иттерү билгеләнә.

Билгеле булганча, алга таба, 1919 елның 20 мартында Милләтләр эшләре буенча халык комиссары И. В. Сталин (1879–1953), Башкорт хөкүмәте рәисе М. А. Кулаев, Башкорт үзәк шурасы әгъзасы М. Д. Халиков, башкорт гаскәрләре сардары адъютанты Ә. И. Бикбауов имзалаган һәм Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты рәисе вазифаларын башкаручы М. Ф. Владимирский (1874–1951), Халык комиссарлары советы рәисе В. И. Ленин (1870–1924) тарафыннан имзаланган «Үзәк Совет хакимияте һәм Башкорт хөкүмәте арасында Башкорт Совет автономиясе турында килешүе» нигезендә РСФСРның бер федератив берәмлеге буларак, Кече Башкортс-

гезендә Башкортстан Җөмһүрияте тәэмин ителә[1]. Бу Җөмһүриятнең чикләре Мәскәүдә тәгъйин ителәчәк[2]. Килешүнең шартларыннан берсе башкортларның Советларга каршы сугышны туктатулары һәм Рус-Европа контрреволюциясенә каршы бөтен бер корпус башкорт гаскәре бирүдер.

Бүген сәгать алтыда Сезне прямой проводка чакырам, тәфсыйле[3] шунда булачак.

Мирсәит Солтангалиев.

---

тан чикләрендә Автономияле Совет Башкорт Республикасы төзелә. Бу хакта тулырак кара: «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов» (Уфа, 1959, с. 227–232).

[1] *Тәэмин ителә* – булдырыла, барлыкка китерелә.

[2] *Тәгъйин ителәчәк* – билгеләнәчәк.

[3] *Тәфсыйле* – җентекле аңлатмасы.

## Мирсәит Солтангалиевнең Уфадан Г. Ибраһимовка телеграммасы[1]

21 февраль 1919 ел

Кечек Башкортстан мәсьәләсе турында

Уфадан ашыгыч телеграм.

Галимҗан Ибраһимовка. Февраль 21.

Сезне сул татар-башкорт социалист революционерлары белән мөселман коммунистларының гомуми уртак тактикалары мәсьәләсе мөнәсәбәте белән Уфага чакыралар.

Башкортлардан ике вәкил Башкортстанның чиген[2] билгеләү өчен Мәскәүгә китәләр. Сез кая барырга телисез? Уфагамы? Мәскәүгәме? Буны үзеңез тәгъйин итеңез дә ашыгыч рәвештә җавап биреңез.

Мирсәит Солтангалиев.

Галимҗан Ибраһимов ашыгыч рәвештә Мәскәүгә, аннан Уфага китәдер.

## 1928

## «Эшче» редакциясенең Галимҗан иптәш Ибраһимовка һәм Үзәк юбилей комиссиясенә җибәргән тәбрик телеграммасы[3]

14 март 1928 ел

Бөек тел художнигы, сөекле әдип һәм җәмәгать эшчесе булган Галимҗан Ибраһимовка аның әдәби, иҗтимагый хезмәтләренең егерме еллык бәйрәмен үткәргән тантаналы көндә ялкынлы сәлам җибәрәбез. Без Галимҗан Ибраһимовны иҗади эш һәм дөньяга караш бабларында түбәннән югарыга таба өзлексез рәвештә күтәрелеп барган һәм бара торган бер кеше дип таныйбыз. Аның исеме хәзердә һәм киләчәктә зур хөрмәт ителергә хаклы.

---

[1] «Эш» газетасының 1919 елгы 25 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Башкортстанның чиген* – Автономияле Совет Башкорт Республикасының чикләре хакында тулырак кара: Соглашение между Советской властью и Башкирским правительством о Советской Автономной Башкирии // Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов.– Уфа, 1959.– С. 227–232.

[3] «Эшче» газетасының 1928 елгы 14 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Галимҗан иптәш Ибраһимовның телеграм-хаты Мәскәү, «Эшче» редакциясенә[1]

14 март 1928 ел

Соңгы айларда күп оешмалардан, редакцияләрдән, аерым иптәшләрдән, 20 еллык хезмәтемне котлап, телеграмнар, тәбрикле мәкаләләр алдым. Боларга аерым җаваплар бирергә мөмкинлегем булмаганга, аз хезмәтемне олылап җибәргән котлауларның һәммәсенә матбугат аркылы тирән күңелемнән рәхмәт укыйм. Мин пролетариат революциясенең солдатымын. Бөтен үткән тормышым мине моңар хәзерләде. Үземне үстергән; тарихы, туган теле булган татар халкының гына түгел, дөньядагы барлык изелгән милләтләрнең, сыйныфларның иҗтимагый азатлыклары пролетариат байрагы астында, ленинизм нигезләренчә көрәшкәндә генә мөмкин дип яшәүчеләрдәнмен.

Эшче-крәстиян халкына кирәкле әйберләр биргән булсам, моның сәбәпләре минем шәхси талантымда гына түгел, бәлки революцион массага бәйләнгән булуымда, бигрәк тә тарихның бердәнбер иҗатчы юлбашчы принципларыннан марксизм методларының биргән куәтләрендә, күрсәткән юлларындадыр. Үземне шулай аңлыйм. Телеграмнарда сәламәтлегемне сорыйлар. Акрынлап төзәләм, көчләрем яңадан кайтырлар дип ышанам. Киләчәктә революцион марксизм нигезендә гыйльми, әдәби хезмәтләремне дәвам иттерү өмидендә яшим.

Коммунистлар сәламе белән:
Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] «Эшче» газетасының 1928 елгы 14 март санында урнаштырылган. Текст «Эшче» газетасыннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла. Редакция искәрмәсе: Бу хат татар телендә телеграф аркылы Ялтадан 11 мартта җибәрелгән.

## Галимҗан иптәш Ибраһимовның телеграмы («Кызыл Татарстан» редакциясенә)[1]

14 март 1928 ел

Соңгы айларда күп оешмалардан, редакцияләрдән, аерым иптәшләрдән 20 еллык хезмәтемне котлап, хатлар, телеграмнар, тәбрикле мәкаләләр алдым. Боларга аерым җаваплар бирергә мөмкинлегем булмаганга, аз хезмәтемне олылап җибәргән котлауларның һәммәсенә матбугат аркылы тирән күңелемнән рәхмәт укыйм. Мин пролетариат революциясенең солдатымын. Бөтен үткән тормышым мине моңар хәзерләде. Үземне үстергән; тарихы, туган теле булган татар халкының гына түгел, дөньядагы барлык изелгән милләтләрнең, сыйныфларның иҗтимагый азатлыклары пролетариат байрагы астында, ленинизм нигезләренчә көрәшкәндә генә мөмкин дип яшәүчеләрдәнмен.

Эшче-крәстиян халкына кирәкле әйберләр биргән булсам, моның сәбәпләре минем шәхси талантымда гына түгел, бәлки революцион массага бәйләнгән булуымда, бигрәк тә тарихның бердәнбер иҗатчы юлбашчы принципларыннан марксизм методларының биргән куәтләрендә, күрсәткән юлларындадыр. Үземне шулай аңлыйм. Телеграмнарда сәламәтлегемне сорыйлар. Акрынлап төзәләм, көчләрем яңадан кайтырлар дип ышанам. Киләчәктә революцион марксизм нигезендә гыйльми, әдәби хезмәтләремне дәвам иттерү өмидендә яшим.

Коммунистлык сәламе белән:
Галимҗан Ибраһимов.
Кырым, Ялта.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 14 март санында урнаштырылган. Текст «Эшче» газетасыннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## 1930
## Казань, газеты «Кызыл Татарстан», копия «Красная Татария», копия Комиссариатская, 4, Гришиной-Ахмадеевой, копия Нуретдинову[1]

Получил глубоко прискорбную весть о печальной смерти дорогого друга и товарища Шагида Ахмадееева[2], выражаю свое искреннее соболезнование жене покойного Лидии Гавриловне, братьям и сестрам его в постигшем нас общем тяжелом горе. Ахмадеев был крупным общественником, деятелем, боевым журналистом, долго и упорно боровшимся против татарской буржуазии и националистических организаций. Ахмадеев был самоотверженным работником пролетарской революции и преданным борцом в рядах великой Ленинской партии. Прощай дорогой друг и товарищ Шагид. Галемджан Ибрагимов.

---

[1] Төп нөсхәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемә итеп Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында урнаштырылган (Казан, 2000, б. 162). Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә китерелә.

*Комиссариатская, 4* – хәзерге вакытта Мөштәри урамы, 20 нче йорт.

*Гришина-Ахмадеева* – Лидия Гавриловна Гришина (?–?), Ш. Әхмәдиевнең хатыны, Казанда мәктәп директоры, Татарстан Мәгариф министрлыгында мәктәпләр бүлеге мөдире булып эшләгән.

*Нуретдинов* – Ш. Әхмәдиевнең туганы.

[2] *Получил глубоко прискорбную весть о печальной смерти дорогого друга и товарища Шагида Ахмадееева* – журналист, язучы, беренче Казан губерна Мәгариф халык комиссары, Г. Ибраһимовның иң якын дусларыннан берсе Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев 1930 елның 12 августында иртәнге сәгать 8 дә 40 минутта вафат була. Өстәмә кара: Şəhit ip. Əxmədief // Qzьl Tatarstan.– 1932.– 13 aug.; Ƣl̡imran Z. Şəhit iptəş Əxmədi / Z. Ƣl̡imran // Jaŋalif.– 1930.– № 2.– B. 75; Şэhit Эxmэdief // Jaŋalif.– 1931.– № 2.– B. 40.

## Казань, Большая Галактионовская, 22. Кави Наджмутдинову[1]

Сценировку «Тирен тамрлар» просмотрел. Требуется коренная переработка. Прошу передать директору Таттеатра Закиру Галееву[2], Гиззатову[3], Шамильскому[4]: нужно приостановить подготовку к постановке. Как автор, я поставить данную сценировку категорически не разрешаю[5]. Жду ответа. Ибрагимов.

## 1931
## Г. Ибраһимовның телеграмы[6]

Ялта, 22 (Телеграф буенча). Такташ безнең совет әдәбиятының талантлы зур шагыйре иде. Аның вакытсыз үлеме зур югалту булып тора. Татарстан хезмәт массасы үзенең якты, сизгер чырасын һәм бөек социализм төзелеше өчен көрәштә әдәби союздашын онытмас.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 10 нчы санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 163) татарча тәрҗемәсе урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче тапкыр бастырыла.

*Большая Галактионовская* – хәзерге Горький урамы.

[2] *Закиру Галееву* – Закир Халит улы Галиев (1902–1941), журналист, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә партия һәм эшчеләр бүлеге мөдире була; хат язылган вакытта – Татар дәүләт академия театры директоры.

[3] *Гиззатову* – Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәт (Гыйззәтов, 1895–1955), драматург. Ул «Тирән тамырлар»ның инсценировкасын эшли.

[4] *Шамильскому* – Шакир Әбтелгани улы Шамильский (Вахитов, 1892–1945), актер. Ул «Тирән тамырлар»ның режиссёры була.

[5] *...я поставить данную сценировку категорически не разрешаю* – Г. Ибраһимов рөхсәт итмәү сәбәпле, спектакль сәхнәләштерелми кала. Бары тик 1969 елда Татарстанның 50 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә актёр, режиссёр Хәким Йосыф улы Сәлимҗанов (1903–1981) тарафыннан Татар дәүләт академия театрында куела.

[6] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1931 елгы 10 декабрь, аннан соң «Яңалиф» журналының 1931 елгы 12 нче санында (б. 70), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 169) бастырылган. Текст газетадан алынды.

## 1933
## Галиәсгар Камалның вафаты уңае белән. Телеграмма[1]

22 июнь 1933 ел

Ялта. 17. Тирән кайгы белән зур татар язучысы – драматург Галиәсгар Камалның үлүе турында ишеттем. Галиәсгар Камал 35 ел буена татар драматургиясен тудыру һәм үстерү эшендә армый эшләп, үз иҗатында ул татар буржуазиясе һәм мещанналары өстеннән рәхимсез рәвештә көлде һәм аларның эчке бозык тормышларын фаш итте. Галиәсгар Камал – безнең әдәбиятта татарның масса әдәби теле өчен моннан 35 ел элек ачыктан-ачык көрәшкә чыккан беренче язучы. Галиәсгар Камалның тормышында иң кыйммәтле ягы шунда, ул 1917 елда – сыйнфый көрәшнең иң кискен чорында, икеләнеп тормастан, пролетариат революциясе ягына басты, бөек Ленин партиясе җитәкчелеге астында актив рәвештә совет матбугатында эшләде.

Галимҗан Ибраһимов.

## 1935
## Гайшә Шәриповага[2]

прием 11 го 19 ч. 15 мин. 1/208 передал 616 139

бл. № 28 Ялта

Ялты 68 36 11/3 19 10 Москва 53 Скорняжный 9 кв. 5 Шариповой

Если возможно необходимо заменить Татарку романом Дочь степи тчк прошу срочно телеграфировать с кем договор на какой язык тчк по получения етих сведение немедленно будет выслана телеграфная доверенность = Ибрагимов.

---

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1933 елгы 22 июнь, аннан соң «Совет әдәбияты» журналының 1933 елгы 4–5 кушма санында (б. 95), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 197) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 28. Төп нөсхә). Татар теленә тәрҗемә ителеп беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 145), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 214–215) урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

## Гайшә Шәриповага[1]

прием 8 го 16 ч. 6 м. 1/208 передал 277 139
бл. № 28 Ялта
Москва Ялты 71 29
8/6 14 8 10 Москва 10 Скорняжный переулок 9 кв. 5 Гайше Шариповой

Гослитиздат телеграфировал мне что переводу наши дни приступают третьем квартале тчк перевод поручаю вам и советую начать нужные подготовки = Ибрагимов.

## Татпредставительству[2]

Телеграмма
Прием 25. 13 ч. 48 м.
Принял Муромцева
77 Казани 66.10. 25. 13 = Москва Татпредставительство

Просим содействовать ускорить перевод пенсии Ибрагимову Наркомсобезе=Тагиров.

*Виза кара белән:* т[оварищу] Бресову. Выяснить оформление и ускорить *(имза аңлашылмый)*.

*Виза кызыл кара белән:* Выяснено и сообщено телеграфом. 23/II-28 *(имза аңлашылмый)*.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 29). Татар теленә тәрҗемә ителеп беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1976 елгы 12 нче санында (б. 145), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 216) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-1150 ф., 1 тасв., 41 эш, 261 кәг.). Ул 1928 елның 25 гыйнварында җибәрелгән. ТССР вәкиллегенең штемпеленнән күренгәнчә, 1928 елның 27 гыйнварында кабул ителгән (керү № 1752). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## Казань. Наркомпрос Тагирову[1]

Тридцатого января дано распоряжение номером 1868 переводе Ибрагимову пенсии февраль-март 2980 Исеев[2]

Татпредставительство Старопанский пер[еулок] д[ом] № 1/5 27 февраля 1928.

---

[1] Күчермә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-1150 ф., 1 тасв., 41 эш, 259 кәг.). Телеграмма 1928 елның 27 гыйнварында җибәрелгән. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә басырыла.

[2] *Исеев* – Мөхәммәт Садыйк улы Исиев (1896–?), 1926 елдан Үзәк Башкарма комитеты Президиумында Татарстан вәкиле, Татарстан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы.

# МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР

## 1922
## Әдипләр, шагыйрьләр, басмаханәчеләр дикъкатенә[1]

10, 12 февраль 1922 ел

Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче китабын нәшр итеп[2], бөтен килерен ач балаларга багышларга журналистлар тарафыннан карар бирелде.

Мәҗмуга 10–12 табак зурлыгында булачак. Ун мең басылачак. Һичкемгә һичбер хезмәте өчен һичбер нәрсә түләнмәячәк. Ачлыктан һәлак булып барган эшче-крестьян балаларына кулдан килгән кадәрле ярдәм итүне үзенең бурычы дип белгән язучылар хәзердән үк кулъязмаларын – әдәби хикәяләр, шигырьләрен миңа ашыгыч тапшырулары үтенелә.

Бу икенче мәҗмуганың да кәгазь һәм басу якларын ярдәм юлы белән тәэмин өчен Казандагы сабикъ[3] баширләрдән «Гасыр», «Сабах», «Мәгариф», «Васита», «Милләт»[4], «Корылтай»[5], «Алга» басмаханәчеләреннән, «Өмет»[6], «Борадәрән Кәримовлар»[7], «Татарстан» һәм башкаларның ияләре яки вәкилләренең

---

[1] «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 10, 12 февраль саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче китабын нәшр итеп* – ул китап: Әдәби ярдәм мәҗмугасы.– Казан: Т. С. Ш. Җ. 2 нче номерлы дәүләт басмаханәсендә эшләнде, 1922.– 130 б.

[3] *Сабикъ* – элекке.

[4] *«Милләт»* – Казанда 1908 елның сентябрендә «Идриси, Галиев вә шөрякәсе» китап сәүдәсе ширкәте буларак оеша, шул ук елның 25 ноябреннән мөстәкыйль фирма булып эшли башлый. 1921 елның 1 гыйнварында дәүләт карамагына алына һәм Сигезенче басмаханә дип атала башлый.

[5] *«Корылтай»* – Казанда 1918 елда хосусый ширкәт буларак оешып, 1924 елга кадәр эшләгән нәшрият.

[6] *«Өмет»* – 1911 елда «Сабах» көтепханәсе каршында Габделвәли Әхмәдуллин ачкан басмаханә (1916 ел азакларында И. Н. Харитонов (1859–1954) типографиясе белән берләштерелә).

[7] *«Борадәрән Кәримовлар»* – Казандагы беренче шәхси татар басмаханәсе. Хуҗалары – китап белән сәүдә итүчеләр, наширләр – бертуган Шәрифҗан (1850–?), Мөхәммәтҗан (1853–?) һәм Хәсән (1872–?) Кәримовлар. 1899 елда Кәримовларның китап сату фирмасы эшчәнлеге кысаларында Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан

февраль 14 ндә якшәмбе көн көндез сәгать 12 дә кем үз ихтыяры белән бу мәҗмуга өчен кәгазь һәм басу белән күпме ярдәм итә алуын билгеләү хакында киңәш өчен җыелуларын үтенәм. Җыелу урыны Тукай урамында 31 нче номерлы йортта «Татарстан хәбәрләре» гәзитәсе идарәсендә булачак.

Кулъязмаларын тапшыручыларга адрес: Воскресенский урам, второй дом Советов, 21 нче бүлмә.

Галимҗан Ибраһимов.

---

тарафыннан нигезләнеп, 1900 елда эшли башлый. 1919 елның июнендә басмаханә дәүләт карамагына алына һәм «Мәгариф» басмаханәсе белән кушып, 6 нчы дәүләт басмаханәсе дип атала башлый.

## Каюм Насыйрины искә төшерү[1]

19 июнь 1922 ел

Татарстан Мәгариф комиссариаты Гыйльми Мәркәзе карары буенча 1922 нче елның икенче сентябрендә татарның мәдәни-әдәби хәрәкәте тарихында зур урын тоткан Каюм Насыйри бабаның вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте белән ядкяр көне ясарга карар бирелде.

Бу ядкярне башкару өчен өч кешелек комиссия төзелде.

Комиссиянең хәзердән бу эшкә тотынып, беренче нәүбәттә Каюм Насыйри турында 10–15 табаклык мәҗмуга чыгару чарасына кереште.

Каюм Насыйри турында азмы-күпме мәгълүматы-материалы булган иптәшләрдән комиссия белән мөнәсәбәткә кереп, ядкяр мәҗмугасының тулы чыгуына кулларындагы материаллар, язулар, хатирәләр, китаплар, рәсемнәр һәм башкалар белән ярдәм итүләрен үтенә.

Комиссия рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

Әгъзалары: Сәлах Атнагулов, Газиз Гобәйдуллин.

Адрес: Казань, 2-й дом Советов ком[ната] 21. Г. Ибрагимову.

Башка урыннардагы газеталарның, матбугат гадәтенчә, бу мөрәҗәгатьне күчерүләрен үтенәбез.

[1] «Татарстан» газетасының 1922 елгы 19 июнь санында бастырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә бастырыла.

## 1925

## Әдипләргә, шагыйрьләргә мөрәҗәгать («Татар әдәбияты көтепханәсе» турында кайбер материал кирәк)[1]

4 март 1925 ел

Иске һәм яңа татар әдәбиятын тикшерү, өйрәнү эше хәзерге көндә бик нык бара. Бу турыда мәктәпләрдә дә, түгәрәкләрдә дә эшлиләр. Ләкин бу әдәбияттан күбесенең басылган нөсхәләре матбугат дөньясында бик аз калган яки бөтенләй беткән. Шуңар күрә мәктәпләр, көтепханәләр, аерым өйрәнүчеләр бу турыда материал таба алмый аптырыйлар. Яңа көтепханәләр төзелгәндә дә зур читенлек чыга.

Безгә бөтен татар әдәбиятының искесен, яңасын бер җепкә – бер күренешкә тезеп, билгеле бер систем[а] буенча басып чыгаруның кирәклеге ачык иде. Менә шуларны күз алдында тотып, Гыйльми үзәкнең коллегиясе үзенең [19] 25 нче елның 11 февралендәге мәҗлесендә (пртокол нумир 12) 150–200 табак чамасы күләмендә «Татар әдәбияты көтепханәсе» төзергә карар бирде. Бу көтепханә өчен нигез буларак, һәрбере биш (5) табаклык китап рәвешендә түбәндәге програм кабул кылынды:

Халык әдәбиятыннан: 1) мәкальләр, табышмаклар; 2) такмаклар, бәетләр, җырлар; 3) әкиятләр; 4) ноталары белән үк татар-башкорт җырлары (яңа заман җырлары да кирәчәк); 5) борынгы татар әдәбиятыннан бишәр табаклы ике китап; 6) Акъегетзадә; 7) Заһир Бигиев; 8) Акмулла[2]; 9) Закир Һади[3]; 10) С. Максуди («Мәгыйшәт»[4]); 11) Г. Исхакый; 12) Фатыйх Кәрими; 13) Г. Камал; 14) Г. Тукай; 15) М. Гафури; 16) Г. Ибраһимов; 17) Ф. Әмирханов; 18) Ш. Камал; 19) К. Тинчурин; 20) Думави, Бәшири, Укмасый (Беренче һәм икенче садалар шунда ук); 21) Сүнчәләй, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Вакыйф Җәлал, Нәкый

---

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 8 март, аннан соң «Мәгариф» журналының 1925 елгы 3 нче (б. 120–121), «Безнең юл» журналының 1925 елгы 3 нче саннарында (б. 143), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 119–120) бастырылган. Текст «Безнең юл» журналыннан алынды.

[2] *Акмулла* – Мифтахетдин Камалетдин угылы Акмулла (1831–1895), татар, башкорт, казакъ халкының уртак мәгърифәтче шагыйре.

[3] *Закир Һади* – Закир Хәлиулла угылы Һади (1863–1933), мәгърифәтче язучы, мөгаллим.

[4] *«Мәгыйшәт»* – Мөхәррире: Садретдин бине мулла Низаметдин әл-Максуди. Мәгыйшәт. Милли роман.– Казань: Тип. Торгового Дома Братьев Каримовых, 1900.– 78 б.

Исәнбәт, И. Башмаков[1]; 22) Ф. Сәйфи-Казанлы; 23) Ш. Бабич[2]; 24) М. Фәйзи[3]; 25) Г. Рәхим; 26) Г. Газиз; 27) М. Гали[4], С. Җәлал; 28) Шамил Госманов; 29) Фәтхи Бурнаш; 30) Һади Такташ; 31) Г. Толымбайский; 32) Кави Нәҗми; 33) К. Әмири; 34) М. Максуд[5]; 35) Кутуй; 36) яшь язучылар (яшь әдипләрдән сайлап); 37) Гомәр Галиев; 38) революция җырлары («Интернационал», «Марсельеза», «Бәхилләшү» һәм башкалар ноталары белән).

«Татар әдәбияты көтепханәсе» югарыгы исемлек белән генә, әлбәттә, чикләнмәячәк, бәлки яңа яшь куәтләр туу-күтәрелү белән нумир тәртибенчә шуңа өстәлә барылачак.

Хәзерге көндә безнең бурыч – әнә шул рәвешчә, билгеле бер система белән татар әдәбиятын чыгара башлаудыр. Татарстан Җөмһүриятенең нәшрият комбинаты бу өлкән эшне үзенең беренче нәүбәттәге планына кертте, якын арада чыга башлаячак. Монда югарыгы нумирлар тарих тәртибенчә төзелделәр. Басканда ул тәртип буенча бару, әлбәттә, мәҗбүри түгел. Соңгы нумирларның, җыелып өлгерсә, алдарак чыгуы мөмкин. Бу эштә тоткарлык чыкмасын өчен Гыйльми үзәк әдипләргә, шагыйрьләргә түбәнге үтенеч белән мөрәҗәгать итә:

Югарыда исемнәре булган язучылар 2–3 битлек кенә рәвештә үзләренең биографияләрен (тормышларын, эшләрен, әсәрләрен) һәм рәсемнәрен җибәрсеннәр иде. Материалның тулылыгы өчен әсәрләре белән берлектә болар кушылып басылачаклар.

Бу материаллар бары да «Казан, Наркомпрос, Гыйльми үзәк» адресы белән «Әдәбият комиссиясенә» дип җибәрелсеннәр.

Гыйльми үзәк председателе:
Галимҗан Ибраһимов.
Гыйльми үзәк секретаре:
Заһид Нуркин.
4 март, 1925 ел.

[1] *И. Башмаков* – Ибраһим Башмаков (Ибраһим Йосыф улы Башмаков) (1893–1913), шагыйрь.

[2] *Ш. Бабич* – Шәехзадә Бабич (Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабич) (1895–1919), шагыйрь.

[3] *М. Фәйзи* – Мирхәйдәр Фәйзи (Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзуллин) (1891–1928), драматург, шагыйрь, фольклорчы.

[4] *М. Гали* – Мөхәммәт Гали (Мөхәммәт Вәли улы Галиев) (1893–1952), язучы, журналист.

[5] *М. Максуд* – Мәхмүд Максуд (Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов) (1900–1962), язучы һәм тәрҗемәче.

## Члену бюро ОК Зие Насырову[1]

19 апреля 1927 г.

Перевод моей книги о татарской культуре, насколько мне известно, уже разослан всем членам бюро ОК, поэтому считаю необходимым заявить следующее:

Тов[арищ] Губайда хороший переводчик с русского на татарский язык, как первый опыт на очень сложную тему вышел далеко неудовлетворительным. В отношении стилистики и литературного русского языка, перевод не выдерживает никакой критики. Марксистическая терминология не выдержана, и поэтому мои мысли облечены в до неузнаваемости грубые формы.

Во многих местах встречаются совершенно ошибочно, подчас совершенно противоречащее оригиналу понимание и толкование переводчиком моих мыслей. Что касается предисловия («от составителя»), то тут оно так извращено и перепутано, что я сам не узнал своих мыслей.

Состояние моего здоровья не позволяет мне заняться исправлением – редактированием данного перевода и поэтому я вынужден ограничиться только следующим заявлением:

Обсуждение моей книги по данному периоду я, как автор, считаю невозможным и недопустимым.

Галимджан Ибрагимов.
19/IV – 27. г. Казань.

---

[1] Б.Ф. Солтанбәковның «Татарстан XX век. Личности, события, документы. Книга вторая. События. Документы. Публицистика / Книга для учителей.– Казань: Татар. респ. изд-во «Хэтер» (ТаРИХ), 2003» дигән китабында бастырылган (б. 211). Текст шуннан алынды.

## Марксист язучыларга
## (Тарихи материализм буенча китаплар кирәк)[1]

Бүгенгәчә татар телендә тарихи материализм нәзарияләрен тулы рәвештә ачып биргән һичбер китап юк. Бу, әлбәттә, безнең матбугат дөньясы өчен бик зур кимчелек һәм бушлык.

Моннан 2–3 ел элек РКПнең Татарстан Өлкә комитеты коммунист татар язучыларыннан берсенә бу турыда әсәр язуны тапшырган иде. Билгеләнгән вакыт әллә кайчан үтте. Ләкин иптәшнең башка күп эшләр белән мәшгульлеге сәбәбеннән китап языла алмады.

Хальбуки, мәктәпләргә, курсларга дәреслек өчен дә, халык өчен дә мондый әсәрләргә ихтыяҗ бик зур.

Мәскәүдә Сарабьяновның[2] китабы белән Бухаринның[3] «Тарихи материализм»ының кайбер җирләре тәрҗемә ителгән дип хәбәр иттеләр. Ләкин башка күп турыларда тәрҗемә белән канәгатьләнергә дә мөмкин булса да, тарихи материализм юлында эшче-крәстиян массасының теләгени тәрҗемә белән генә үти алмыйбыз: бу нәзариянең нигезләре ачык, тулы аңлашылсын өчен бу ысул чыннан да тормышны анализ, мәсьәләләрне чишүдә туры корал булсын өчен тарихи материализм нигезләрен өйрәнгәндә, өйрәткәндә татар эшче-крәстияннең сүзенә якын тормыштан мисаллар алынырга, урыс, Яврупа марксистлары китергән моментлар белән генә тукталмыйча, безнең массаның тирә-юнендә күренгән Көнчыгыш ислам-татар дөньясының мисаллары, фактлары материал ителеп тикшерелергә тиешле. Чөнки шулай итмәгәндә, бу нәзария көндәлек мәсьәләләрне тикшерергә, аңларга практически ярдәм бирүче бер корал була алмый. Әмма коры тәрҗемә биргәндә әсәрнең мона бу моменты үтәлә алмый. Шуңар күрә, төп әсәрләрне тәрҗемә белән бергә татар массасының аңлавынча җайлап, аның үзе белгән, үзе аң-

---

[1] «Безнең юл» журналының 1925 елгы 4 нче (б. 186–187), «Мәгариф» журналының 1925 елгы 3 нче (б. 121–123), «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 4 нче апрель саннарында урнаштырылган. «Безнең юл»дан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Сарабьянов* – Владимир Николаевич Сарабьянов (1886–1952), марксист философ.

[3] *Бухарин* – Николай Иванович Бухарин (1888–1938), сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1929). Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган (1988).

лаган материаллар, идеологияләр буенча анализлар ясап, татарча тарихи материализм әсәрләре кирәк. Масса белән бик якын торган татар укытучылары өчен мондый әсәрләрнең кирәге үткенләште. Алар моны бик сорыйлар.

Мона шуларны күз алдында тотып, Татарстан Халык мәгариф комиссариатының Гыйльми үзәге яшь, карт татар марксист язучыларның һәммәсенә бу турыда мөрәҗәгать итәргә тиешле тапты.

1 – Югарыда әйтелгән рәвешчә, татар телендә тарихи материализм нәзариясен өйрәтүче китаплар чыгару чарасын күрергә кирәк. Бу нәзариянең һәммә моментларын эченә алган бер тулы әсәр рәвешендә, шулай ук мәсьәләнең аерым бер моменты турындагы монографияләр рәвешендә языла ала.

2 – Бу эшкә гыйльми хезмәт, гади әсәр язуга караганда күп артык керәчәк булганга, әсәрләргә гади гыйльми оригиналь китапларга түләгән кадәр (табагына 70–80 сум) гонорарны Татарстанның нәшрият комбинаты түләү өстенә Гыйльми үзәк үз тарафыннан табагына илле сум кадәр акча арттырып түләргә вәгъдә итә.

3 – Бу юлда эшләгән, эшләүче, эшләргә теләгән марксист язучылар үзләренең план, програмнарын яки конспектларын, яки әсәрләреннән бер өлешен җибәрсеннәр иде. Параллелизм булмасын өчен шулар эчендә сайланып берничә иптәш белән әсәрләрне яздыру турында договор ясарга булыр.

4 – Бер әсәр чын гыйльми оригиналь, бер әсәр масса өчен гыйльми-популяр булуы күздә тотыла. Планнарын җибәрүчеләр шуны хәтергә алсыннар иде. Һәммә хәбәрләшүләр: Казан, Наркомпрос, Гыйльми үзәк адресы белән булачак. Хәбәрләшүнең тиз арада тәмам булуы матлуб.

Гыйльми үзәк исеменнән: Галимҗан Ибраһимов.

(Башка гәзитләр моны күчереп бассыннар иде) Г. И.

## 1926
## В Главполитпросвет Башнаркомпрос от редакции журнала «Безнең юл»[1]

10 сентября 1926 г., г. Казань

Как Вам известно, журнал «Безнең юл», издаваемый в Казани как орган Татнаркомпроса, в настоящее время является единственным литературно-художественным и научно-общественным журналом на татарском языке по всему Союзу СССР.

Декабря прошлого года на основании чего при отделе ЦК ВКП(б) было принято особое постановление об оставлении этого журнала, как журнала всесоюзного значения для татарского литературного мира. В связи с этим постановлением журнал «Безнең юл» существенно изменил свой характер, как в смысле привлечения все больше и больше литературных сил. В журнале «Безнең юл» участвуют не только казанские писатели (и вообще писатели Татреспублики), но и писатели из других восточных республик и областей. В области литературных форм и техники журнал «Безнең юл» за время своего пятилетнего существования являлся тем зеркалом, которое отражено все литературные течения, имеющиеся в тат. литературе.

Но несмотря на все вышеизложенные, в области распространения этого журнала мы имеем неудовлетворительный успех. Причиной этого неудовлетворительного успеха, главным образом, является то, что соответствующие культурно-просветительные учреждения недостаточно обращают внимания на подписку этого журнала как для самих, так и для своих подведомственных культурно-просветительных единиц (библиотеки, клубы, избачи, красные уголки, школы и т.п.).

Принимая во внимание близость начала нового хозяйственного года, редакция «Безнең юл» обращается [к] Вам с просьбой о включении журнала «Безнең юл» в список тех изданий, которое Вами будет выписываться с начала этого хозяйственного года для Ваших подведомственных культурно-просветительных единиц.

Ответ[ственный] редактор журнала «Безнең юл»: *(подпись Г. Ибрагимова)*

Ответств[енный] секретарь: *(подпись Гумера Галиева)*

---

[1] Төп нөсхә Башкортстан Республикасының Милли архивында саклана (Р-798 ф., 1 тасв., 1792 эш, 12 кәг.). «Безнең юл» журналының грифле рәсми кәгазенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 313). Текст төп нөсхәдән алынды.

# АВТОГРАФЛАР

## 1919
## Габделәхмәт Сөләймановка[1]

3 сентябрь 1919 ел

1919, 3 сентябрь – Солтанморат

Габделәхмәт иптәш Сөләймановка[2] Сибириядә 1919 елдагы революциясендә подпольный хезмәттән исән-сау кайтуның ядкяре.

Галимҗан Ибраһимов.

## 1920
## Үзбәк Алпаровка[3]

Май 1920 ел

Өч елдан соң кызыл баһадир улачак Үзбәк Алпаровка[4] ядкяр.

Галимҗан – май – 1920, Казан.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның Колчак тылыннан йөреп кайткач киемнәрен дә алыштырмый алдырылган фотосының икенче ягына язылган. Г. Сөләйманов тарафыннан болай дип тә язып куелган: «Алгучы Сөләйманов Әхмәт. 1919 нчы ел алдым Галимҗан туганның революция вакытында төшкән карточкасын 1919 ел 20 сентябрьдә алдым. Карточканы алгач бик шатландым. Сөләйманов Әхмәт».

Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Ә. Сөләйманов (1885–1962)* – Г. Ибраһимовның яшьлек дусты, Солтанморат-тан өч кенә чакрымдагы Әпсәләм авылыннан.

[3] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» (Казан, 1919) дигән китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 104), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[4] *Үзбәк Гыйбадулла улы Алпаров (1914–2003)* – РСФСР һәм ТАССРның атказанган төзүчесе, инженеры.

## 1921
## Ташкенттагы «Белем йорты»нда ачылган татар бүлегендә укучы яшьләргә[1]

2 июль 1921 ел

Казан, 1921, июль 2.

Ерак Төркестан илләрендә яшәүче, шунда укып, халыкны агарту хезмәтенә хәзерләнүче яшь иптәшләргә Тойгы туташ Исхакова[2] аркылы үз революционерлык сәламнәремне күндерәм.

Галимҗан Ибраһимов.

## Газиз Гобәйдуллинга[3]

26 май 1922 ел

Г. Газиз иптәшкә ядкяр итәм – Галимҗан Ибраһимов. 1922 – май 26, Казан.

---

[1] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1957 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 106), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[2] *Тойгы туташ Исхакова* – Мәрьям Шәйхетдин кызы Исхакова (1905–1985), партия-совет хезмәткәре. Тойгы – аның псевдонимы.

Ташкенттагы «Белем йорты»нда ачылган татар бүлегендә укучы М. Исхакова 1921 елның җәендә Казанга кайта. Г. Ибраһимов белән очрашкач, аңа үзе белән бергә укучы татар яшьләренең сәламен тапшыра. Әдип Төркестанда укучы якташларыбызның тормышлары, укулары, белемнәре белән кызыксына, мәктәпне тәмамлаганнан соң, аларны Татарстанга хезмәткә кайтырга чакыра һәм бу мөрәҗәгатьне язып җибәрә.

[3] Төп нөсхә дәүләт фәнни бюджет учреждениесе «Татарстан Фәннәр академиясе» «Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган берәмлегенең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Автограф Г. Ибраһимовның «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (Казан, 1922) китабының эчке битенә язылган. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1987 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 110), «Тулпар» журналының 2012 елгы 3 нче санында (б. 53), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1924
## Сәид Вахидовка[1]

1924 ел

Сәид Вахидов[2] иптәшкә. Г. И.

## 1925
## Муса Җәлилгә[3]

Февраль 1925 ел

Яшь шагыйрь Муса Җәлил иптәшкә ядкяр итәм. Галимҗан Ибраһимов.

1925 – февраль.

## «Кызыл Татарстан» редакциясенә[4]

1925 ел

«Кызыл Татарстан» редакциясенә. Г. И.

---

[1] Төп нөсхә Казан (Идел буе) федераль университетының Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең сирәк кулъязмалар һәм китаплар бүлегенең Шәрык бүлекчәсендә саклана (Т0126623). Автограф Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (М., 1924) дигән китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә С. Вахидовның (Вахидиның) улы Нәзиф Вахитов (?–?) тарафыннан «Приборостроитель» газетасының 1967 елгы 13 март санында рус телендә бирелгән. Аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст китаптан алынды.

[2] *Сәид Вахидов* – Сәидгаттар Габделмәннан улы Вахидов (Вахиди) (1887–1938), археограф, тарихчы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Автограф Г. Ибраһимовның «Пролетариат әдәбияты турында» (М., 1924) дигән китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Шәмси Хамматовның (1920–1989) «Муса Җәлил, аның каләмдәшләре» (Казан, 1986) дигән китабында (б. 4; 97), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 118), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст Ш. Хамматов китабындагы фотокүчермәдән алынды.

[4] Төп нөсхә Россия Фәннәр академиясе Казан Фәнни үзәгенең Фәнни китапханәсендә саклана (7830). Автограф Г. Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Беренче бүлек (1905)» (Казан, 1925) дигән китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1926
## Фәрид бәйгә[1]

Февраль 1926 ел

Кадерле Фәрид бәй иптәшкә ядкяр булсын.

Галимҗан Ибраһимов.
1926-февраль-Баку.

[1] Төп нөсхә Истанбул шәһәренең Бөекшәһәр бәләдиясендәге (мэриясендәге) Ататөрек китапханәсендә саклана. Берничә мөһердән аңлашылганча, ул М. Җәүдәтнең хосусый китапханәсендә дә булган. Автограф Г. Ибраһимовның «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Беренче бүлек (1905)» (Казан, 1925) дигән китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 11 март, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 март саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

Китап Г. Ибраһимов 1926 елның февраль-март айларында Бакуда үткәрелгән Беренче тюркология корылтаена баргач бүләк ителгән булса кирәк.

## 1928
## Гайшә Шәриповага[1]

1928 ел

Хөрмәтле Гайшәгә Кырым ядкяре: Галимҗан.

1928 – Ялта

## Сәйфи Кудашка[2]

1928 ел

Шагыйрь Сәйфи Кудашев иптәшкә.

Г. И
1928 – Ялты

---

[1] Төп нөсхә дәүләт фәнни бюджет учреждениесе «Татарстан Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе «Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган берәмлегенең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (89 ф., 4 тасв., 101 эш). Автограф Г. Ибраһимовның почта карточкасына эшләтелгән фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә «Тулпар» журналының 2012 елгы 3 нче санында (б. 52), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә С. Кудашның шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның хезмәт эшчәнлегенә 20 ел тулу уңае белән рус телендә чыгарылган «Галимджан Ибрагимов. Статьи П. С. Когана, А. Н. Самойловича, Н. Н. Фирсова, И. Н. Бороздина и А. Саади» (Казань, 1928) дигән китапның титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 147), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды.

## 1931
## Бертуган абзыйсы Шакирҗан Ибраһимовка[1]

1931 ел

Шакирҗан абзый.

Мәрхүм балабыз кадерле Рөстәмнең күмү көнендә[2] алынган кайгы рәсемен сиңа җибәрәбез.

Галимҗан,
Гөлсем
1931 – Ялта

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Вафат булган улы Рөстәмне җирләр алдыннан соңгы тапкыр алдырылган фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 169), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *...Рөстәмнең күмү көнендә...* – 1926 елның 5 ноябрендә туган уллары Рөстәм бу дөньяда нибары 4 ел, 4 ай, 16 көн яшәп, каты авырудан соң 1931 елның 21 мартында вафат була, 23 март көнне җирләнә. Хәзерге вакытта аның кабере билгеле түгел, үлеме хакындагы шәһадәтнамәнең күчермәсе генә сакланган: «Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых» (Казань, 2012, с. 297).

## Мәрхүм улы Рөстәмнең соңгы фотосы артында[1]

23 март 1931 ел

Рөстәм Ибраһимов. Күмеләсе көн.

1931 – март 23. Ялта.

## 1932
## «Безнең көннәр» романының рус телендә чыгачак басмасы өчен Г. Шәриповага җибәргән фотосында[2]

1932 ел

1932 е. Ялта. Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана (ДВХ – 8/447). 21 март көнне вафат булган улы Рөстәмне җирләр алдыннан соңгы тапкыр алдырылган фотосының икенче ягына латин хәрефләре белән язылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 31). Г. Ибраһимов фотосының икенче ягына язылган. Фото «Безнең көннәр» романының рус телендә чыгачак басмасы өчен Г. Шәриповага җибәрелгән булган. Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## Туганы Җиһан Тулунгузинага[1]

8 июль 1932 ел

Кадерле Җиһан туганга Ялтада очрашу ядкяре.

Галимҗан
1932. 8. VII.
Ялта

## Туганы Мохтар Ибраһимовка[2]

8 июль 1932 ел

Кадерле Мохтар!

Сиңа уртак дус Шәһит мәрхүм белән бергә төшкән бу рәсемне җибәрәм.

Минем хәл яхшыра, үлемне җиңәргә дигән көрәшләрем нәтиҗәсез булмады – хәзер инде авыруның куркыныч дәвере кичте, инде ныгып эшкә башлау заманнары якынлый.

Сагынып сәлам: Галимҗан
1932. 8. VII.

## Туганы Габделхак Ибраһимовка[3]

29 август 1932 ел

Габделхак туганга Ялтада очрашуның истәлеге.

Галимҗан
1932. 29. VIII.
Ялта

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның утырып төшкән фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 173), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимов белән Ш. Әхмәдиев бергә утырып төшкән фотоның икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 173), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[3] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе дәүләт фәнни бюджет учреждениесе «Татарстан Фәннәр академиясе» «Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган берәмлегенең Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана (65 ф., 5 тасв., 19 эш). Автографны Г. Ибраһимов үз фотосының икенче ягына язган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 174), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

## 1934
## Гыйбадулла Алпаровка[1]

27 декабрь 1934 ел

Гыйбадулла, бу нәрсәнең урысчасына күз салып кара әле.

Галимҗан.
1934. 27. XII.
Ялта

## Гослитиздат. Москва. В редакцию Альманаха «Творчество народов СССР»[2]

1934 г.

Гослитиздат. Москва. В редакцию Альманаха «Творчество народов СССР» от Галимджана Ибрагимова. Отрывок из романа «Наши дни» под названием: «Кавказлы Герей Султан». Семь глав. 52 стр.

СССР халыклары иҗаты альманахы өчен. Кавказлы Гәрәй Солтан («Безнең көннәр» романыннан). Галимҗан Ибраһимов.

Галимҗан Ибраһимов
Кавказлы Гәрәй Солтан
(«Безнең көннәр» романыннан)

---

[1] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романының Г. Шәрипова тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп «Дочь степи» (М., 1934) исеме белән басылган китапның титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 212), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694а-165. Л 1559). Г. Ибраһимовның 1934 елда Казанда нәшер ителгән «Безнең көннәр» романының яңа редакциядәге икенче басмасы китабының титул битеннән алдагы чиста һәм 5 нче битләргә язылган. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## 1936

## Гыйбадулла Алпаровка[1]

27 февраль 1936 ел

Гыйбадулла туган Алпаровка.

Галимҗан.
Ялта, 1936. 27. II.

## Гайшә Шәриповага[2]

7 март 1936 ел

Хөрмәтле Гайшә Шәрипова иптәшкә.

Г. Ибраһимов
1936. 7. III.
Ялта

[1] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» романының Г. Шәрипова тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп «Татарка» (М., 1935) исеме белән басылган китапның титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 219), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (125694[а] – 33). Автограф Г. Ибраһимов фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Шәрипова тарафыннан «Казан утлары» журналының 1967 елгы 3 нче санында (б. 129), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 16 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 22 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

# КӨНДӘЛЕКЛӘР

## Шамил Госманов көндәлекләреннән[1]

29/III – 27. ...Галимджан болеет. Судя по его письмам, безнадежно.

Помню, в 21-м и 22 году по приезде из Ташкента я заболел тифом и в ожидании скорой смерти написал завещание. В нем говорилось: «Знаю, что после моей смерти Галимджан будет меня расхваливать. Мое последнее желание – не помещайте в газетах его лицемерные дифирамбы. А также прошу не допускать к участию в моих похоронах Галимджана и других левых эсеров». Думаю, у Галимджана в мой адрес тоже заготовлено что-нибудь подобное.

29/III – 27. ...Если в повседневной жизни мы относились друг к другу в общем доброжелательно, то на общественной арене нас разделяла непримиримая вражда. Она особенно усилилась после тюркологического съезда, когда Галимджан из лагеря латинистов вдруг переметнулся к арабистам. Этим он окончательно оттолкнул меня от себя.

9/VI – 28. Интересно, почему у некоторых я вызываю враждебные чувства? Временами это всплывает на поверхность так отчетливо. Собственно, не я сам, а скорее моя политическая и творческая деятельность. Одним из тех, кто при каждом удобном случае в тонкой форме высказывает свою ко мне неприязнь, я считаю Галимджана Ибрагимова. Один эпизод. В 3 / 15 / номере «Безнен юл» я выступил с критикой на его «Адэмлэр»[2]. А через неделю подарил ему свою пьесу «Байская дочь» с автографом[3]. Он принял подарок, но потом, оказывается, говорил: «Вот Каин[4], притворяется другом, а сам костерит меня на чем свет стоит». После этого в личных отношениях с ним я стал соблюдать осторожность.

---

[1] «Казань» журналының 1998 елгы 2 нче санында Ш. Госмановның кызы Айсылу Сагайдак-Усманова тарафыннан «Дневник комиссара» дигән исем белән бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *...я выступил с критикой на его «Адэмлэр»* – кара: Госманов Ш. «Адәмнәр» / Ш. Госманов // Безнең юл.– 1924.– № 3 (15).– Б. 149–150.

[3] *... подарил ему свою пьесу «Байская дочь» с автографом* – Усманов Ш. Бай кызы. Пьеса 4 пәрдәдә / Ш. Усманов.– Казан: Татпечать, 1923.– 63 б.

[4] *Каин (хаин)* – бәдбәхет, юньсез.

В тюркологическом съезде он исподтишка, через Шарафа[1] и других проводил кампанию с целью не допустить меня на съезд. А ведь вначале, когда был в «Латын дуст»[2], он изображал из себя латиниста. Галимджан не одинок. У него целая свита «галимджанистов». Например, глава Академцентра М. Тагиров. Похож на Султан-Гали. Дипломат, националист. Изо всех сил старается продвинуть Галимджана...

24/X – 28. Сегодня сразу после завтрака наняли с Асией[3] извозчика и съездили в соседние деревни Диркей и Ай-Васыл. Диркей бедное, безводное население. Ай-Васыл – его противоположность: красивое, богатое село с хорошими подходами. Обе деревни расположены в горах.

По возвращении встретились у дома с женой Галимджана Ибрагимова. Позавчера я послал ему коротенькое письмо, в котором выражал желание повидаться. Он прислал с женой записку, где в теплых выражениях приглашает нас к себе.

Докладларны татар телендә Нигъмәти, урыс телендә Линсцер иптәшләр ясыйлар. Иптәш Нигъмәти иң башта Ибраһимов иптәшнең нинди мохиттә, нинди икътисади шартлар эчендә эшкә башлавына туктала: «Ибраһимов иптәшнең әдәби хезмәте 2 гә: революциягә кадәр һәм революциядән соңгы чорларга бүленә», – ди һәм, боларга тәфсилле анализ ясап, әдәби әсәрләренең идеология, мөндәриҗә һәм форма якларына, типларына туктала. Ибраһимов иптәшнең революция көрәшләренә катнашуын (шәкертләр хәрәкәте, Киевтәге татар студентлары вакыйгасы), революциядән соң коммунист һәм марксист әдип булып әверелүе турында әйтеп уза.

«Ибраһимов иптәш үзе таныш булмаган һәм үзе хис итмәгән тормыш турында язмады. Язган әйберләрен каты тәнкыйть аша үткәрде. Типларын бик нык җентекләде, әсәрләренең зур күпчелеге авыл, күпчелеге яшьләр тормышыннан алынды.

Ләкин Ибраһимовның хезмәте әдәби иҗат белән генә чикләнми, ул зур әдип булу өстенә чын әдәбият теориячесе, педагог, тарихчы, методист, теория белемен, практиканы бергә бәйләүче гыйльми эшчедер.

Иптәш Ибраһимов кызыл чәчәкләр чәчәргә тырышты һәм чәчте. Ул чәчәкләр яхшы йогынты ясады, яхшы җирлектә калып, безгә кирәкле рәвештә өлгерделәр. Яшьләр иптәш Ибраһимовтан үрнәк алдылар. Без аның хезмәтләрен чын күңелебездән тәкъдир итәбез. Тәмам савыгып, хезмәтләрен дәвам иттерүен телибез», – дип тәмам итә.

Котлаулар.

Линсцер иптәш Ибраһимов иптәшнең иҗатлары һәм иҗтимагый хезмәтләре турында русча доклад ясый. Аннан соң котлаулар башлана. Беренче сүз партиянең Татарстан Өлкә комитеты

---

ның атказанган фән эшлеклесе (1926).

[1] *Линсцер* – Герман Фёдорович Линсцер (1974–1946), әдәбият галиме.

[2] *Г. Рәфыйков* – Габдрахман Вәли улы Рәфыйков (1873–1954), педагог, мәгърифәтче, Хезмәт Батыры (1924).

[3] *Халикъ Садри* – Габделхаликъ Гариф улы Садретдинов (1890–1955), язучы.

агитпроп бүлеге мөдире Әхәт иптәш Әхмитовка бирелә. Ул әйтә: «Иптәш Ибраһимовның хезмәтләре бик күп тармакларга бүленә. Иптәш Ибраһимов революция вакытында совет, җәмәгать эшләрендә дә нык танылды. Ул революциядә вакыйгаларны дөрес аңлады, ерактан күрә белде, туры бәя бирде. Бу интеллигент булган кеше өчен зур эш. Иптәш Ибраһимовның хезмәтләренә бәя биргәндә бу моментка игътибар итәргә кирәк. Без иптәш Ибраһимовның эшләренә сәяси яктан карыйбыз. Безнең кайбер җәмәгать эш[че]ләребез, коммунистларыбыз, матбугатта эшләргә, язарга вакыт юк, диләр. Ләкин иптәш Ибраһимов алай түгел. Безгә иптәш Ибраһимовның күп якларыннан үрнәк алырга кирәк. Без хәзер бөтен күләме белән культура революциясе, культура төзелеше мәсьәләләрен алга куйдык. Мондый моментта иптәш Ибраһимов һәм аның эше бигрәк тә кыйммәтле», – ди.

Моннан соң Татарстан Үзәк Башкармасы секретаре иптәш Баһаветдинов Татарстан хөкүмәте исеменнән адрес укый һәм иптәш Ибраһимовны котлый.

Иптәш Таһиров Татарстан Халык комиссарлары Советы рәисе иптәш Исмаевның эшләр белән мәшгуль булу сәбәпле, тантаналы утырышка килә алмавын белдерә һәм иптәш Исмаевның хатын укый. Шулай ук Татарстан Мәгариф халык комиссариатының адресын укып үтә.

Юбилейгә катнашу өчен Уфадан махсус килгән Башкортстан хөкүмәте әгъзасы һәм «Башкортстан» газеты редакторы иптәш Кәлимуллин (Төхвәт Янәби[1]): «Мин Башкортстандагы төрле оешмалар тарафыннан җибәрелгән адресларны укып, сезнең вакытыгызны алмыйм. Иптәш Ибраһимовның Башкортстан белән багланышы зур. Ул татарга да, башкортка да, туры татарга да эшләде. Башкортлар Галимҗан иптәшне бик нык таныйлар, ихтирам итәләр. Мин аны Башкортстан исеменнән котлап, авыруына кайгы белдерәм, тизрәк эшенә башлавын телим, башкортлар сәламен күндерәм», – ди.

Казан шәһәр Советы әгъзасы Фәрит иптәш Хәсәнов шәһәр Советының иптәш Ибраһимовка түләүсез фатир бирергә, су, электр кебек нәрсәләргә акча алмаска карар чыгарганлыгын белдерә һәм Татар мәдәнияте йорты исеменнән адрес укый.

---

[1] *Кәлимуллин (Төхвәт Янәби)* – Төхвәт Янәби (чын исеме: Төхвәтулла Кәлимулла улы Кәлимуллин) (1894–1938) – башкорт язучысы, 1927–1930, 1932–1937 елларда «Башкортстан» газетасының җаваплы мөхәррире була.

Татарстан профсоюзлар советы рәисе иптәш Боярский, юбилярны котлап: «Бу юбилей Татарстан юбилее генә түгел, бәлки, СССРдагы барлык хезмәт халыкларының юбилее. Без Ибраһимов иптәш коммунист булганлыгы өчен түгел, бәлки, профессор Коган әйткәнчә, азатлык һәм матурлык шагыйре, зур әдип булганлыгы өчен бәйрәм итәбез», – ди.

Комсомолның Татарстан Өлкә комитеты матбугат бүлеге мөдире иптәш Мөбарәкшин: «Иптәш Ибраһимов яшьләргә зур материал бирде. Яшьләр аның әсәрләрен күп укыйлар. Без зур остазыбыздан үрнәк алабыз һәм алырга тиешбез», – ди.

Болардан соң Мәгариф эшчеләре союзының Татарстан бүлеге тарафыннан иптәш Ибраһимовны Хезмәт Каһарманы итү турында карар чыгарганлыгы игълан ителә. Фән эшчеләре секциясе исеменнән иптәш Векслин[1] котлый. Профессор Миславский Казан дәүләт университеты исеменнән адрес укый. Линсцер иптәш Көнчыгыш педагогия институты исеменнән котлап, Шәрык педагогия институты янындагы татар әдәбияты кабинетының Ибраһимов иптәш исеменә аталганлыгын белдерә. Профессор Лурия Ленин исемендәге дәүләт институты исеменнән, СССРның атказанган артисты Литвинов Көнчыгыш музыка техникумы исеменнән котлый. Мөхетдин Корбангалиев Татар педагогия җәмгыяте исеменнән чыгып адрес укып һәм Ибраһимов иптәшнең Педагогия җәмгыятенә фәхри әгъза булып сайланганлыгын белдерә. Зыя Насыйри татар рабфагы исеменнән, Мирза Зәетов театр-сәнгать техникумы исеменнән, Халикъ Садри Татар коммунистлар университеты исеменнән, Камал II[2] Дәүләт татар академия театры артистлары исеменнән котлыйлар. Адреслар укыйлар, байтак адресларны вакыт тарлыктан укырга мөмкин булмый.

Соңыннан Татарстан кантоннарыннан, Ташкент, Нәманган, Әстерхан, Күкчәтау, Саратов, Кызыл Урда, Оренбург, Чиләбе шәһәрләреннән, Донбас татар шахтерларыннан, Махачкаладан, Кырым Наркомпросыннан, «Төрекмәнстан» газетыннан, Нәфис сәнгать фәннәре академиясеннән, Мәскәүнең 2 нче дәүләт

---

[1] *Векслин* – Носон-Бер Залманович Векслин (1897–1942), географ-икътисадчы. 1926–1929 елларда ТАССРның Мәгариф халык комиссары урынбасары. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[2] *Камал II* – Габдерахман Галиәкбәр улы Камал II (1869–1948), актер, режиссер.

университетыннан, академик Бартольд[1] һәм Ольденбургләрдан[2], Германия тюркологларыннан, Германиядәге Кёльн университетыннан, Төркиядән, Ленинградтагы Шәрык институтыннан, Әрмәнстан Наркомпросыннан, «Азат» һәм «Эшче» редакцияләреннән, Себер мәгариф эшчеләреннән, Мәскәү һәм Уфа язучыларыннан, Уфа мәгариф эшчеләреннән, Пензадан, төрле редакцияләрдән, язучылардан, профессор Коганнан, профессор Бороздиннан, тагы башка җирләрдән телеграммалар, адреслар килгәнлеге белдерелә. Вакыт тарлык сәбәпле, боларның бераз гына укыла.

Тантаналы утырыш рәисе иптәш Рәхмәтуллин соңгы сүз сөйли: «Киң хезмәт массасы, укымышлылар, мәдәният дөньясы Галимҗан аганың юбилеен үткәрү эшенә баштан ук иң яхшы караш, җылы күңеллелек күрсәткән иде, – ди. – Бу кичке тантаналы утырыш моны тагын да ачыграк рәвештә күрсәтте. Галимҗан аганың 20 еллык әдәби, мәдәни хезмәтен без иң бөек рәвештә тәкъдир итәбез. Бу бәйрәм – бер кешенең, Галимҗан аганың, бәйрәме булудан бигрәк безнең бәйрәмебез». 20 еллык хезмәтне тәкъдир итеп Художество фәннәре академиясе Галимҗан аганы үзенең әгъзасы итеп сайлады. Мәгариф эшчеләре союзы аның Хезмәт Каһарманы итеп танылуын сорый. Көнчыгыш пед[агогия] институты, Татар педагогия җәмгыяте Галимҗан аганың исемен мәңгеләштерү юлында чаралар күрәләр. Татарстан Мәгариф комиссариаты Көнчыгыш пед[агогия] институты да Галимҗан ага исеменә бер стипендия төзергә карар бирде. Татарстан нәшрияты Галимҗан аганың әсәрләрен (элеккеләрен һәм яңаларын) бастыру юлында чаралар күрә. Шулай итеп, иптәш Ибраһимовның исемен мәңгеләштерү һәм аның эшләрен киң хезмәт ияләре арасында, мәдәни дөньясында уртаклашу өчен чаралар күрелә. Кызганычка каршы, авыру сәбәпле, Галимҗан ага безнең арабызда юк. Хөкүмәт аның терелүенә бөтен чараларны күрә. Татарстан хөкүмәте хисабына терелүгә кадәр аңа Кырым курортында урын бирелде. Үзәк хөкүмәт айлык 180 сум пенсия билгеләде. Сез монда шәһәр Советы вәкиленең игъланын ишеттегез. Шәһәр Советы Галимҗан агага бер квартир һәм буш рәвештә коммуна йомышлары бирә. Галимҗан ага терелеп кайтсын, эшли алсын иде».

[1] *Бартольд* – Василий Владимирович Бартольд (1869–1930), шәркыятьче.

[2] *Ольденбург* – Сергей Фёдорович Ольденбург (1863–1934), шәркыятьче, рус индология мәктәбенә нигез салучыларның берсе.

Тантаналы утырыш исеменнән Кырымга – иптәш Ибраһимовка җибәрелә торган телеграм укылып раслана. Шуның белән утырыш ябыла. Рәсми бүлектән соң Дәүләт татар академия театры иптәш Ибраһимов әсәре булган «Яңа кешеләр»нең беренче пәрдәсен уйныйлар. Аннары атаклы көчләрнең катнашы белән зур күләмдә концерт бирелә.

Тантаналы утырышта сөйләнгән сүзләр һәм концерт бүлекләре Казан радиостанциясе аркылы бирелеп барды.

Тантаналы утырыш рәисе: *(имза юк)* (Рәхмәтуллин)
Секретарь: *(имза юк)* (Г. Галиев)

## Краткий отчет о деятельности Дома татарской культуры с момента организации по 1-е мая 1928 года[1]

Издательский план ДТК на 1927/28 г[од].

Примечание: Кроме указанной выше литературы, будут изданы вне плана... 2) сборник «Галимджан Ибрагимов», приуроченный к юбилею Ибрагимова.

I. Центральная Книжная палата.

Опубликованием через газеты ТР собраны все произведения Г. Ибрагимова – будет организована выставка таковых ко дню юбилея.

II. Научное общество Татароведение.

С 1-го июля 1927 года по 1-е марта 1928 г[ода].

...В настоящее время сдан в печать и скоро будет выпущен в свет № 8 «Вестник»а размером в 15 листов, посвященной 20-тилетнему юбилею Г. Ибрагимова.

III. Татарское педагогическое общество.

...Организована Комиссия по проведению юбилея т[оварища] Ибрагимова; составлена инструкция о проведении юбилея в школах.

VI. Кружок молодых писателей.

...С целью выполнения этой задачи, за отчетный период было проведено ряд докладов и лекций. Причем, некоторые из них, например нижеуказанные, прошли с особенным успехом:

1) Революционные мотивы Г. Ибрагимова.

Зав[едующий] Домом татарской культуры (Хасанов)

Секретарь (Дистанов)

---

[1] Күчермә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-439 ф., 1 тасв., 29 эш, 6, 7, 8, 11, 12 кәг.) Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## 1935
## В ТатЦИК, юбилейной комиссии[1]

20 июня 1935 г[ода]

№ 45.

При сем препровождаются характеристики т[оварищей] Г. Ибрагимова, Ш. Камала, К. Тинчурина, К. Наджми, Г. Галеева, Т. Нигмати, Тулумбайского, И. Газеева и Х. Туфана, рекомендуемых ССП ТР для премирования, в связи с 15-тилетием Татреспублики.

Ответственный секретарь
Правления ССП ТР *подпись* / Х. Ярмухаметов /

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-732 ф., 7 тасв., 19 эш, 541 кәг.). Татарстан Совет язучылары берлегенең рәсми кәгазенә язылган. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## 1936
## Из выступления А. Лепы 27 октября 1936 года[1]

...Теперь о Г. Ибрагимове. Не знаю, как его состояние, можно ли его привезти сюда, можно было бы устроить вечер, немного почествовать человека, ведь он лучший литератор. Есть лучшее его с точки зрения художественности (с места: «Лучше его нет»), тогда давайте приблизим человека, а то все-таки он у вас на отшибе.

Когда М. Горький делал отдельные ошибки, его критиковали, но большая помощь была и со стороны Горького, почему бы с этой точки зрения не воспользоваться Г. Ибрагимовым, почему бы к Ибрагимову не послать некоторых молодых писателей, почему бы с ним не поговорить о том, чтобы эти молодые писатели у него работали, как работали у Горького. Г. Ибрагимов заработал за этот год немало денег, как будто бы 28 тысяч, но это не очень большая сумма. Если бы молодые писатели около одного-двух-трех месяцев поработали с ним, могли бы многому положительному научиться, и на это надо ассигновать определенную сумму денег. Подумайте об этом, а то вы в своей работе зачастую склочничаете вместо такой положительной работы. Г. Ибрагимов. Несомненно, является авторитетом, Г. Ибрагимова знал Горький и уважал его, и пусть молодые писатели поучатся у него.

---

[1] Б. Ф. Солтанбәковның «Татарстан. XX век. Личности / Книга для учителей.– Казань: Татар. респ. изд-во «Хэтер» (ТаРИХ), 2003.» дигән китабында бастырылган (б. 185). Текст шуннан алынды.

*Лепа Альфред Карлович (1896–1938)* – партия эшлеклесе. 1933–1937 елларда ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты 1 нче секретаре. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## Галимҗан Ибраһимовның иң соңгы кулъязмасы[1]

...түгел, бәлки, нык тирәнәйтте дә. Беренче әсәр «Зәки шәкерт...»тә яңа фикер иске реакциягә көрәшсә, «Татар хатыны ниләр күрми?»дә хатын коллыкка каршы көрәшә, бара торгач, бу инде иҗтимагый каршылык, иҗтимагый көрәшләргә әйләнә. Миңа бу турыда Киев хәрәкәте, Киев зинданы байтак тәэсир кыйлды. Аннан соңгы «Көтүчеләр», «Мәрхүмнең дәфтәре», 1914 нче елда язылып тәмам булган һәм үзгәртми басылган «Безнең көннәр» менә шуңа мисал булыр.

Революциягәчә мин ул заманның хәрәкәтенә оппозициядә бардым. Февраль дәвере буржуага каршы тел, каләм көрәше белән үтте, анда яза алмадым. 1918 нче елның башыннан Петербургта (Ленинградта) комиссариаттан башлап тагын Октябрь һәм Совет өчен көрәш белән үтеп, әдәбиятка форсат тимәде.

Бөтен үткән хәятым, яшьтән каты эшләп, бөтен 10–15 ел уку һәм яшь язучы заманнары ачлык-ялангач һәм көрәш белән үткәрүләр мине мәҗбүри рәвештә коммунист активист булуга хәзерләп китерделәр. Минем марксист әдип булуым, пролетариат байрагы астында эшләүне үземә тормышның, гомеремнең төп максуды итеп куеп, шул юлны алуым – бөтен үткән хәятымның тарихи мәҗбүри нәтиҗәләредер.

Әгәр гомер булып та, бу үткән хәятны бер киң рәвештә яза алсам иде, хәзерге яшьләр өчен үткән безнең буынның нинди кыен, тәшкил...

---

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (15 ф., 6 тасв., 6367 эш, 27 кәг.). Ниндидер язмасының сакланып калган бер өлеше. Кәгазьнең өске ягында машинкада «Галимҗан Ибраһимовның иң соңгы кулъязмасы» дип язылган. Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ИСЕМЕН МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ ДОКУМЕНТЛАРЫ

## 1961
## [Уфада урамга Галимҗан Ибраһимов исемен бирү турында][1]

1961 ел

Уфа шәһәр советы башкарма комитеты «Уральский проспект» урамына күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, күп еллар Уфа шәһәрендә эшләгән Галимҗан Ибраһимов исемен бирде.

[1] «Совет әдәбияты» журналының 1961 елгы 2 нче санында бастырылган (б. 158). Текст шуннан алынды.

Башка чыганакта исә әдипнең тууына 80 ел тулу уңае белән 1967 елда Уфада Ибраһимов бульвары барлыкка килүе әйтелә: Узиков Ю., Наймушин П. Как зовут тебя, улица? / Ю. Узиков, П. Наймушин.– Уфа: Башкир. кн. изд-во, 1977.– С. 79.

## 1967
## Чакыру[1]

1967 ел

Хөрмәтле иптәш А. Шамов!

Казан шәһәренең Ленин районы Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы урта мәктәбе Сезне татар әдәбияты классигы, галим һәм революционер Галимҗан Ибраһимовка музей һәм һәйкәл ачылу көненә чакыра.

Музей һәм һәйкәл 6 март көнне 15 сәгатьтә ачыла.

Адрес: Восстание урамы, йорт № 104.

Дирекция

Уважаемый товарищ А. Шамов!

Средняя школа № 89 имени Галимджана Ибрагимова Ленинского р[айо]на города Казани приглашает Вас на открытие музея и памятника классику татарской литературы, ученому и революционеру Галимджану Ибрагимову.

Музей и памятник открывается 6 марта в 15 часов.

Адрес: ул[ица] Восстания, дом № 104.

Дирекция

---

[1] Төп нөсхә Казан шәһәре Мәскәү районының «Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесенең Г. Ибраһимов әдәби музеенда саклана. Текст шуннан алынды.

Казан шәһәре Мәскәү районының «Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә Галимҗан Ибраһимовның музее 1996 елның 10 ноябрендә әдипнең тууына 110 ел тулу уңае белән ачыла (Гимназия директорының Приказы № 67а).

Җәмгыятькә файдалы зур эзләнү-тикшеренү эшләре алып барган, кызыклы экспозицияләр (күргәзмә әсбаплар) булдырган һәм укучыларны тәрбияләүдәге уңышлары өчен гимназиянең Г. Ибраһимов исемендәге әдәби музеена 1999 елда мәктәп музее исеме бирелә (206 санлы Таныклык).

## Г. Ибраһимов исеме бирелде[1]

7 апрель 1987 ел

ТАССР Министрлар Советы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, галим-марксист, татар совет әдәбияты классигы язучы Галимҗан Ибраһимов истәлеген мәңгеләштерү максатыннан, Актаныш районының «Кызыл көч» колхозы членнарының гомуми җыелышы, КПССның Актаныш райкомы бюросы һәм район Советы башкарма комитеты тәкъдимен исәпкә алып, «Кызыл көч» колхозының исемен «Галимҗан Ибраһимов исемендәге» дип үзгәртү турында карар кабул итте.

## 1991

## Решение

## Исполкома Московского районного Совета народных депутатов[2]

г[ород] Казань № 701 от 26 августа 1991 г[ода]

Об открытии татарской гимназии

Рассмотрев предложение Московского районного отдела народного образования по сети учреждений народного образования на 1991 год

Исполком Московского районного Совета народных депутатов

решил:

1. Открыть с 1 сентября 1991 года татарскую гимназию

2. Для размещения гимназии выделить часть помещения,

занимаемого ВССОШ № 13 по адресу: ул[ица] Восстания, дом № 48

3. Порядковый номер гимназии не присваивать, впредь называть

«Татарская гимназия имени Галимзяна Ибрагимова».

Председатель исполкома *подпись* Л. Н. Мурысин

*(Гербовая печать)*

Управляющий делами *подпись* Л. П. Фролова

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 7 апрель санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] Төп нөсхә Казан шәһәре Мәскәү районының «Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә саклана. Фотокүчермәсе беренче мәртәбә «Галимджан Ибрагимов: документы и факты: Галимджан Ибрагимов глазами молодых» дигән китапта бастырылган (Казань, 2012). Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1996
## Приказ № 67а
## по гимназии имени Г. Ибрагимова от 10.11.96 г.[1]

п. 1. К 110-летию со дня рождения открыть музей Галимжана Ибрагимова.

п. 2. Руководителем музея назначить Мубаракшину Насиму Носратовну.

Директор гимназии *(подпись и гербовая печать)* А. М. Давлетшина.

## 1999
## ТАНЫКЛЫК[2]
## № 206

МӘКТӘП МУЗЕЕ ИСЕМЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Казан шәһәре Г. Ибраһимов исемендәге гимназия әдәби музеена

Җәмгыятькә файдалы зур эзләнү-тикшерү эшләре алып барган, кызыклы экспозицияләр (күргәзмә әсбаплар) булдырган һәм укучыларны тәрбияләүдәге уңышлары өчен тапшырыла.

*(Түгәрәк мөһер, имза)*

31 март 1999

## СВИДЕТЕЛЬСТВО
## № 206

О ПРИСВОЕНИИ ЗВАНИЯ ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ

Литературному музею гимназии им. Г. Ибрагимова г. Казани

За большую поисково-исследовательскую работу, создание интересной экспозиции и успехи в воспитании учащихся.

*(Гербовая печать, подпись)*

31 марта 1999

---

[1] Төп нөсхә Казан шәһәре Мәскәү районының «Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә саклана. Текст шуннан алынды.

[2] Төп нөсхәсе Казан шәһәре Мәскәү районының «Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесендә саклана. Текст шуннан алынды.

## 2007
## Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы кую хакында Ялта шәһәре хакимиятенең карары[1]

25 октябрь 2007 ел

Ялта шәһәре хакимияте Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы кую хакында 2007 елның 25 октябрендә 2119 санлы карар кабул итә.

## 2008
## Ялта шәһәрендә Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы куела[2]

21 апрель 2008 ел

Ялта шәһәре хакимияте тарафыннан 2007 елның 25 октябрендә кабул ителгән 2119 санлы карар нигезендә Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка 2008 елның 21 апрелендә истәлек тактасы куела.

---

[1] Османов Д. И. Галимҗан Ибраһимов һәм Кырым / Д. И. Османов // Наследие Галимджана Ибрагимова в контексте многообразия культур: материалы Междунар. конф., посвящ. 130-летию со дня рожд. Г. Ибрагимова / Сост. Ф. Х. Миннулина, А. Ф. Ганиева. – Казань: ИЯЛИ, 2017. – Б. 243.

[2] «Дуслык=Дружба» (Киев) журналының 2008 елгы 6 (71) санында бастырылган (б. 21). Текст шуннан алынды.

# Галимҗан Ибраһимовның тормышы һәм эшчәнлеге хроникасы[1]

**1887**

10 март (искечә 26 февраль). Уфа губернасы Стәрлетамак өязе Өршәкмин волосте (хәзерге Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Солтанморат авылында указлы Гыйрфан мулла Нурмөхәммәт улы (1847–1913) белән Бибхәсәнә абыстай Заһит кызы (1862–1921) Ибраһимовлар гаиләсендә туган.

**1898**

Көз ае. Гыйрфан мулла олы улы Шакирҗан белән Галимҗанны Оренбургка «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга алып бара. Галимҗан анда кабул ителмәгәч, «Вәлия» мәдрәсәсенә урнаштырыла. Соңгысы Оренбургта 1802 елдан эшләп килә торган 1 нче мәчет (хәзерге Левашев урамы, 12 йорт) каршындагы кадими уку йорты. Башта мәдрәсә чыгышы белән Стәрлетамак ягыннан булган Шакир хәзрәт (?–?) карамагында булып, аның вафатыннан соң 1908 елдан мәчеттә имам-хатыйб булган Вәли (Мөхәммәтвәли) Габделгани улы Хөсәенов (1867–1933) исеме белән атала башлый.

**1906**

Вәли мулла мәдрәсәсен ташлап чыга һәм туган авылына кайта.

Көз аенда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә.

**1907**

10, 17 октябрь, 5, 12, 19, 12, 19, 3 декабрь. Казанда «Әлислах» газетасында «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясенең бер өлеше басылып чыга.

17 декабрь. «Әлислах» газетасында «Әлислах мөхбире» имзасы белән «Уфа мәдрәсәләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

**1908**

14, 21 гыйнвар, 9 февраль, 2 март, 3, 28 апрель, 19 май, 10, 17, 24 июнь, 2 июль. «Әлислах» газетасында «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясенең дәвамы бастырыла.

10 июнь. «Әлислах» газетасында «Шәкертләр аһ-зары» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 август. «Әлислах» газетасында «Мөхбиреңез» имзасы белән «Уфа йоклый» дигән мәкаләсе бастырыла.

8, 15, 23 сентябрь. «Әлислах» газетасында «Шәкертләр һәм уку» дигән мәкаләсе бустырыла.

Үзе язганча, «…Беренчедән, мәдрәсәнең программасына һәм укыту системасын тәнкыйть иткән өчен, икенчедән, мәдрәсә идарәсенә каршы еш чыгышлар ясаган өчен һәм, өченчедән, бу мәдрәсәдә укыган чакта «Коръән алладанмы, түгелме?» исемле китап язган өчен» «Галия» мәдрәсәсеннән куыла.

---

[1] Филология фәннәре докторы Р.Ф. Исламов тарафыннан төзелде.

**1909**

«Әлислах» газетасының 57 нче санында «Гыйрфанзадә» имзасы белән «Яңа ел хатирәсе», 26 февраль санында «Уфа, мәдрәсәи «Галиядә» тентү», 64 нче санында «Дустыма» дигән мәкаләләре бастырыла.

Ел ахырында Казанга килә.

Казанда «Үрнәк» матбагасында «Гыйшык корбаннары. Милли хикәя» әсәре «Гыйрфанзадә» имзасы белән нәшер ителә (ел күрсәтелмәгән).

Казанда «Гасыр» нәшриятында «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (32 б.) дигән хикәясе, Оренбургта «Вакыт» нәшриятында «Борынгы ислам мәдәнияте» (139 б.) дигән хезмәте нәшер ителә.

**1910**

12 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Татар матбугаты» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Фикердә инкыйлаб» дигән мәкаләсе бастырыла.

26 февраль, 4 март. «Йолдыз» газетасында «Рәссамлык» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 март. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Галлей киткәннән соң» дигән мәкаләсе бастырыла.

30 март. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Татар теле вә татарча язу хакында бер-ике сүз» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 апрель. «Йолдыз» газетасында «Әдәбият мәсьәләләре. I. Тәгъриф» дигән мәкаләсе бастырыла.

10 апрель. «Йолдыз» газетасында «Г-җан» имзасы белән «Тәрҗемә һәм аның шартлары»; «Габди» имзасы белән «Татар яшьләре» дигән мәкаләләре бастырыла.

15 апрель. «Йолдыз» газетасында «Тәрҗемә һәм аның шартлары» дигән мәкаләсе бастырыла.

19 апрель. «Йолдыз» газетасында «Татар яшьләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 май. «Йолдыз» газетасында «Галлей киткәннән соң» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 май. «Йолдыз» газетасында «Госманлы музәсе»нең мөдире мәрхүм Хәмди бәк җәнапләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

Май ае. «Яз башы» хикәясен яза.

1 июнь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикадчы В.Г. Белинский җәнабләре хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

3, 8 июнь. «Йолдыз» газетасында «Әдәбият мәсьәләләре. II. Халык мөсәннафәте» дигән мәкаләсе бастырыла.

17, 20 июль. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Нәүмид» дигән мәкаләсе бастырыла.

16, 30 сентябрь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Әстерханнан» дигән мәкаләсе бастырыла.

3 октябрь. «Йолдыз» газетасында «Гъ» имзасы белән «Әстерханнан» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 октябрь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Нугай туе» дигән мәкаләсе бастырыла.

Октябрь. Казанда Шәһит Әхмәдиев (1888–1930) белән бергә төшкән автографлы фотокарточкасын әнисенә бүләк итә.

18 ноябрь. «Йолдыз» газетасында «Тупый» имзалы авторның «Яңа әсәрләр. «Татар хатыны ниләр күрми» дигән бәяләмәсе бастырыла.

21 декабрь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Мөтәнәбби йә мөтәмәһди» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 декабрь. «Идел» газетасында «Габди» имзасы белән «Мөтәнәбби йә мөтәмәһди» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Аң» журналының 18 нче санында (б. 2–3) «Әрәм юбилей (Хәсәнгата казыйның[1] мәктүбен укыгач)» дигән мәкаләсе бастырыла.

Эстәрлетамакта «Каләм» ширкәте тарафыннан «Нур» матбагасында «Татар хатыны ниләр күрми?» дигән романы, Казанда «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан «Яз башы (Бер шәкерттән хикаять)» дигән хикәясе бастырыла.

## 1911

4 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Яңа әсәр» («Мәктәптә милли әдәбият дәресләре». Г. Тукаев тәртибе) дигән мәкаләсе бастырыла.

23 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Йә габид» имзасы белән «Яңа талантлы шагыйрь» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 февраль. «Йолдыз» газетасында «Әдәбият мәсьәләләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

13 февраль. «Йолдыз» газетасында «Г-җан Ибраһим» имзасы белән «Интикать асәр» («Төрки сарыфы») дигән мәкаләсе бастырыла.

14 февраль. «Йолдыз» газетасында «Әдәбият мәсьәләләре. IV. Шигырь» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 апрель. Халык шагыйре Габдулла Тукайның (1886–1913) «Күңел җимешләре» җыентыгына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Яңа әсәрләр (1)» («Күңел җимешләре») дигән бәяләмәсе бастырыла.

9, 11 апрель. «Йолдыз» газетасында «Мәдрәсә чуалулары» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 апрель. Тел галиме, журналист Гыймад Нугайбәкнең (1881–1943) «Башлангыч» исемле китабына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Яңа әсәрләр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

24 апрель. Хокук белгече, филолог Шәехгаттар Иманаевның (1875–1939) «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» китабына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Яңа китап» дигән бәяләмәсе бастырыла.

---

[1] *Хәсәнгата казый…*– Хәсәнгата Габәши (1863–1936), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы педагог. 1905–1915 елларда Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә икенче мәртәбә казый булып тора.

21 июнь. Г. Тукайның «Мияубикә» китабына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Мияубикә». Нәзымы Тукаев. Нашире «Сабах» дигән бәяләмәсе бастырыла.

14 август. «Вакыт» газетасында «Габди» имзасы белән «Учительская школа» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 сентябрь. «Вакыт» газетасында «Габди» имзасы белән «Сәүдәгәрләр арасында үзгәреш» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 октябрь. «Вакыт» газетасында «Габди» имзасы белән «Казан китапчылары» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 октябрь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Авылда мәгыйшәт» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 ноябрь. Язучы Фатыйх Әмирханның (1886–1926) «Хәят» повестена «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Хәят» дигән бәяләмәсе бастырыла.

8 ноябрь. «Вакыт» газетасында «Габди» имзасы белән «Тентү вә хибесләр нәтиҗәсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

15 ноябрь. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Яңа әсәрләр» мөнәсәбәте илә бер мөлахазә», «Шура» журналында «Г-җан Ибраһимов» имзасы белән «Әдәбият агымы» дигән мәкаләләре бастырыла.

18 ноябрь. Язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәриминең (1870–1937) «Тарих гомуми» китабына «Йолдыз» газетасында «Яңа әсәр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

4 декабрь. «Йолдыз» газетасында «Казан китапчыларының рәддиясе» дигән мәкаләсе бастырыла.

15 декабрь. Педагог, журналист Шиһабетдин Әхмәров (1882–1966) һәм аның фикердәшләренә карата «Йолдыз» газетасында дәгъвәте бастырыла.

25 декабрь. «Йолдыз» газетасында «Тәхсыйс» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Шура» журналының 6, 7 нче саннарында «Диңгездә» хикәясе (б. 171–175), (б. 205–207); 8 нче санында «Без татармыз» мәкаләсе (б. 236–238); 12, 13, 14 нче саннарында «Йөз ел элек» хикәясе (б. 379–386), (б. 411–413), (б. 440–443); 22 нче санында «Әдәбият агымы» мәкаләсе (б. 680–682), 23, 24 нче саннарында «Уты сүнгән җәһәннәм (Бер мулладан хикәят)» хикәясе (б. 734–736), (б. 765–768) бастырыла.

Казанда «Гасыр» нәшриятында «Татар нәхүе» (74 б.), «Татар сарыфы» (82 б.), «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (32 б.), Оренбургта «Вакыт» нәшриятында «Диңгездә», «Йөз ел элек» (35 б.) дигән китаплары нәшер ителә.

**1912**

12 гыйнвар. Журналист, драматург, театр тәнкыйтьчесе Кәбир Бәкернең (1885–1944) «Җанлы курчаклар» пьесасына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Яңа китап мөнәсәбәтилә» дигән бәяләмәсе бастырыла.

15, 22 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Әдәбият (Еллык хисап урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

17, 21, 24 февраль. «Идел» газетасында «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтенең шагыйрь Сәгыйть Рәмиевкә (1880–1926) багышланган өлеше бастырыла.

28 февраль. Тел галиме Гыйбадулла Алпаровка (1888–1936) «Сөю-сәгадәт (Карт шагыйрьнең тәэсораты)» дигән китабын автограф белән бүләк итә.

4 март. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Китап игъланнары» дигән бәяләмәсе бастырыла.

13 март. Ф. Әмирханның «Урталыкта» романына «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Зур романнар» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Шура» журналының 5, 8, 9 нчы саннарында «Карт ялчы» исемле хикәясе (б. 156–158), (б. 251–253), (б. 285–287), 9 нчы санында «Без кем?» бәхәсе» (б. 267–268), «Тәшәккер йөзеннән» (б. 266–268), 10 нчы санында «Ихтилаф вә риваять бәласе» (б. 305–307) дигән мәкаләләре дөнья күрә.

8, 12, 17 апрель. «Йолдыз» газетасында «Милли тарих» дигән мәкаләсе бастырыла.

17 апрель. «Идел» газетасында «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәтенең беренче бүлегенең С. Рәмиевкә багышланган баш өлеше бастырыла.

10 май. «Йолдыз» газетасында «Габди» имзасы белән «Матбугат әңгәмәләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 май. «Йолдыз» газетасында «Асар матбуг хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

Көз көне Киевкә килеп урнаша.

13 декабрь. Киевтән Казанга Хәнәфи Кайбышевка (1890–?) хат яза.

28 декабрь. Казаннан Х. Кайбышев хат яза.

Декабрь. Язучы, тәрҗемәче, нашир Әхмәдгәрәй Хәсәнигә (1883–1933) автографлы фотокарточкасын бүләк итә.

Казанда «Гасыр» нәшриятында «Карак мулла», «Сөю – сәгадәт. Карт шагыйрьнең тәэсораты», «Өмид» матбагасында «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәяләре, «Яшь йөрәкләр» романы, Оренбургта «Вакыт» нәшриятында «Карт ялчы», «Уты сүнгән җәһәннәм», Әхмәд әл-Исхакый наширлегендә Казанда «Яз башы. Бер шәкерттән хикаять» хикәяләре, Уфада «Мәзлумә хатын яхуд күргән җәфаларым» дигән әсәре нәшер ителә.

**1913**

1 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Матбугат агымы (Еллык хисап урынында)», «Мәктәп» журналының 1 нче санында (б. 25–28) «Мәктәптә әдәбият» дигән мәкаләсе бастырыла.

3 гыйнвар. Киевтән Казанга Х. Кайбышевка хат яза.

10, 13, 15, 17, 20, 22, 24 гыйнвар. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

24 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Авыргазый» имзалы авторның «Яшь йөрәкләр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

25 гыйнвар. «Аң» журналының 3 нче санында (б. 49) «Бәйрәм мөбарәк булсын!» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 гыйнвар. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

27 гыйнвар. Казаннан Х. Кайбышев хат яза.

29, 31 гыйнвар. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

3, 5, 7, 10, 12, 14 февраль. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

21 февраль. «Идел» газетасында Хөснинең [Хөснетдин Кәримнең, 1887–1965], «Вакыт» газетасында Җәләйнең [Җәмал Вәлидинең, 1887–1932] «Яшь йөрәкләр» дигән бәяләмәләре бастырыла.

3, 5, 17 март. «Йолдыз» газетасында «Рус, төрек вә татар тарихыннан (Романовлар ханаданының 300 еллык шәүкәте мөнәсәбәте белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

17 март. «Йолдыз» газетасында «Рус, төрек вә татар тарихыннан» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 март. Әтисе Гыйрфан Ибраһимов вафат була, 28 мартта җирләнә.

28 март. Киевтә мөселман студентларының съездын әзерләү комиссиясе утырышында ул төзегән резолюция карала.

Март. Яшь вакытта алдырган фотокарточкасын автограф белән Киевтән агасы Шакирҗанга (1880–1962) җибәрә.

«Хокук вә хәят» журналының 3 нче санында (б. 45–54) Фатыйх Сәйфинең [Фатих Сәйфи-Казанлының, 1888–1937] «Яшь йөрәкләр» (Роман. Мөхәррире – Галимҗан Ибраһимов)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

6 апрель. «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәттә булган Төхфәтулла Мамлиев (1887–?) Киевтә мөселман студентлары түгәрәге җитәкчелегендә Г. Ибраһимов та барлыгын Казан губерна жандарм идарәсенә хәбәр итә.

8 апрель. Киевтәге мөселман студентлары интернационал социалистик оешмасы җитәкчелегендә Г. Ибраһимов та барлыгы хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев сак бүлегенә хәбәр итә.

9 апрель. «Йолдыз» газетасында «Мәдрәсә чуалулары» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 апрель. Әтисе вафаты уңае белән «Вакыт» газетасында некролог бастырыла.

17 апрель. Казаннан Хәлиулла Еникеев (1891–1946) аңа хат яза.

17 апрель. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы боерыгы буенча Киев Бульвар полиция участогының надзирателе Крумин Г. Ибраһимов яшәгән фатирда (Степановская, 18) төнге сәгать $12^{30}$ да тентү үткәрә һәм бу хакта беркетмә төзи.

17 апрель. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы полковник боерыгы буенча Г. Ибраһимовның тентелүе хакында белешмә төзелә.

18 апрель. Г. Ибраһимовның кулга алынуы хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы карар чыгара.

18 апрель. Аерым жандармнар корпусы тарафыннан Г. Ибраһимовтан сорау алына.

18 апрель. Г. Ибраһимовның кулга алынуы хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев губернаторына хәбәр итә.

19 апрель. Г. Ибраһимов кулга алыну карары белән таныштырыла һәм Киев төрмәсенә ябыла. Бу хакта надзиратель Крумин Киев губерна жандарм идарәсенә хәбәр итә.

21 апрель. «Йолдыз» газетасында Уйгурның [Габделбари Батталның, 1880–1969] «Яшь йөрәкләр» (Роман)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

24 апрель. Киев төрмәсеннән Казанга Шәһит Әхмәдиев белән Заһит Нуркинга (1898–1966) рус телендә хат яза.

25 апрель. Г. Ибраһимовны сак астында тоту срогын озайтуны сорап Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев губернаторына мөрәҗәгать итә.

27 апрель. Аерым жандармнар корпусы тарафыннан сорау алу вакытында Казан университетының медицина факультеты студенты Х. Кайбышев 1912 елның көзендә Казанга килгән Киев университеты студенты Х. Еникеев уртак иптәшләр арасында Г. Ибраһимов та барлыгын әйтүен белдерә.

28 апрель. «Теоретик» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәттә булган Х. Кайбышев 1912 елның көзендә Казанга килгән Киев университеты студенты Х. Еникеев уртак иптәшләр арасында Г. Ибраһимов та барлыгын әйтүен Казан губерна жандарм идарәсенә хәбәр итә.

29 апрель. Киев округ мәхкәмәсе прокуроры Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына Г. Ибраһимовны сак астында тоту срогы озайтылуы хакында хәбәр итүен сорый.

29 апрель. Сак астында тоту срогы кулга алынган көннән башлап бер айга Киев губернаторы тарафыннан озайтыла һәм бу хакта Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр ителә.

30 апрель. Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев төрмәсе башлыгына Г. Ибраһимов кулга алынган көннән алып сак астында тоту срогы бер айга озайтылу хакында үзенә язмача белдерергә боера.

30 апрель. Сак астында тоту срогы бер айга озайтылу хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев округ мәхкәмәсе прокурорына хәбәр итә.

30 апрель. Киевтә кулга алынуы хакында Казан мөселман студентларының хәбәрдар булуы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәттә булган Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсенә белдерә.

1 май. Киевтәге мөселман студентлары түгәрәгендә Г. Ибраһимов та барлыгы хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаментына хәбәр итә.

3 май. Киевтә кулга алынуы хакында Казан мөселман студентларының хәбәрдар булуы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәттә булган Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсенә белдерә.

3 май. Х. Кайбышевны тентү вакытында алынган Г. Ибраһимовның бер хатын Казанда Аерым жандармнар корпусы Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына юллый.

3 май. Х. Кайбышевны тентү вакытында алынган Г. Ибраһимовның бер хатның Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына җибәрелүе хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаментына хәбәр итә.

15 май. Киев округ мәхкәмәсе прокуроры Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына Г. Ибраһимовны сак астында тоту срогы тагын озайтылуы хакында өстәмә хәбәр итүен сорый.

16 май. Х. Кайбышевтан Аерым жандармнар корпусы тарафыннан сорау алу вакытында Г. Ибраһимовтан хат почта буенча килмичә, ә кемдер бер кеше тапшыруы һәм ул конверт тышына «Кабул итүдән баш тартам» дип язып куюын белдерә.

25, 26, 27, 28, 29, 30 май, 1 июнь. «Татар шагыйрьләре» китабы нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

1–3, 5–10, 13–26 июнь. Кулга алганда тентү вакытында алынып, 4 төенчеккә тупланып, Киев губерна жандарм идарәсе тарафыннан Казан губерна жандарм идарәсенә җибәрелгән әйберләренең Казанда Аерым жандармнар корпусы һәм 15 нче Татар Улан полкы штабс-ротмистры, тәрҗемәче Александр фон-Трентовиус (1881–?) тарафыннан тасвирламасы төзелә.

2, 6, 7, 8, 9, 12, 13 июнь. «Татар шагыйрьләре» китабы нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

13 июнь. Җинаять эше табылмау сәбәпле, сак астыннан азат ителеп Киев төрмәсеннән чыгарыла һәм бу хакта Киев төрмәсе башлыгы вазыйфасын башкаручы Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

13 июнь. Туган авылы Солтанморатка кайтып китәчәге хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына язмача белдерә.

14 июнь. «Татар шагыйрьләре» китабы нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

14 июнь. Тентү вакытында алынган газета-журналларны, брошюраларны, китапларны сәяси яктан тикшерү өчен Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан Вакытлы матбугат комитетына бирә.

14 июнь. Тентү вакытында алынган һәм кайтарып бирелергә тиешле даими паспортын, 14 исемдә әйберләрен Киев губерна жандарм идарәсеннән имза куеп ала.

15 июнь. Тентү вакытында алынган «Казакъ кызы» һәм «Яшь куәтләр» дигән әсәрләрен сәяси яктан тикшерү өчен Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан Вакытлы матбугат комитетына бирә.

15, 16, 17, 19, 20, 21, 22 июнь. «Татар шагыйрьләре» китабы нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

18 июнь. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Г. Ибраһимовның җинаятен күрсәтә торган материалларның Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына җибәрелүе хакында 3 майдагы донесениесенә өстәмә рәвешендә Полиция департаментына хәбәр итә.

22 июнь. Җинаять эше табылмау сәбәпле, алга таба сак астында тотуны туктату хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаментына хәбәр итә.

21 июнь. «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәттә булган Т. Мамлиев тиздән татар телендә газета чыгарыла башланачагы һәм аның мөхәррире Г. Ибраһимов булачагы хакында Казан губерна жандарм идарәсенә хәбәр итә.

23 июнь. Киевтән Казанга кайтуы хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

25 июнь. «Йолдыз» газетасында «Мең дә беренче кичәгә каршы… («Йолдызның» әлфия көне мөнәсәбәте белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

Июнь. «Карак мулла» әсәре нәшер ителү хакында «Православный собеседник» журналының июнь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 3 нче китабында А. Емельяновның «Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в Приволжском и Оренбургском крае за 1912-й год» дигән мәкаләсендә бастырыла.

Июнь. «Мәзлумә хатын яхуд күргән җәфаларым» әсәре нәшер ителү хакында «Православный собеседник» журналының июнь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 3 нче китабында А. Емельяновның «Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в Приволжском и Оренбургском крае за 1912-й год» дигән мәкаләсендә бастырыла.

1 июль. Тентү вакытында алынган газета-журналларга, брошюраларга, китапларга арест салынмаганлыгы хакында Казан губернасында типографияләр, литографияләр һәм китап белән сәүдә итү җитәкчесе Розенштейн Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

2 июль. Казан Вакытлы матбугат комитеты башлыгы «Казакъ кызы» һәм «Яшь куәтләр» әсәрләре сәяси яктан куркынычлы түгеллеге хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

4 июль. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы «Казакъ кызы» һәм «Яшь куәтләр» әсәрләрен кире Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына җибәрә.

5 июль. Казан Вакытлы матбугат комитеты башлыгы Михаил Пинегин (1863–1935) сәяси яктан тикшерү өчен 14 июньдә алынган газета-журналларны, брошюраларның Комитет әгъзасы Пантелеймон Жузе (1870–1942) тарафыннан тикшерелеп, сәяси яктан куркынычсыз дип табылулары, ә китапларның Николай Катановка (1862–1922) тапшыры-

лып, әлегә бәяләмәнең юклыгы хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

8 июль. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы вазифасын вакытлыча башкаручы Г. Ибраһимовны тентү вакытында алынып, Казан губерна жандарм идарәсенә юлланган газета-журналларның, брошюраларның һәм китапларның кире җибәрелүе хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

19 июль. 17 апрельдә сак астына алынган Г. Ибраһимов хакында Полиция департаментына белешмә җибәрелә.

20 июль. Н. Катановтан бәяләмә алынуы һәм Габделмәҗит Гафуриның (1880–1934) «Милли шигырьләр», Мөхәммәтгаяз Исхакыйның (1878–1954) «Зиндан» китапларыннан башкалары сәяси яктан куркынычсыз булулары хакында Казан Вакытлы матбугат комитеты башлыгы М. Пинегин Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

17 август. Туган якларында яшәве һәм Ш. Әхмәдиев белән «Шимбә» исемле газета чыгарырга ниятләве хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

23 август. Ш. Әхмәдиев белән Г. Ибраһимов «Аваз» исемле атналык журнал чыгарырга җыенулары хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

26 август. Туган авылы Солтанморатта яшәве хакында Стәрлетамак өяз ротмистры Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

29 август. Г. Ибраһимов белән очрашырга Ш. Әхмәдиев Уфага китүе хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

4 сентябрь. «Ак юл» журналының 10 нчы санында «Г. И.» имзасы белән «Җиләк вакытында» дигән әсәре бастырыла башлый.

8 сентябрь. Солтанморат авылыннан Казанга Ә. Хәсәнигә хат яза.

16 сентябрь. «Ак юл» журналының 11 нчы санында «Г. И.» имзасы белән «Җиләк вакытында» дигән әсәренең ахыры бастырыла.

19 сентябрь. Солтанмораттан Казанга килүе хакында «Йолдыз» газетасында белдерү бастырыла.

19 сентябрь. Казанга килүе һәм «Апанаев номерлары»нда тукталуы; кышын Казанда татар газеталарында, шул исәптән Ш. Әхмәдиевнең «Аваз» журналында эшләргә ниятләве, әгәр дә урнаша алмаса, С. Петербургка китеп, Г. Исхакый белән Муса Бигиев (1873 яки 1875–1949) чыгарачак «Ил» газетасында эшләргә җыенуы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

Сентябрь. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Православный собеседник» журналының сентябрь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 4 нче китабында «Критика и библиография» дигән бүлекчәдә бастырыла (б. 229).

17 октябрь. «Аң» журналына сәркятип булып урнашуы хакында «Теоретик» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Х. Кайбышев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

20 октябрь. «Аң» журналына сәркятип булып урнашуы хакында басманың 20 нче санында хәбәр бастырыла. «Аң» журналының 20 нче санында имзасыз «Мәрхүм шагыйрь» дигән мәкаләсе бастырыла.

26 октябрь. Казаннан Әстерханга Х. Кәримгә хат яза.

27 октябрь. «Аң» журналының 21 нче санында язылышучыларны, язучыларны, басманы алдыручыларны һәм барлык укучыларны Корбан бәйрәме белән котлавы, «Асар» хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Шура» журналының 10 нчы санында (б. 312–313) Г. Зәбировның «Яшь йөрәкләр» китабы мөнәсәбәте илә (Истанбулдан)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Аң» журналының 11 нче санында (б. 189–194) Г. Газизнең [Газиз (Габделгазиз) Салих улы Гобәйдуллинның, 1887–1937] «Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр» (Тәнкыйь)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

4 ноябрь. Студент Фатыйх Мөхәммәдъяровта (1883–1950) кунакта булуы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

17 ноябрь. «Аң» журналының 22 нче санында (б. 380–387) «Көтүче карт (Басылмаган романнан бер фасыл)» дигән әсәре бастырыла.

26 ноябрь. «Аң» журналында сәркятип булып урнашуы һәм «Яңа елга ни телисез?», «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән ике анкета урнаштыруы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

2 декабрь. «Аң» журналының 23 нче санында (б. 319–416) «Баттал әфәнденең нәзарият әдәбиясе» дигән бәяләмәсе бастырыла.

10 декабрь. «Сабах», «Мәгариф» һәм «Гасыр» көтепханәләренең складлары белән кызыксынуы хакында «Житель» кушаматы белән жандармериядә яшерен хезмәт итүче Т. Мамлиев Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

11 декабрь. 13 октябрьдә Казанга китүе хакында Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгы үзенең 6 сентябрьдә язган хатына өстәмә итеп Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

18 декабрь. «Аң» журналының 24 нче санында (б. 439–442) «Фәнни истиляхлар (Г. Батталның нәзарият әдәбиясе мөнәсәбәте белән)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

26 декабрь. «Матбугат вә әдәбиятымыз барышы (Еллык хисап урынында)» дигән мәкалә яза.

31 декабрь. «Йолдыз» газетасында журналист Хәлим Искәндәровның (1888–1958) «Галимҗан Ибраһимов вә аның әсәрләре» дигән бәяләмәсе басыла [«Татар хатыны ниләр күрми» турында].

Декабрь. Ак эшләпә һәм плащ-накидка киеп төшкән фотосын почта карточкасы итеп ясалган) Ш. Әхмәдиевкә автограф белән бүләк итә (Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана: 122214–20).

Казанда «Гасыр» нәшриятында «Татар сарыфы» (икенче кәррә басылуы) (78 б.) дигән уку әсбабы, Оренбургта «Вакыт» нәшриятында «Татар шагыйрьләре. Беренче бүлем. Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукай» (103 б.) дигән хезмәте нәшер ителә.

«Аң» журналының 20 нче санында (б. 350) шагыйрь Ибраһим Башмаков (1893–1913) хакында «Мәрхүм шагыйрь» дигән мәкаләсе бастырыла.

**1914**

5 гыйнвар. «Аң» журналының 1 нче санында (б. 12–17) «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Матбугат вә әдәбиятымыз барышы (Еллык хисап урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

10 гыйнвар. «Аң» журналының 24 нче санында (б. 428–430) «Мәрхүмнең дәфтәреннән» дигән әсәре бастырыла.

25 гыйнвар. «Аң» журналының 3 нче санында (б. 49) «Бәйрәм мөбарәк булсын!» дигән мәкаләсе бастырыла.

29 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында Х. Искәндәровның «Галимҗан Ибраһимов вә аның әсәрләре» дигән бәяләмәсе бастырыла [«Татар хатыны ниләр күрми» турында].

13 февраль. Тиз йөрешле поездда Киевкә китүе хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Киев, Кутаиси губерна һәм Одесса шәһәр жандарм идарәләре башлыкларына хәбәр итә.

15 февраль. Киевкә килеп җитә. Жилянская урамындагы «Мәскәү» номерларына (130 санлы йорт) урнаша.

16 февраль. Львовская урамындагы 55 санлы йорттан бүлмә алып, шунда күчә.

22 февраль. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

24 февраль. 15 февральдә Киевкә килеп җитүе, аның башта Жилянская урамындагы «Мәскәү» номерларына (130 санлы йорт), 16 февральдә Львовская урамындагы 55 санлы йорттан бүлмә алып, шунда күчүе хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

25 февраль. Украин халкының күренекле шагыйре Тарас Шевченконың (1814–1861) тууына 100 ел тулу уңаеннан «Йолдыз» газетасында «Каһарман шагыйрь (Олугъ малорус шагыйре Тарас Шевченко)» дигән мәкалә бастыра.

28 февраль. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

2 март. «Аң» журналының 6 нчы санында (б. 117–122) «Тәрбиядә хөррият вә шәхсыять нигезләре (Җәдид аталган бер мәктәпне күреп чыгудан алган тәэсир белән язылды)» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 март. «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

11 март. Сухум шәһәренә сәфәре хакында «Йолдыз» газетасында хәбәр бастырыла.

11 март. Киевтән Одессага китә.

12–13 март. Одессада була.

13 март. Көндезге сәгать 12 дә «Германия» кунакханәсеннән чыгып, «Цесаревич Георгий» пароходында сәгать 3 тә Кырым-Кавказ линиясе буенча китә.

14 март. Киевтән Одессага китүе хакында Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

14 март. «Цесаревич Георгий» пароходында Севастопольгә килеп җитә. Аннан шул ук көнне Ялтага китә.

14 март. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

17 март. «Цесаревич Георгий» пароходы белән Сухумга килеп җитә һәм Михайловская Набережная урамында урнашкан «Венеция» кунакханәсенә туктала. Анда «Безнең көннәр» романын язып тәмамлый.

22 март. Севастополь, Ялта шәһәрләренә килә, аннары Феодосия һәм Керчькә китә.

25 март. Полиция департаменты Киев, Кутаиси губерна һәм Одесса шәһәр жандарм идарәсе башлыкларыннан күзәтү нәтиҗәләре хакында мәгълүмат бирүләрен сорый.

26 март. 13 мартта Одессадан китүе хакында Одесса шәһәр жандарм идарәсе башлыгы Киев, Казан губерна, Севастополь жандарм идарәсе башлыкларына, Полиция департаменты директорына хәбәр итә.

28 март. 22 мартта Севастополь, Ялта шәһәрләренә килүе, аннары Феодосия һәм Керчькә китүе хакында Одесса шәһәр жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаменты директорына, Киев, Казан губерна жандарм идарәсе башлыкларына хәбәр итә.

31 март. 14 мартта «Цесаревич Георгий» пароходында Севастопольгә килеп җитүе һәм шул ук көнне аннан Ялтага китүе хакында Севастополь жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаменты директорына хәбәр итә.

2 апрель. «Цесаревич Георгий» пароходы белән Сухумга килеп җитүе һәм Михайловская Набережная урамында урнашкан «Венеция» кунакханәсенә тукталуы, анда дүрт айга якын торырга ниятләве һәм фатир хаклары белән кызыксынуы хакында Кутаиси губерна жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаментына хәбәр итә.

2 апрель. Киев губерна жандарм идарәсе башлыгы күзәтү нәтиҗәләрен Полиция департаментына хәбәр итә.

2 апрель. «Йолдыз» газетасында Г. Тукайга багышланган «Талант трагедиясе» дигән мәкаләсе бастырыла.

9, 22 апрель. «Йолдыз» газетасында «Г. И.» имзасы белән «Әхмәт Мидхәт әфәнде» (Ризаэтдин бине Фәхретдин әсәре)» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 апрель. Сухумнан Әстерханга Х. Кәримгә хат яза.

18 апрель. «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

22 апрель. «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәте нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

8 май. Сухум шәһәрендәге 2 нче Подгорный урамында Сигаев йортында яшәүче Г. Ибраһимов артыннан 17 апрельдән 1 майга кадәр куелган тышкы күзәтү нәтиҗәсендә хилаф эш күренмәве хакында Кутаиси губерна жандарм идарәсе башлыгы Полиция департаментына хәбәр итә.

13 май. Сухумнан Әстерханга Х. Кәримгә хат яза.

12 июнь. Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы күзәтүләр нәтиҗәсен Полиция департаментына хәбәр итә.

16 июль. Сухумнан Одессага китә.

11 июль. «Тормыш» газетасында «Габди» имзасы белән «Мөгаллим вә мөгаллимәләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

21 июль. 16 июльдә Сухумнан Одессага китүе хакында Кутаиси губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

23 июль. Казанга кайта.

5 август. «Диңгездә» дигән әсәре нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

6 август. Туган ягына (Стәрлетамак өязенә) кайтып китүе хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

26 август. Стәрлетамак өяз ротмистры Стәрлетамак өяз исправнигыннан туган ягына кайту-кайтмавын тикшерүен һәм хәбәр итүен сорый.

Август. Автографлы фотокарточкасын туганы Мохтар Ибраһимовка (1885–1969) Дәүләкәндә бүләк итә.

2 сентябрь. Г. Баттал белән берлектә төзелгән «Яңа әдәбият» дигән дәреслек нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

10 сентябрь. Туган ягына кайтып җитүе һәм яшертен күзәтүне 1 стан приставына йөкләнүе хакында Стәрлетамак өяз исправнигы Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

18 сентябрь. Солтанморатта яшәве һәм аның артыннан күзәтү оештырылуы хакында Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

23 сентябрь. Г. Баттал белән берлектә төзелгән «Яңа әдәбият» дигән дәреслек нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

2 октябрь. Туган авылыннан Казанга китә.

9 октябрь. 2 октябрьдә туган авылыннан Казанга китүе хакында Стәрлетамак өяз исправнигы Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

2 октябрь. Даими яшәү өчен Казанга күченеп килә.

15 октябрь. 2 октябрьдә Казанга китүе хакында Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

5, 6, 9, 10, 11, 12, 13 ноябрь. Г. Баттал белән берлектә төзелгән «Яңа әдәбият» дигән дәреслек нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

10 декабрь. «Йөз ел элек» дигән хикәясе нәшер ителү хакында «Вакыт» газетасында хәбәр бастырыла.

28 декабрь. «Йолдыз» газетасында «Яңа әдәбият» мөрәттибләреннән Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Яңа әдәбият» хакында тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләсе бастырыла.

Казанда «Гасыр» нәшриятында «Татар имлясы» (28 б.), «Татар нәхүе» (74 б.) (икенче басмасы), «Яңа әдәбият» (Г. Баттал белән берлектә) дигән дәреслекләре нәшер ителә.

**1915**

8, 14 гыйнвар. «Йолдыз» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Хәят вә әдәбият (Еллык тәэсорат)» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 гыйнвар. Илаһият галиме, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) истәлегенә үткәрелгән мәҗлестә катнаша.

25 гыйнвар. Ф. Сәйфи-Казанлының «Ямьсез тормыш» пьесасы сәхнәгә куелу уңаеннан «Йолдыз» газетасында «Г-җан» имзасы белән «Шәрекъ клубы»нда татарча театр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Аң» журналының 1 нче санында (б. 39–47) Ш. Мәрҗанигә багышланган «Бөек остазның кайбер тәэлифләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 гыйнвар. «Аң» журналының 2 нче санында (б. 39–47) Ш. Мәрҗанигә багышланган «Бөек остазымызның тарихи бер тәнкыйте» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 февраль. «Йолдыз» газетасында «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр (Еллык тәэсоратым)» дигән мәкаләсе бастырыла башлый.

10 февраль. Абзыйсы Шакирҗанны сугышка озату өчен Казаннан Уфага китә.

17 февраль. Туганын сугышка озату өчен 10 февральдә Казаннан Уфага китүе хакында Казан губерна жандарм идарәсе башлыгы Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

19 февраль. Уфада тукталган Большая Успенская урамы, 50 санлы йорттан Стәрлетамакка китә.

26 февраль. 19 февральгә кадәр Уфада яшәве һәм Стәрлетамак өязенә китүе хакында Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгы генерал-майор Устинов Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

26, 27 февраль. «Тормыш» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 февраль. 19 февральдә Уфада тукталган Большая Успенская урамы, 50 санлы йорттан Стәрлетамакка китүе хакында Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгы Казан губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

6 март. Туган авылы Солтанмораттан Казанга Ә. Хәсәнигә хат яза.

20 март. «Кояш» газетасында «Аң» альбомы» дигән бәяләмә бастырыла.

29 апрель. «Йолдыз» газетасында «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр (Еллык тәэсоратым)» дигән мәкаләсенең ахыры бастырыла.

«Шура» журналының 6 нчы санында (б. 174–175) Әхмәт Зәкинең [Әхмәтзәки Вәлидинең, 1890–1970] «Шәрекъка гаид әсәрләр» дигән мәкаләсендә «Яшь йөрәкләр» романына да бәяләмә бирелә.

26 июль, 9 август. Мәктәп китаплары хакында Уфада киңәш мәҗлесендә сөйләгән чыгышы «Тормыш» газетасында бастырыла.

30 июль. «Тормыш» газетасында «Журналларыбыз» дигән мәкаләсе бастырыла башлый.

9, 11, 12 август. «Тормыш» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Журналларымыз» дигән мәкаләсе бастырылып тәмамлана.

23 август. Уфада Гаяз Исхаков, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Терегулов (1883–1938) һәм Сәгыйть Рәмиев яшертен мөселман революцион партия төзергә җыенулары хакында «Житель» Казан губерна жандарм идарәсенә белдерә. Бу хакта Уфа губерна жандарм идарәсенә хәбәр ителә.

Сентябрь. Г. Баттал белән берлектә төзелгән «Яңа әдәбият» дигән дәреслек нәшер ителү хакында «Православный собеседник» журналының кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 12 нче китабында А. Емельяновның «Краткий обзор татарско-мухаммеданской неповременной печати за 1914-й г.» дигән мәкаләсендә мәгълүмат китерелә (б. 1017).

30 сентябрь. «Йолдыз» газетасында «Гани бай вәкыфы мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

16, 20 октябрь. «Йолдыз» газетасында «Галимҗан Ибраһимов», «Г. И.» имзалары белән Г. Тукай хакында «Актык сәлам» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 ноябрь. «Тормыш» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Хәзерләнә башларга вакыт җитмәдеме?» дигән мәкаләсе бастырыла.

15 декабрь. «Аң» журналының 21–22 нче кушма санында (б. 378–390) «Татар сарыфлары (Фатыйх Сәйфи, Җәмалетдин Вәлиди һәм Г. Сәгъди әфәнделәрнең яңа чыккан сарыф вә нәхү китаплары мөнәсәбәте белән)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

16 декабрь. Уфадан Казанга Ә. Хәсәнигә хат яза.

26 декабрь. Ноябрь аенда туган авылы Солтанмораттан Уфага китүе, аның анда «ниндидер мөселман училищесендә укытучы булып торуы» хакында Уфа губерна жандарм идарәсенең Стәрлетамак пунктындагы өстәмә штаты унтер-офицеры Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгына хәбәр итә.

«Аң» журналы нәшерендә чыккан «Альманах»та «Табигать балалары» хикәясе дөнья күрә (б. 1–28); «Гасыр» нәшриятында «Татар сарыфы» (62 б.), «Татар нәхүе» (төзәтелгән өченче басмасы) (74 б.) дәреслекләре; ул төзегән «Альбом (Санаигы нәфисә мәҗмугасы)» (30 б.) «Аң» нәшерендә чыга. Анда «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 12–30). Андагы күмәк фотода ак эшләпә, плащ-накидка киеп төшкән аның да сурәте бар (б. 32): (уңнан сулга) Гаяз

Исхакый, Сәгыйть Рәмиев, Шәриф Манатов (1887–1936), Галимҗан Ибраһимов. Рәсемнең 1913 елның җәй аенда алдырылуы язылган.

«Аң» журналының 15–16 нчы санында (б. 284–286) «Уфада дәрес китаплары хакындагы киңәш мәҗлесенең карарлары»; 14 нче санында (б. 253–256) «Хезмәт һәм әдәби җинаять. Тәнкыйть (Юрист Шакир Мөхәммәдъяровның «Суд законнары»)»; 18–19 нчы санында (б. 327–336) «Татар имлясында яңа агымнар (Уфада мәктәп китаплары хакында ясалган киңәш мәҗлесендә укылган мәгърүзәнең холасасы)»; 20 нче санында (б. 378–390) «Мәдрәсәи Галия вакыйгасы» хакында берничә сүз (Муса әфәнденең «Вакыт»та басылган мәкаләсен укыгач язылды)» дигән мәкаләләре бастырыла.

**1916**

21 февраль. «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында «Тәрҗеман» газетасында белдерү бастырыла.

22 март. Дүрт хезмәтен бастыру өчен «Кәгазе бар наширләр дикъкатенә» дигән мөрәҗәгате «Тормыш» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән бастырыла.

31 март. «Аң» журналының 5 нче санында (б. 87–90) «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Телләре башка булса да күңелләре бер (Матбугатта казакъ яшьләре тарафыннан кузгатылган тел мәсьәләсе мөнәсәбәте белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 апрель. «Тормыш» газетасында «Ихтирам белән Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Идарәгә мәктүб» дигән хаты бастырыла.

28 октябрь. «Тормыш» газетасында «Ихтирам белән Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Әдәбият дустларыннан бер үтенеч» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

1 ноябрь. «Аң» журналының 18; 19–20 нче саннарында «Габдрахман Салихов» дигән хикәясе бастырыла (б. 287–291; 300–303).

6 ноябрь. «Галия» мәдрәсәсендә укытучы булып эшләве хакында «Тормыш» газетасында хәбәр бастырыла.

16 декабрь. Уфадан Казанга Ә. Хәсәнигә хат яза.

16 декабрь. Уфада «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юбилей кичәсендә төп доклад укый.

20 декабрь. Уфада алдырган фотокарточкасын автограф белән туганы Мотаһар Ибраһимовка (1893–1975) бүләк итеп җибәрә.

22 декабрь. Казаннан килгән Ш. Әхмәров белән сөйләшеп, әсәрләрен көзгә бастырып чыгару шарты белән, «Сабах» көтепханәсенә бирүе хакында «Тормыш» газетасы идарәсенә хат яза.

24 декабрь. Уфа земствосының тәгълим вә тәрбия курсларында һәм кызлар мәдрәсәсендә укытуын ташлавы хакында «Тормыш» газетасы идарәсенә хат яза.

26 декабрь. Уфадан «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юилей кичәсендә Зыяэтдин Камалига (1873–1942) тәбрикнамә һәм Коръән бүләк иткәндә ул да автографын куя.

Казанда «Сабах» ширкәте тарафыннан «Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» (90 б.), «Әдәбият дәресләре» (148 б.), «Татар нәхүе» (4 нче басмасы) (74 б.) уку-укыту әсбаплары; «Милләт» матбагасында «Габдрахман Салихов» (32 б.) хикәясе нәшер ителә.

**1917**

10 февраль. Госмановларның кызлар мәдрәсәсендә укытмаячагы һәм «Галия» мәдрәсәсеннән вакытлы ял алуы хакында «Тормыш» газетасында хәбәр бастырыла.

9 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату бюросы»на әгъза итеп сайлана.

11 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату бюросы»ның тәхрир (беркетмә) комиссиясенә сайлана.

12 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату бюросы» «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» итеп үзгәртелә һәм Г. Ибраһимов аның идарәсенә әгъза итеп сайлана.

17 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

20 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша. Халыкны хәзерге хәл белән таныштыру өчен авылларга таныштыручылар җибәрергә кирәк дигән тәкъдиме кабул ителә.

21 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында лекторларга бирелгән вәкаләтнамәнең Г. Ибраһимов тәкъдим үрнәге кабул ителә.

22, 23, 24 март. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

29 март. Уфада 1 нче апрельдән чыга башлаячак «Ирек» газетасына абунә дәфтәре ачылу хакында «Тормыш» газетасында белдерү бастырыла.

30 март. «Галия» мәдрәсәсе укытучысы Ф. Сәйфи-Казанлы белән берлектә Уфада «Сарай» номерлары бинасында (хәзерге Пушкин урамы, 92) сул социалист революционер интернационалистларның (эсерларның) «Ирек» исемле газетасын чыгара башлый.

30 март. «Ирек» газетасында «Куәт – халыкта» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 март. Уфада «Ирек» газетасы чыга башлавы хакында «Вакыт» газетасында белдерү бастырыла.

2 апрель. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

2 апрель. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гадәттән тыш икенче җыенында рәислек итә. Мәскәүдә булачак Гомумрусия мөселманнары съездына комитет исеменнән вәкил булып сайлана.

3, 5, 7 апрель. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

«Ирек» газетасында «Халык – падишаһ» дигән мәкаләсе бастырыла.

9, 13 апрель. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

15 апрель. Сул социалист-революционерлар (эсерлар) фиркасенә әгъза булып керә.

19, 20, 22 апрель. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

22 апрель. «Ирек» газетасында «Сәгыйть Рәмиев мәсьәләсе», Ф. Сәйфи-Казанлы белән берлектә «Ирек» идарәсе тарафыннан» дигән мәкаләләре бастырыла.

1–11 май. Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенрусия мөселманнарының I съездында Уфадан вәкил буларак катнаша һәм чыгышлар ясый.

6 май. «Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнары җыелышы (Җыелыш алды көннәре)» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 май. «Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнары җыелышы» дигән мәкаләсе бастырыла.

19, 24, 25 май. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

25 май. «Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнары җыелышы. Эшчеләр мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

26, 28 май. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

«Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнары җыелышы. Хатынкыз мәсьәләсе», «Безнең юл», Ф. Сәйфи-Казанлы белән берлектә язылган «Халык үзе хөкем итсен» дигән мәкаләләре бастырыла.

1 июнь. «Ирек» газетасында «Имля мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 июнь. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында рәислек итә.

4 июнь. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша һәм вилаять игенчеләр (крәстияннәр) съездына вәкил булып сайлана.

«Ирек» газетасында «Социалист революционерлар ни телиләр?» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 июнь. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында рәислек итә.

16 июнь. «Ирек» газетасында «Безгә нинди курслар кирәк?» дигән мәкаләсе бастырыла.

18, 21 июнь. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында катнаша.

«Ирек» газетасында «Гъ. И.» имзасы белән «Көрәш башланды» дигән мәкаләсе бастырыла.

23, 27 июнь. Уфада «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» җыенында рәислек итә.

5 июль. «Ирек» газетасында «Халыкны саташтырмаңыз» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 июль. «Ирек» газетасында «Революция вакытындагы беренче бәйрәм көненә багышлыйм» дигән мәкаләсе бастырыла.

21 июль – 2 август. Казанда үткәрелгән Бөтенрусия мөселманнарының 2 съездында Уфадан вәкил буларак катнаша.

25 июль. «Аваз» газетасында «Милли-мәдәни мохтарият һәм социалист-революционерлар» дигән мәкаләсе бастырыла.

26 июль. Казан мөселман социалистлары тарафыннан 1917 елның 15 июнендә «Кызыл байрак» газетасы нәшер ителә башлауны котлап, «Ирек» газетасында «Өченче социалистик газета» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 июль. «Кояш» газетасының 1917 елгы 25 июль санында Г. Ибраһимовның татар социалистлары исеменнән Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездын котлавы әйтелә.

30 июль. «Ирек» газетасында «Социал-демократлар һәм йир мәсьәләсе», «Аваз» газетасында «Икенче съезддагы тәэсоратым» дигән мәкаләләре бастырыла.

2 август. Х. Әхтәмовның «Вакыт» газетасында бастырылган «Русия мөселманнарының гомуми съезды» исемле мәкаләсендә Г. Ибраһимовның Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездында революционный комиссиягә әгъза итеп сайлануы хакында әйтелә.

6 август. Русия мөселманнарының икенче съездында сөйләгән чыгышы «Вакыт» газетасында бастырыла.

7 август. Казаннан «Ирек» газетасына телеграмма җибәрә; «Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнарының икенче җыелышыннан кайткач» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 август. Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездында вәкил булып катнашуы хакында «Корылтай» газетасында белдерү бастырыла.

Август. Укытучы Вәсфи Гыйльмияров (1893–1978) блокнотына автограф яза.

11 август. «Ирек» газетасында «Бөтенрусия мөселманнарының икенче җыелышы» дигән мәкаләсе бастырыла. Газетаның шул ук санындагы «Татар социалист-революционерлар оешмасының Вакытлы мәркәз комитеты төзелде» дигән мәкаләдә комитетка сайланган җиде кешенең беренчесе итеп Г. Ибраһимов күрсәтелә.

18 август. «Безнең көннәр» романы нәшер ителәчәге хакында «Ирек» газетасында белдерү бастырыла.

18 август. «Ирек» газетасында «Ялгыш аңламаңыз» дигән мәкаләсе бастырыла.

Уфада мөселман «Ханымнар җәмгыяте» мөгаллимәләр өчен ачкан җәйге курсларда укыта.

3 сентябрь. «Ирек» газетасында «Пычракларыгызны үзегезгә кайтарабыз» дигән мәкаләсе бастырыла.

4 сентябрь. «Ирек» газетасында «Башкортстан мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

Сентябрь. «Ирек» белән революцион мөселман студентлары оешмасы органы «Солдат теләге» газеталары берләштерелеп «Безнең юл» исеме белән чыга башлаган газетаның мөхәррире була.

21 сентябрь. Уфа вилаять халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционерлар оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башлау комиссиясендә катнаша һәм әгъза итеп кертелә.

«Безнең юл» газетасында «Без ник берләштек?» дигән мәкаләсе бастырыла.

23, 24, 29, 30 сентябрь. Уфа вилаять халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционерлар оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башлау комиссиясендә катнаша.

2, 7, 8, 9 октябрь. Уфа вилаять халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционерлар оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башлау комиссиясендә катнаша.

9 октябрь. Уфада большевиклар үткәргән демонстрациядә чыгыш ясый.

19 октябрь. Уфа вилаять халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционерлар оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башлау комиссиясендә катнаша.

«Безнең юл» газетасында «Галимҗан Ибраһимов мәктүбе (Мәсләкме, дипломмы?)» дигән хаты бастырыла.

22 октябрь. «Безнең юл» газетасына хат яза.

30 октябрь. Уфада вилаять мәҗлесендә катнаша һәм Милли мәҗлескә әгъза булып сайлана.

8 ноябрь. Уфа вилаять халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционерлар оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башлау комиссиясендә катнаша.

«Безнең юл» газетасында «Федерация, җиргә социализация» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 ноябрь. Уфа мөселман социалистларыннан Учредительный собраниегә вәкил булып сайлануы хакында «Йолдыз» газетасында мәгълүмат бастырыла.

19 ноябрь. «Безнең юл» газетасында «Эшче халык» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Мохтарият» журналының 4 нче санында Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының беренче Милләт Мәҗлесенә әгъза булып килүе хакында белдерү бастырыла (б. 14–15).

20 ноябрь. Уфада уздырылган «Милли мәҗлес» җыелышында катнаша.

26 ноябрь. «Мохтарият» журналының 1917 елгы 4 нче санында (б. 1–15) Г. Ибраһимовның Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының беренче Милләт Мәҗлесендә яңа канун ляихәләре комиссиясенә сайлануы хакында мәгълүмат китерелә.

27 декабрь. «Безнең тавыш» газетасында «Мөхбир» имзалы авторның «Милләт Мәҗлесе хәбәрләре» дигән мәкаләсендә Г. Ибраһимовның Милләт Мәҗлесеннән башкортлар съездына китүе хакында мәгълүмат китерелә.

Казанда «Сабах» көтепханәсе тарафыннан «Татар нәхүе» (5 нче басмасы) (84 б.), «Татар сарыфы» (4 нче басмасы) (52 б.) дигән дәреслекләре нәшер ителә.

«Тугры, гомуми, тигез, яшерен һәм мөтәнасыйп сайлауга нигезләнгән Учредительный собрание» дигән китапта (Казан, 1917, б. 29) Татар әдәбияты хадимнәренең Үзәк союзының председателе буларак имза куйган.

**1918**

5 гыйнвар. Петроградта Учредительное собрание ачылышында катнаша.

6 гыйнвар. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты декреты белән Учредительное собрание таратыла.

10 гыйнвар. Эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларының III Бөтенроссия съездында Уфа губернасыннан делегат булып катнаша (билет № 846), «Россия халыкларының хокуклар декларациясе»н кабул итүдә тавыш бирә.

14 гыйнвар. «Шура» газетасы аның большевикларга кушылып, Учредительное собраниене ташлап чыгып китүе хакында яза.

15 гыйнвар. Советларның Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетына 18 апрельгә кадәр әгъза булып сайлана (билет № 118).

17 гыйнвар. Совет хөкүмәтенең В. И. Ленин имзалаган декрет белән Халык комиссарлары Советы янында Үзәк мөселман комиссариаты төзелә. Комиссариатның рәисе итеп Мулланур Вахитов (1885–1918), ә аның урынбасарлары итеп Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов билгеләнә. Г. Ибраһимов шулай ук комиссариатның коллегия әгъзасы һәм төрле вакытта төрле бүлекләрнең мөдире дә була.

18 гыйнвар. Үзәк мөселман комиссариатының басма органы булган «Чулпан» газетасы оештырыла һәм аның фактик мөхәррире була.

«Чулпан» газетасында «Мәрхүм Учредительное собрание» дигән мәкаләсе бастырыла.

20 гыйнвар. Смольнига 1 мартка кадәр кереп йөрү өчен 231 санлы рөхсәт кәгазе бирелә.

24 гыйнвар. «Чулпан» газетасында «Федерация, тупраклы мохтарият һәм шуралар хөкүмәте» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 гыйнвар. «Чулпан» газетасында «Идел-Урал җөмһүрияте», «Татар матбугаты» дигән мәкаләләре бастырыла.

30 гыйнвар. «Кызыл Армия» газетасында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән «Габдулла Кариев иптәш рухына» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 гыйнвар. «Чулпан» газетасында «Бөек бәйрәм! Җиргә социализация канун булып кабул кылынды!», «Монахлар ни өчен кузгалды?» дигән мәкаләләре бастырыла.

1 февраль. Казан һәм Уфа белән телеграф аркылы сөйләшү өчен рөхсәт бирелә.

19 февраль. «Сугыш сафы» газетасында «Илгә кайтачак гаскәри иптәшләргә» дигән мәкаләсе бастырыла.

20 февраль. «Чулпан» газетасында «Бөек өмидләр алдында» дигән мәкаләсе бастырыла.

23 февраль. «Чулпан» газетасында «Авыр трагедия», «Җиңеләләр! Идел-Урал җөмһүриятендә хакимият мәсьәләсе», «Тупраклы мохтарият хакында (Казан белән тугыры чыбык аркылы сөйләшү)» дигән мәкаләләре бастырыла.

28 февраль. Сул социалист революционерлар (эсерлар) фиркасе белән арасын фактик яктан өзә.

28 февраль. «Чулпан» газетасында «Чулпан» һәм комиссариат» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 март. «Чулпан» газетасында «Шатлык түгел, мәҗбүрият» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 март. Эчке Россия мөселманнары комиссариатының Баш коллегиясе утырышы эшендә катнаша.

8 март. «Чулпан» газетасында «Караңгылык эчендә» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 март. Хөкүмәт бинасына 1 июньгә кадәр керү өчен 141 санлы рөхсәт кәгазе бирелә.

22 март. Русия Шуралар федерациясенең Татар-Башкорт Шуралар җөмһүрияте нигезләмәсен имзалауда катнаша.

30 март. «Чулпан» газетасында «Бөек бәйрәм! Милли вә икътисади азатлык юлында Татар вә Башкорт җөмһүрияте!», «Сул социалист-революционерларның хөкүмәттән чыгуы мөнәсәбәте белән бер изах» дигән мәкаләләре бастырыла.

13 апрель. Татар-башкорт республикасы съездын чакыру буенча Комиссариатның беренче утырышында катнаша.

18 апрель. Г. Батталның «Алтай» газетасында бастырылган «Милләт мәҗлесе» дигән мәкаләсендә Учредительное собрание таратылу белән, аның татар әгъзаларыннан М. Вахитов, Г. Ибраһимов вә Ш. Манатов, сул социалистлар белән чыгып китүләре һәм шул вакытта Петербургта дәвам

иткән 3 нче Советлар съездына барып кушылулары, бераздан Эчке Русия мөселманнары комиссариаты төзүләре турында әйтелә.

28 апрель. Уфада татар, башкорт эшчеләренең җыелышында катнаша һәм чыгыш ясый.

30 апрель. «Чулпан» газетасында «Комиссариатның эшләячәк эшләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 май. «Көрәш» газетасында «Бөек бәйрәм (1)» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 май. Уфада эшчеләр клубында татар, башкорт эшчеләре җыелышында доклад белән чыгыш ясый.

6 май. «Правда» газетасында «Совещание по созыву Учредительного съезда Татаро-Башкирской республики в г. Москве. Доклад тов. Ибрагимова» дигән мәкалә бастырыла.

10 май. Казанда Бөтенрусия мөселман укытучыларының 3 нче корылтаенда риясәткә әгъза итеп сайлана.

16 май. Мәскәүдә Милләтләр комиссариаты һәм Татар-башкорт комиссариаты үткәргән киңәшмәдә катнаша һәм чыгыш ясый.

23–31 май. Казанда Бөтенрусия мөселман укытучыларының III съезды эшендә катнаша. 1 нче утырышта Мәркәз мөселман комиссариаты исеменнән корылтайны котлап чыгыш ясый. 2 нче утырышта хәзерге хәлләр хакында доклад укый. 5 нче һәм 9 нчы утырышларын ача, ягъни рәислек итә. Съездан соң Уфага китә.

Съездда ясаган чыгышы «Укытучы» журналының 5–6 кушма санында (б. 155–164) бастырыла.

28 май. «Чулпан» газетасында «Татар-башкорт шуралар җөмһүриятенең Учредительный корылтаен җыю хакындагы киңәш мәҗлесе. Галимҗан Ибраһимов доклады» дигән мәкалә бастырыла.

30 май. «Эш» газетасында Бөтенрусия мөселман укытучыларының өченче съездында ясаган чыгышы бастырыла.

9 июнь. Уфа милли эшләр комиссары Владимир Егошин (?–?) Г. Ибраһимовны Уфага ашыгыч рәвештә чакырып телеграмма җибәрә. Аны алгач, Г. Ибраһимов һәм Казан милли эшләр комиссары Сахибгәрәй Сәетгалиев (1894–1939) Уфага китәләр.

24 июнь. «Чулпан» газетасында «Гъ.» имзасы белән «Халык корбаннары» дигән мәкаләсе бастырыла.

4 июль. «Эш» газетасында «Үзәк мөселман комиссариаты коллегиясенең киңәшмәсе турында» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 июль. Советларның V Бөтенроссия съезды мөселман делегатлары киңәшмәсендә яңадан Комиссариатның рәис урынбасары һәм коллегия әгъзасы итеп сайлана.

24 июль. Мәскәүдә төрек социалист-коммунистларның конференциясендә чыгыш ясый.

24 июль. Мәркәз мөселман комиссариаты вәкиле буларак, Мәскәүдә Милли идарә фондларыннан акчаларны Мәркәз мөселман комиссариатына күчерү мәсьәләсен карауда катнаша.

26 июль. «Чулпан» газетасында «Бөек өмидләр юлында» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 август. Казаннан «Ирек» газетасына телеграмма җибәрә. Анда: «Русия мөселманнарының 2 нче җыелышының карарлары бөтенләй байлар файдасын күзәтә, 1 нче съездда кабул кылынган җир, хатын-кызларның хокукы һәм федерация хакындагы карарларын бозды, авыл кешеләре разый түгелләр…» – дип белдерә.

7 август. Вакытлыча Үзәк мөселман комиссариаты рәисе вәкаләтләре бирелә.

15 август. Үзәк мөселман комиссариаты рәисе урынбасары буларак, Ш. Әхмәдиевкә бирелгән Үзәк мөселман комиссариатының Үзәк коллегия әгъзасы таныклыгын имзалый.

19 август. Үзәк мөселман комиссариаты рәисе урынбасары буларак, Ш. Әхмәдиевкә бирелгән Үзәк мөселман комиссариаты мәгариф бүлеге мөдире урынбасары таныклыгын имзалый.

20 август. Әстерхан Мөселман комиссариаты рәисе Касыйм Шаһиҗан Туйбактин (1887–1918) үтерелү уңаеннан Мәскәүдән Әстерхан Мөселман хәрби комиссариатына телеграмма җибәрә.

24 август. «Чулпан» газетасында «Мәркәз комиссариатының мәрхүм Милли идарә эшләре хакындагы хисабы мөнәсәбәте илә бер-ике сүз» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 сентябрь. 1918 елның 30 августында Михельсон заводында Ленинга һәм Петроградта М. С. Урицкийга (1873–1918) булган һөҗүмнәр уңае белән Ленинга хат яза.

17 сентябрь. Мәскәүдә хастаханәгә ята.

6 октябрь. Мәскәүдә хастаханәдән чыга.

Октябрь урталары. Казанга кайта. «Чулпан» газетасы да Казанга күчерелә һәм 12 мартта Казан Мөселман комиссариаты тарафыннан чыгарылган көндәлек сәяси, әдәби, иҗтимагый «Эш» газетасы белән берләштерелә.

17 октябрь. Үзәк мөселман комиссариатында эшләве тәгәлләнә.

7 ноябрь. «Эш» газетасында «Мәркәздә һәм урыннарда мөселман комиссариатлары» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 ноябрь. Ул оештырган «Мәгариф» журналының 1 нче саны чыга.

Казанда «Сабах» ширкәте тарафыннан «Татар сарыфы. Бөтенләй яңадан эшләнгән бишенче басмасы» (84 б.), «Әдәбият кануннары. Икенче басма» (120 б.), «Татар нәхүе», «Тел сабаклары. Беренче китап» (36 б.), «Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» (76 б.), «Яңа әдәбият. Беренче китап. Мәктәпләр өчен. Бөтенләй яңадан эшләнгән өченче басмасы» (144 б.) дәреслекләре нәшер ителә.

Журналист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе Газыйм Касыймов (1891–1938) тарафыннан төзелеп Мәскәүдә нәшер ителгән «Милли идарәдә татар кадетлары ни эшләгәннәр? (Хисап урынында)» дигән китапта «Бер-ике сүз» исемле кереш мәкаләсе бастырыла (б. 3–18).

## 1919

Гыйнвар. Татар теленең хәрефе һәм орфографиясе буенча 1 нче Бөтенрусия конференциясендә катнаша.

6 февраль. Шәрык поездына лектор итеп билгеләнү турында телеграмма ала.

19 февраль. 18 февральдә Кече Башкортстан хөкүмәте белән Шуралар хакимияте арасында килешү булганлыгы турында М. Солтангалиев Уфадан Г. Ибраһимовка телеграмма белән белдерә.

21 февраль. М. Солтангалиев Кече Башкортстан мәсьәләсе турында Уфадан Г. Ибраһимовка телеграмма җибәрә. Г. Ибраһимов башта Мәскәүгә, аннан Уфага китә.

10, 11, 12 март. «Эш» газетасында «Иҗтимагый революция вә татар зыялылары» дигән мәкаләсе бастырыла.

14 апрель. Казаннан Мәскәүгә Милләтләр эшләре буенча халык комиссариатына, Үзәк Татар-Башкорт комиссариатына, Үзәк Бюрога телеграмма җибәрә.

7 сентябрь. «Кызыл яу» газетасында «Дошманнар арасында дүрт ай» дигән мәкаләсе бастырыла.

14 сентябрь. «Кызыл Армия» газетасында «Галимҗан Ибраһимов хатирәләре дигән мәкалә бастырыла.

15 сентябрь. «Эш» газетасында «Тыңлаучы» имзасы белән «Дошманнар арасында дүрт ай (хисап докладымның фиһристы)» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 сентябрь. «Кызыл Армия» газетасында «Галимҗан иптәш Ибраһимов хатирәләре (Дошманнар арасында дүрт ай)» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 ноябрь. «Кызыл Армия» газетасында «Еллык хисап урынында» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 декабрь. «Кызыл Армия» газетасында «Бөек тарихи мәсьүлият алдында» дигән мәкаләсе бастырыла.

26, 28 декабрь. «Кызыл Армия» газетасында «Шәрык пролетариаты вәкилләре арасында» дигән мәкаләсе бастырыла.

Октябрь аенда туган авылына кайтып китә.

Ул төзегән «Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» (100 б.) дигән хезмәте, аның мөхәррирлегендә «Бөек Октябрь революциясе» дигән мәҗмуга; «Сабах» ширкәте тарафыннан «Татар нәхүе. Бишенче басмасы» (52 б.), «Яңа әдәбият. Икенче китап. Урта мәктәпләр, курслар, семинарияләр һәм мәдрәсәләр өчен. Бөтенләй яңадан эшләнгән өченче басмасы», «Әдәбият кануннары. Өченче басма» (127 б.), «Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)» (78 б.) дәреслекләре, «Тел сабаклары. Икенче басма (Гамәли имля, иншага, сарыф, нәхүгә хәзерлек)» (47 б.) дәреслекләре; «Мәгариф» нәшриятында «Яз башы» (12 б.) хикәясе нәшер ителә.

«Шәрыкнең бөек ревлюционеры Мулланур Вахитов» мәҗмугасында «Мулланур Вахитов иптәшнең кыскача тәрҗемәи хәле» (б. 3–11), «Шә-

рыкнең бөек революционеры Мулланур Вахитов» (б. 15–38), «Мулланур иптәшнең кадерле мираслары» (б. 90), «Иҗтимагый революция мәҗмугалары» (б. 92–94) исемле мәкаләләре бастырыла.

**1920**

Гыйнвар. «Сабанчы» журналының 1 нче санында «Авылда яңа эшләр, яңа кешеләр» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 6–8).

«Кызыл Шәрык» журналының 1, 2, 3–4 (кушма) нче саннарында «Сарайларга – сугыш, фәкыйрә өйләргә – туганлык!» (б. 4–13; 55–67; 116–123); «Шәрыкнең бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» (б. 44–46) дигән мәкаләләре бастырыла.

7 гыйнвар. «Эшче» газетасында «Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми-әдәби коллективлар» дигән мәкаләсе бастырыла.

30 гыйнвар. «Кызыл Армия» газетасында «Габдулла Кариев иптәш рухына» дигән мәкаләсе бастырыла.

10 февраль. «Эш» газетасында «Печән базары» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 февраль. «Эшче» газетасында «Яңа савытта иске эчемлекләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

18 март. «Кызыл Армия» газетасында «Париж пролетариатының диктатурасы» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 апрель. «Кызыл Армия» газетасында «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин», «Эшче» газетасында «Ленинның әдәби хезмәтләре» дигән мәкаләләре бастырыла.

25 апрель. «Биш ел эчендә. 1925. 25. VI. 1920» җыентыгында «Бу биш ел татар мәдәниятенә нәрсә бирде?» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 107–140).

«Кызыл Шәрык» журналының 3–4 кушма санында (б. 142–145) Ф. Сәйфи-Казанлының «Безнең көннәр» романы» дигән бәяләмәсе бастырыла.

1 май. «Кызыл Армия» газетасында «Җиңел хатирәләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

20 май. «Эшче» газетасында Сәлах Атнагуловның (1893–1938) «Безнең көннәр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

7 июль. Губерна комитеты Бюросы Мәскәүдә милләтләр советына вәкил итеп раслый.

«Кызыл Шәрык» журналының 7–8 кушма санында «Мәсьәлә чишелде (Хәреф-имля хакындагы карарлар һәм декрет)» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 241–244).

26 сентябрь. Казанда Татарстан республикасы советларының 1 нче учредительный съездында катнаша. Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына әгъза итеп сайлана.

13 октябрь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Кара куллар» дигән мәкаләсе бастырыла.

18 октябрь. «Эшче» газетасында «Кызыл штык һәм кызыл каләм» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 октябрь. «Эшче» газетасында «Татар әдәбиятына кергән яңа сүзләр хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

29 октябрь. «Эшче» газетасында «Кызыл каләмгә юл ачылсын (Сәетгалиев, Фәтхи Бурнаш һәм Шәфигуллин иптәшләрнең мәкаләләре мөнәсәбәте белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 октябрь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Кара куллар» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 ноябрь. «Эшче» газетасында «Дүртенче елга кергәндә (Әдәбият, матбугат хисабы урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 ноябрь. «Кызыл Армия» газетасында Ш. Байчураның [Шәриф Байчураның, 1892–1971] «Яңа кешеләр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

14 ноябрь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында Ф. Сәйфи-Казанлының «Яңа кешеләр» драмасы» дигән бәяләмәсе бастырыла.

22 ноябрь. Бөтенроссия Шәрык журналистлары һәм матбугат хадимнәренең киңәш мәҗлесендә ясаган «Пролетариат әдәбияты һәм матбугаты» дигән доклады «Татарстан хәбәрләре» газетасында бастырыла.

3 декабрь. РКП(б)га әгъза итеп кабул ителүе хакында «Эшче» газетасында «Эшче-крестьян иптәшләргә белдерү» дигән белдерүе бастырыла.

4 декабрь. «Яңа кешеләр» драмасы өчен Гыйльми үзәкнең сәнгать бүлеге, бер ел авторлык гонорары түләмәү шарты белән, 150000 сум күләмендә премия бирү хакында карар кабул итә.

7 декабрь. РКП(б)га әгъза итеп кабул ителүе хакында «Кызыл Армия» газетасында «Эшче-крестьян иптәшләргә белдерү» дигән белдерүе бастырыла.

23 декабрь. РКП(б)ның Казан шәһәре Болак арты-Пләтән районы комитеты утырышында Г. Ибраһимов партия әгъзасы итеп раслана һәм аның партия стажы 1917 елдан билгеләнә.

29 декабрь. «Эшче» газетасында «Истилахлар һәйәтеннән» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Кызыл Шәрык» журналының 5–6 нчы кушма санында «Шәрык халыклары съезды» дигән мәкаләсе бастырыла.

Казанда «Өмид» матбагасында «Безнең көннәр» романының беренче варианты; «Корылтай» нәшриятында «Табигать балалары» хикәясенең икенче басмасы; «Караңгы төннәрдә» дигән җыентыкта «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (б. 2–6), «Уты сүнгән җәһәннәм» (б. 7–17), «Габдрахман Салихов» (б. 19–32), «Көтүчеләр» (б. 4–23), «Карт ялчы» (б. 24–57), «Диңгездә» (б. 58–79) хикәяләре; «Табигать балалары» хикәясенең икенче басмасы; «Яңа кешеләр» драмасы; «Яңа әдәбият» дәреслеге беренче кисәгенең дүртенче басмасы нәшер ителә.

**1921**

Гыйнвар. Ел башында М. Гафуриның Казанда аерым китап булып нәшер ителгән «Эшче» поэмасына «Берничә сүз» дигән кереш мәкаләсе бастырыла (б. 2–8).

7 гыйнвар. «Эшче» газетасында «Яңа мәдәният төзү юлында гыйльми, әдәби коллективлар» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 гыйнвар. «Эшче» газетасында «Коммунизм әлифбасы» дигән бәяләмәсе бастырыла.

14 февраль. «Яңа кешеләр» драмасына карата тәнкыйтькә «Эшче» газетасында «Кара интригаларга юл бирелмәсен!» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 февраль. «Эшче» газетасында «Яңа савытта иске эчемлекләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 март. «Эшче» газетасында «РКПның өлкә конференциясе» дигән хисап мәкаләсе бастырыла.

21 март. Ф. Әмирханга хат яза.

21 апрель. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Иҗтимагый икътисад гыйлемендә беренче тәҗрибәләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 апрель. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Иҗтимагый икътисад» гыйлемендә беренче тәҗрибәләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 май. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Бөек тарихи юл буенча» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 май. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Яңа әсәрләр (1)» дигән мәкаләсе бастырыла.

13 июнь. РКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Төрки халыклары үзәк бюросының матбугат бүлеге редакцион коллегиясе җитәкчесе итеп билгеләнә.

21 июнь. РКП(б) Үзәк Комитеты төрки халыклар арасында агитация һәм пропаганда Үзәк Бюросының нәшрият бүлеге РКП(б) Өлкә конференциясендә киңәшләшү тавышына хокук белән катнаштыруны сорап мандат комиссиясенә мөрәҗәгать итә.

25–28 июнь. Эшче, крестьян һәм кызылармияче Советлары делегатларының 2 нче Бөтенроссия съездында катнаша.

29 июнь. Татарстан АССРы төзелүгә бер ел тулу уңаеннан «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Икенче елга кергәндә» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 июль. 16 нчы Казан мөселман пехота курсларында сәяси белем укытучысы итеп билгеләнә.

5 сентябрь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Кавказ курортлары» дигән мәкаләсе бастырыла.

26 сентябрь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Мең дә бер мәртәбә!» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 сентябрь. 6 нчы Дәүләт типографиясенең партиясез эшчеләре җыелышында РКП(б) әгъзалары арасында чистарту мәсьәләсе тикшерелеп, Г. Ибраһимов кандидатурасы уңай бәяләнә.

РКП(б) әгъзалары арасында чистарту кампаниясе вакытында полиграфия эшчесе, РКП(б) әгъзасы Әхмәт Җиһаншинга (?–?) уңай тәкъдимнамә, РКП(б) әгъзасы Кояш Вәлитованың (1898–1985) автобиографиясенә раслау яза.

РКП(б) әгъзалары Т.М. Гайнуллин, Борһан Мансуров (1882–1942), Саттар Еникеев (1885–1939), имзасы аңлашылмаган тагын бер кеше Г. Ибраһимовка уңай тәкъдимнамә яза.

27 сентябрь. РКП(б)ның Казан шәһәре Болак арты-Плэтән районы комитеты утырышында партия әгъзалары арасында чистарту мәсьәләсе тикшерелеп, Г. Ибраһимов партия әгъзасы итеп калдырыла.

26 октябрь. Төркиядәге сәяси вазгыять хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Мең дә беренче мәртәбә!» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 ноябрь. Октябрь түнтәрелешенең дүрт еллыгы уңае белән «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Бишенче елга кергәндә мәдәни-икътисади мәсьәләләр» дигән мәкаләсе бастырыла.

4 декабрь. Журналист буларак анкета тутыра.

«Кызыл Шәрык» журналының 7–8 кушма санында «Мәсьәлә чишелде» дигән мәкаләсе бастырыла.

Казанда «Сабах» ширкәте тарафыннан «Татар сарыфы. Бөтенләй яңадан эшләнгән 5 нче басма» (84 б.) дәреслеге; «Күчмә уку китаплары. Беренче төп.– беренче китап»та «Авыл мәктәбендә» (б. 3–7), «Иске мәдрәсәдә беренче көннәр» (б. 12–16) әсәрләре; Татар социал шуралар җөмһүриятенең дәүләт нәшриятында «Яз башы» (16 б.); «Мәгариф» ширкәте тарафыннан «Көтүче карт» (27 б.) хикәяләре; «Өмид» матбагасында «Яңа кешеләр. Драма, 3 пәрдәдә (Вакыйга 1918–19 нчы елларда Идел-Урал тупрагында)» китабы нәшер ителә.

**1922**

«Наука и просвещение» журналының 1 нче санында (б. 19–21) Павел Фалевның (1888–1922) «Татарский революционный роман» дигән бәяләмәсе бастырыла [«Безнең көннәр» романы турында].

«Шәрык яшьләре» журналының 1 нче санында «Безнең вазифалар» дигән Мөхәммәт Парсинның (1899–1963) шул исемдәге әсәренә бәяләмәсе бастырыла.

«Безнең юл» журналының 1 нче санында (б. 79–84) «Төрле кавемнәрнең матбугаты – әдәбият тирәсендә» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Кызыл Шәрык» журналының 2 нче санында (б. 23–25) «Безнең заманның Әбуҗәһелләре, Ишмиләре, Пуришкевичлары (Яшьләргә ачык хат урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 гыйнвар. РКП(б) әгъзаларының Бөтенроссия исәп алу анкетасын тутыра.

17 гыйнвар. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Яңа әсәрләр (1)» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 гыйнвар. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Зур Башкортстан мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 гыйнвар. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Татар сәхнәсе («Янгура» уйналуы мөнәсәбәте белән») дигән мәкаләсе бастырыла.

Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

1 февраль. РКП(б) Өлкә комитеты секретариаты утырышында татар телендә сәяси-икътисади әдәбият кытлыгы һәм бу мәсьәләне хәл итү юнәлешендә конкрет тәкъдимнәре тыңлана.

2, 3 февраль. Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

3 февраль. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Габди» имзасы белән «Моны пролетариат кына эшли алачак» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 февраль. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Татар әдәбияты (Хисап урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

10 февраль. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Әдипләр, шагыйрьләр, наширләр, басмаханәчеләр дикъкатенә» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

12 февраль. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Әдипләр, шагыйрьләр, наширләр, басмаханәчеләр дикъкатенә» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

12 февраль. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк коллегиясе әгъзасы таныклыгы бирелә.

14, 15 февраль. Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

17, 20 февраль. «Безнең көннәр» романы һәм «Яңа кешеләр» драмасының сатылуы хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

23 февраль. «Кызыл Армия» газетасында «Пролетариат кылычы (Эшче-крестьян Кызыл ордасының дүрт еллык бәйрәме)» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 март. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Тарихи кыңгыравык өзелде (Рәшит бабай үлде)» дигән мәкаләсе бастырыла. Ул «Мөхбир» имзасы белән берәүнең Ташкентта чыга торган «Кызыл байрак» исемле газетадагы Рәшит казый Ибраһимов хакында ялгыш мәгълүматтан алып, «Татарстан хәбәрләре» газетасының 24 февраль санында бастырган «Рәшит казый белән шагыйрь Вәкыйф Җәлал үлгәннәр»[1] дигән мәкаләгә нигезләнгән.

«Безнең юл» журналының 3 нче санында «Татар-башкорт пролетариаты хакында материал җыю мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

---

[1] *Рәшит казый белән шагыйрь Вәкыйф Җәлал үлгәннәр* – Рәшит (Габдерәшит) Гомәр улы Ибраһимов (1857–1944) – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист. Япониядә вафат була.

*Вакыйф Җәлал (1886–1922)* – шагыйрь. Мәкаләдә аның Ташкентта вокзалда вафат булганлыгы хакында әйтелә.

7 март. Җ. Вәлидинең «Татарстан хәбәрләре»нең 5 март санында чыккан «Әдәби мөсәхабә» исемле мәкаләсенә карата «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Аңларга тырышыгыз!!» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 март. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Татар хатынының үсүе» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 март. Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителүе хакында «Татарстан хәбәрләре» газетасында белдерү бастырыла.

20 март. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Татарның соңгы тарихында өч дәвер (Эпоха) («Аңлау юллары»)» дигән мәкаләсе бастырыла.

21 март. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Бөек өмидләр алдында (Яшь талантлар)» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 март. Милләтләр эшләре буенча комиссариат янындагы Бөтенроссия Көнчыгышны өйрәнү ассоциациясе әгъзасы итеп сайлана.

3 апрель. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Янгура» мөхәрриренең изахы» дигән мәкаләсе бастырыла.

4 апрель. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында сәяси уку әсбаплары төзү хакында доклад укый.

28 апрель. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Өч җавап («Ярдәм» – «Хисап» – Әдәби мизан)» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 май. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Революция тарихына материаллар (Кыска бер фиһрист)» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 май. Журналист буларак анкета тутыра.

16 май. «Татарстан» газетасына беркетелә.

19 май. «Татарстан хәбәрләре» газетасында «Каюм Насыйриның вафатына егерме ел тула» дигән мәкаләсе бастырыла.

Май ае. РКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты тарафыннан «Татарстан» газетасына беркетелә.

Май. «Безнең юл» журналының 1, 2 нче саннарында «Иҗтимагыйәдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» (б. 28–41), (б. 40–46); 4 нче санында «Татар-башкорт пролетариаты хакында материал җыю мәсьәләсе (Атнагулов-Гомәров моназаралары мөнәсәбәте белән)» (б. 42–45) дигән мәкаләләре бастырыла.

31 май. РКП(б)ның Болак арты-Пләтән район комитеты тарафыннан аңа партия билеты (№ 348327) тапшырыла.

13 июнь. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша; Каюм Насыйриның (1825–1902) вафатына 20 ел тулуны билгеләп үтү кирәклеге хакында доклад укый.

18 июнь. «Кызыл чәчәкләр» хикәясе нәшер ителгәне хакында «Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

20 июнь. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша.

20 июнь. Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче кисәге нәшер ителгәне хакында «Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

27 июнь. «Татарстан» газетасында «Татар җөмһүриятенең икенче елында әдәбиятыбызның язмышы (Хисап урынында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 июнь. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша; Г. Гобәйдуллин һәм Гали Рәхимнең (1892–1943)»Татар әдәбияты тарихы»на язган бәяләмәсе тыңлана.

21 июль. «Татарстан» газетасында «Революция һәм әдәбият тарихларын эшләү юллары» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 август. Казаннан Уфага журналист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе Газыйм Касыймовка (1891–1941) һәм язучы, җәмәгать эшлеклесе Давыт Юлтыйга (1893–1938) хат яза.

15 август. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша; «Әдәбият кануннары» дигән китабын кабат бастыру мәсьәләсе карала.

23 август. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша; дәреслекләр хакында доклады тыңлана.

5 сентябрь. Гыйльми үзәк янындагы Татар редакциясе комиссиясе утырышында катнаша; әдәбиятчы Габдрахман Сәгъдинең (1889–1956) «Татар әдәбияты» дигән китабына бәяләмә әзерләү тапшырыла.

13 сентябрь. Партиянең Татарстан өлкә комитеты карары нигезендә Татар коммунистик университетына (ТКУ) эшкә чакыру хакында карар чыгара.

22 ноябрь. Качалов исемендәге Зур драма театрында «Яңа кешеләр» пьесасының премьерасы куела.

Аның җитәкчелегендә төзелгән «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»ның 1 һәм 2 нче китаплары нәшер ителә. 1 нче китапта «Ярдәм юлында» (б. 2), «Вакытсыз һәлак булды» (б. 4–11), «Бабичның зәмине һәм әсәрләре» (б. 12) дигән мәкаләләре, «Без түбәннән күтәрелдек» (б. 122–130) исемле әсәре; 2 нче китапта драматург Фәтхи Бурнаш (1898–1942) белән берлектә язылган «Ярдәм юлында…» (б. 2), «Ярдәм» мәҗмугалары идарәсеннән» (арткы тышлыкта) дигән мәкаләсе, «Алмачуар (Бер мәхәббәтнең тарихы)» исемле хикәясе бастырыла (б. 4–40).

Татар социал шуралар җөмһүрияте нәшриятында «Алмачуар» (43 б.), «Кызыл чәчәкләр» хикәясе (Без түбәннән күтәрелдек)» (148 б.), «Көтүчеләр» (23 б.), «Диңгездә» (20 б.), «Ялчы карт» (27 б.) хикәяләре; «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (147 б.), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» (42 б.) хезмәтләре нәшер ителә.

Аның редакциясендә «Шәехзадә Бабич. Шигырь мәҗмугасы. Беренче китап» (163 б.) дигән китап нәшер ителә һәм анда «Вакытсыз һәлак булды» исемле мәкаләсе урнаштырыла (б. 5–24).

«Каюм Насыйри мәҗмугасы»нда «Каюм Насыйриларның тарихи урыннары» (б. V–XIV), «Яңа әдәби татар теленең беренче баскычларында» (б. 150–160) дигән мәкаләләре бастырыла.

Драматург Мирхәйдәр Фәйзинең (1891–1928) «Галиябану» драмасына сүз башы итеп «Галиябану» хакында бер-ике сүз» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 3–5).

«Беренче баскыч эш мәктәпләренең өченче уку еллары өчен гамәли тел сабаклары (икенче китап). Сарыф-нәхүгә хәзерлек өчен мәсьәләләр, тикшерү һәм күнегү өчен мисаллар, сөйләү һәм өслүб куәләрен арттыру өчен рәсемнәр, мәүзугълар, планнар» дигән дәреслекне төзүдә катнаша.

**1923**

6 февраль. «Татарстан» газетасында Г. Газиз һәм Г. Рәхимнең «Татар әдәбияты тарихы» исемле китабы хакында «Татар әдәбияты тарихына материаллар» дигән мәкаләсе бастырыла.

13 февраль. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында шагыйрь Һади Такташның (1901–1931) шигырьләр җыентыгына бәяләмәсе тыңлана.

«Мәгариф» журналының 2 (12) нче санында «Латин хәрефләре алыргамы? Гарәп хәрефләрен ислах итәргәме?» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 4–19).

«Мәгариф» журналының 2 (12) нче санында «Россия коммунист большевиклар партиясенең 25 еллык бәйрәме» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 43–50).

6 март. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында шагыйрь Миргазиз Укмасиның (1884–1948) Гыйльми үзәккә тапшырган кульъязмаларына бәяләмәсе тыңлана.

«Безнең байрак» газетасында «Партиянең 25 еллык бәйрәме белән» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 март. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында дингә каршы пропаганда максатында алты брошюра бастыру мәсьәләсе хакында доклады тыңлана.

Март, апрель. «Мәгариф» журналының 3–4 (13–14) нче кушма санында «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында (Әдәбиятыбызны укыту рәвешләре хакында кайбер төшенчәләр)» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 35–44).

14 март. «Безнең байрак» газетасында «Яшь татар пролетариаты һәм большевизм» дигән мәкаләсе бастырыла.

3 апрель. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында РКП(б) тарихын әзерләп нәшер итү мәсьәләсе хакында чыгышы тыңлана.

4 апрель. Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар (До революции 1917 г.). М.– Пг., 1923» китабы нәшер ителү уңаеннан «Безнең байрак» газетасында «Татар әдәбияты хакында тагы бер әсәр» дигән мәкаләсе бастырыла.

17 апрель. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакциясе коллегиясе утырышында күптән түгел нәшер ителгән «Известия общества археологии, истории и этнографии» җы-

ентыгы советка һәм революциягә каршы характерда булу сәбәпле, аны таратуны тоткарлап торырга тәкъдим итә.

24 апрель. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакциясе коллегиясе утырышында язучы һәм шагыйрь Кави Нәҗминең (1901–1957) шигырьләр җыентыгына бәяләмәсе тыңлана.

4 май. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Г. Гобәйдуллин һәм Г. Рәхимнең «Татар әдәбияты тарихы» (1 том, 2 кисәк), язучы Нәҗип Думавиның (1883–1933) «Иблис»[1] дигән китапларына бәяләмәсе тыңлана.

8 май. «Безнең байрак» газетасында «Әдәби тел мәсьәләсе яңадан күтәрелә. Татар-башкорт телләре хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 май. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Ф. Сәйфи-Казанлының «Татар дине»[2] дигән китабына бәяләмәсе тыңлана.

16 май. Казаннан Уфага М. Гафуриga шагыйрьнең иҗади хезмәтенең 20 еллык бәйрәме якынлашуы уңае белән хат яза.

30 май. «Безнең байрак» газетасында «Татар-башкорт коммунист оешмаларының биш еллыгы» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Яңа юл» журналының 4 нче санында «Ислам тирәсендә» дигән мәкаләсе бастырыла.

3 июнь. М. Гафуриga халык шагыйре исеме бирелү уңае белән «Башкортстан» газетасында «Мәҗит ага!» дигән котлавы бастырыла.

12 июнь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында драматург Кәрим Тинчуринның (1887–1938) «Зар»[3] дигән пьесасына бәяләмәсе тыңлана.

23 июль. «Татарстан» газетасында журналист Хәнәф Наумның (?–?) «Татар әдәбиятында зәһәрле микроб» исемле мәкаләсенә карата шул ук газетада «Аңларга тырышыгыз, туганнар! (җавап түгел, тәҗрибәле сабак)» дигән мәкаләсе бастырыла.

23, 28 август. «Эшче» газетасының чыга башлавына бер ел тулу уңаеннан «Эшче» газетасында «Пролетариат сүзе» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 август. «Безнең байрак» газетасында «Беренче Бөтенрусия күргәзмәсе хакында» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 сентябрь. «Татарстан» газетасында «Әдип Г. Камалның хәле авыр» дигән мәкаләсе бастырыла.

---

[1] Н. Думавиның андый исемдә китабы бастырылмаган.

[2] Сәйфи-Казанлы Ф. Татар дине (Татарның иске, яңа диннәре, боларның сыйнфый-икътисади хәлләргә мөнәсәбәте хакында халык өчен язылган) (Төзәтелгән икенче басма) / Ф. Сәйфи-Казанлы. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшре, 1924. – 50 б.

[3] Тинчурин К. Зар. Бәни адәм фаҗигасе. Алты пәрдәдә / К. Тинчурин. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комитеты нәшре, 1924. – 144 б.

5 сентябрь. «Татарстан» газетасында «Мәсьәләне өзәргә вакыт! (Татар һәм башкорт телләре хакында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 сентябрь. «Татарстан» газетасында «Кәфене муенында, бер-ике көннән җеназасы күтәреләчәк» диләр иде! (Өзек хатирәләр)» дигән мәкаләсе бастырыла.

22 сентябрь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында шагыйрь Төхфәтулла Ченәкәйнең (1893–1959) шигырьләр җыентыгына бәяләмәсе тыңлана.

27 сентябрь. «Татарстан» газетасында «Пролетариат сүзе» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 октябрь. «Татарстан» газетасында «Әдип Г. Камалның хәле авыр» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 октябрь. «Безнең байрак» газетасында «Ислам тирәсендә» (Татар комуниверситетында диндә көрәш кабинеты ачылу мөнәсәбәте белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 октябрь. «Татарстан» газетасында «Татар эшчеләрен ник оныталар?!» дигән мәкаләсе бастырыла.

15 октябрь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында «Адәмнәр»[1] әсәре басмага тәкъдим ителә.

22 октябрь. Казанда татар эшче факультеты ачылуга карата «Татарстан» газетасында «Пролетариатның яңа гыйльми йортлары арта» исемле мәкаләсе бастырыла.

Октябрь, ноябрь, декабрь. «Яшь эшче» журналының 10, 11, 12 нче саннарында «Идеология фронтының ышанычлы көрәшчеләреннән беренә («Яшь эшче» журналының 1 еллыгы уңае белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 декабрь. Казан шәһәр Советына әгъза итеп сайлана.

15 декабрь. 4 нче Бөтентатар Советлары съездында тавыш бирү хокукы белән катнашу өчен мандат бирелә.

10 декабрь. 4 нче Бөтентатар Советлары съездында тавыш бирү хокукы белән катнаша.

23 декабрь. «Эшче» газетасында «Идеология фронтының ышанычлы көрәшчеләреннән беренә («Яшь эшче» журналының 1 еллыгы уңае белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 декабрь. 4 нче Бөтентатар Советлары съездында Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына әгъза итеп сайлана.

Казанда «Адәмнәр», «Күчмә уку китаплары» сериясеннән икенче төпләмгә 16 нчы китап итеп «Алмачуар» хикәяләре нәшер ителә; «Беренче баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфлары өчен гамәли тел сабаклары. Өченче китап. Гамәли сарыф-нәхү» дигән дәреслекне төзүдә катнаша.

---

[1] Ибраһимов Г. Адәмнәр: Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1923.– 50 б.

«Г. Тукайның үлүенә 10 ел тулуга багышлана. 1913–1923» дигән китапта «Татар әдәбиятын тикшерү юлында (Әдәбиятыбызны укыту рәвешләре хакында кайбер төшенчәләр)» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 35–44).

**1924**

1, 10 гыйнвар. «Татарстан» газетасында «Татар әдәбияты (2) (Еллык хисап урынында)» исемле мәкаләсе бастырыла.

9 гыйнвар. «Татарстан» газетасында язучы Гомәр Толымбайскийның (1900–1938) «Адәмнәр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

10, 13, 15, 16 гыйнвар. «Адәмнәр» хикәясе нәшер ителүе хакында «Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

24 гыйнвар. «Татарстан» газетасында «Ленин вафат булды» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 гыйнвар. «Татарстан» газетасында «Ленинны аңлау, өйрәнү юлында» дигән мәкаләсе бастырыла («Ленин вафат булды» дигән мәкаләсенең ахыры).

«Безнең юл» журналының 3 нче санында Шамил Госмановның (1898–1937) «Адәмнәр» дигән бәяләмәсе бастырыла.

7 март. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында педагог Габделхәй Динмөхәммәтов (1892–1922) белән берлектә тәрҗемә ителгән С. Трапезниковның «Мәктәп яны җир участокларын ничек файдаланырга» дигән китабын кабат бастыру мәсьәләсе карала.

Март-апрель. «Октябрь яшьләре» журналының 3–4 нче саннарында «1905 нче ел революциясендә татар яшьләре турында материаллар җыю» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Мәгариф» журналының 3–4 нче кушма санында «Имля-хәреф мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

1 май. «Кызыл Татарстан» газетасында «Беренче Май уйлары» дигән мәкаләсе бастырыла.

5, 9 май. «Кызыл Татарстан» газетасында «Русиядә пролетариат матбугаты тарихыннан» дигән мәкаләсе бастырыла.

13 май. РКП(б)ның Татарстан IX өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән делегат итеп сайлана (мандат № 75).

2 июнь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Бондюг пролетариаты арасында» дигән мәкаләсе бастырыла.

19 июнь. Сезон өчен дачага тулаем акча түләнгәнлеге һәм анда Һ. Такташ яшәячәге хакында Тарасова фамилияле кешегә хат яза.

25 июнь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татарстан җөмһүриятенең дүрт ел эчендә партия оешмасы» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 июнь. Өммегөлсем Давыт кызы Мөхәммәдовага (1903–1988) өйләнә.

9 сентябрь. Казанныңаклардан азат ителүенә 6 ел тулу уңаеннан «Кызыл Татарстан» газетасында «Бу әдәби тикшерүне Казан алынган көнгә багышлыйм» дигән мәкаләсе бастырыла.

14 сентябрь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар телен җиңеләйтү мәсьәләсен чишәргә кирәк» дигән мәкаләсе бастырыла.

28 сентябрь. I Интернационал хакында «Кызыл Татарстан» газетасында «Пролетариатның беренче штабы» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 октябрь. Башглавлит коллегиясе утырышында Уфа үзәк һәм кантон үзәк китапханәләрендә һәм кантон үзәк китапханәләрендә китапларының һәрберсеннән 3 нөсхә генә калдырырга һәм аларны Үзәк һәм кантон партия комитетлары яки сәяси агарту учреждениеләр тәкъдиме белән генә тикшеренүчеләргә бирү хакында карар кабул итә.

4 октябрь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында шагыйрь Кәрим Әмиринең (1893–1962) «Пролетар җырлар» китабына[1] бәяләмәсе тыңлана.

7 ноябрь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Октябрь һәм Ленин» дигән мәкаләсе бастырыла.

26 ноябрь. Диния нәзарәте тарафыннан «Ислам мәҗәлләсе» исемле журнал чыгарыла башлавы уңаеннан «Кызыл Татарстан» газетасында «Иннә әддин гаин вә илла эддине ислам» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 декабрь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Юк-бар провокацияне ташларга вакыт» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 декабрь. Совет партия-дәүләт эшлеклесе Шәһит Ходайбирдин (1896–1924) вафаты уңае белән «Кызыл Татарстан» газетасында «Шәһит иптәш Ходайбирдин» дигән мәкаләсе бастырыла.

Мәскәүдә «Казакъ кызы» (135 б.) романы; «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» (70 б.), «Пролетариат әдәбияты турында» (74 б.); Казанда «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре (1923–1911)» (143 б.) хезмәтләре аерым китап булып нәшер ителә.

«Октябрь яшьләре» журналының 3–4 нче кушма санында «1905 нче ел революциясендә татар яшьләре турында материаллар җыю» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 32–33).

«Яшь эшче» журналының 17 нче санында «Пролетариат әдәбияты» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 48–52).

Гыйльми үзәктә Ленин хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итү буенча төзелгән комиссиягә рәис итеп билгеләнә.

Татар театрлары өчен репертуар мәсьәләсе буенча төзелгән комиссия әгъзасы була.

«Артист Г. Кариев» дигән җыентыкта «Габдулла Кариев иптәш рухына» (б. 19–20); «Владимир Ильич хатирәсе» дигән китапта «Ленин һәм крестьяннар» (б. 85–96) дигән мәкаләләре урнаштырыла.

«Беренче баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфлары өчен гамәли тел сабаклары. Өченче китап. Гамәли сарыф-нәхү. Гыйльми мәркәз хозурындагы тел-әдәбият дәреслекләре хәзерләүче һәйәт тарафыннан төзелде. Икенче басма» (110 б.), «Беренче баскыч эш мәктәпләренең өченче уку

---

[1] Ул «Пролетариат моңнары» исеме белән 1926 елда нәшер ителә: Әмири К. Пролетариат моңнары / К. Әмири.– М.: «Нәшрият» кооперативы матбагасы, 1926.– 20 б.

еллары өчен гамәли тел сабаклары (икенче китап). Сарыф-нәхүгә хәзерлек өчен мәсьәләләр, тикшерү һәм күнегү өчен мисаллар, сөйләү һәм өслүб куәләрен арттыру өчен рәсемнәр, мәүзугълар, планнар. Тел-әдәбият дәреслекләре хәзерләүче һәйәт тарафыннан төзелде. Икенче басма» (95 б.), «Беренче баскыч мәктәпләрнең беренче һәм икенче уку еллары өчен гамәли тел сабаклары (1 нче китап). Дөрест язу кагыйдәләре, сарыф-нәхүгә хәзерлек өчен мәсьәләләр, тикшерү һәм күнегү өчен мисаллар, сөйләү һәм өслүб куәләрен арттыру өчен рәсемнәр, мәүзугълар, планнар (төзәтелгән, арттырылган икенче басма)» (74 б.) дигән дәреслекләрне төзүдә катнаша; аның редакциясендә «Троцкийның ленинизмга каршы көрәше» (152 б.) дигән мәкаләләр җыентыгы нәшер ителә. Анда «Җыючыдан» дигән кереш мәкаләсе бастырыла (б. 4–5).

**1925**

1 гыйнвар. РКП(б)ның Татарстан X өлкә конференциясенә тавыш бирү хокукы белән делегат итеп сайлана.

Гыйнвар. «Безнең юл» журналының 1 нче санында «1905 нче ел революциясе эчендә татарларның хәрәкәтләрен өйрәнү өчен материаллар җыю турында» (б. 30–34), «Китаплар арасында» (б. 46–50) дигән мәкаләләре бастырыла.

5 гыйнвар. ТССР эшче, крестьян һәм кызылармияче Советларының 5 нче съездына депутат итеп сайлана.

6 гыйнвар. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакция коллегиясе утырышында шагыйрь Һади Такташның (1901–1931) «Давылдан соң»[1] дигән шигырьләр җыентыгына бәяләмәсе тыңлана.

«Кызыл Татарстан» газетасында «Партиянең X өлкә конференциясендә өч момент» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 гыйнвар. Татарстан хөкүмәте карары белән Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе әгъзасы итеп билгеләнә.

11 гыйнвар. Татарстан Советларының V съезды уңаеннан «Кызыл Татарстан» газетасында «V съезд нәрсә әйтеп таралды?» дигән мәкаләсе бастырыла.

14 гыйнвар. ТССР эшче, крестьян һәм кызылармияче Советларының 5 нче съездында Татарстан Үзәк башкарма Комитетына әгъза итеп сайлана.

22 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Пугачев явы (1925. 23. I. 1775)» дигән мәкаләсе бастырыла.

30 гыйнвар. Татарстан хөкүмәте карары белән Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк рәисе итеп билгеләнә.

«Вестник научного общества Татароведения» журналының 1–2 кушма санында (б. 65–67) Г. Гобәйдуллинның «Новые произведения Галимджана Ибрагимова. Роман «Наши дни», первый том трилогии.– Казань: Издание Товарищество «Сабах», 1920.– 454 с.; рассказ «Люди».– Изда-

---

[1] Taqtaş H. Davьldan soŋ / H. Taqtaş.– Qazan: Tatar. matbugat nəşr. komb. basmasь, 1925.– 80 b.

ние комбината Издательства и Печати ТССР, Казань.– 54 с.; роман «Дочь степи».– Центр. Изд-во народов Востока СССР, Москва.– 135 с.» дигән бәяләмәсе бастырыла.

4 февраль. Гыйльми үзәк коллегиясе – Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе җыелышында Гыйльми үзәк янындагы татар һәм рус коллегияләренең рәисе итеп билгеләнә.

5 февраль. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында нәшриятның 1924/25 елга эш планына кайбер төзәтмәләр тәкъдим итә. «Кызыл Татарстан» газетасында әдәбият тәнкыйтьчесе Хәйретдин Вәлинең (1893–1969) «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән бәяләмәсе бастырыла.

10 февраль. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Селькредитпромсоюз музеен сатып алу кирәклеге хакында Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына Гыйльми үзәк тәкъдиме хакында хәбәр итә.

15 февраль. Дәүләт татар театрында К. Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән Гыйльми үзәк тарафыннан ясалган җыелышта «Каюм Насыйриның тарихи урыны» дигән темага доклад укый.

15 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында «Каюм бабаның йөз еллыгы» дигән мәкаләсе бастырыла.

19 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар интеллигенциясе турында берничә сүз» дигән мәкаләсе бастырыла.

24 февраль. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе утырышында катнаша.

25 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында «Нәриман иптәшнең 30 еллык хезмәт бәйрәме» дигән мәкаләсе бастырыла.

27 февраль. РКП(б)ның Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Иван Морозовка (1889–1957) һәм РКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире Миңлегәрәй Сәгыйдуллинга (1900–1937) Уфа Диния нәзарәте мөфтие Ризаэтдин Фәхретдинов (1859–1936) белән сөйләшү нәтиҗәләрен язып бирә.

Февраль. «Безнең юл» журналының 2 нче санында «Татарстан җөмһүриятенең X нчы конференциясе белән V съезды нәрсә бирделәр» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 76–79).

1 март. «Красная Татария» газетасында «Дедушка Каюм» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 март. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе утырышында катнаша; Татарны өйрәнү җәмгыяте секретарена тиешле хезмәт хакы түләүне оештыруны хәл итә.

Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Җүкәтау шәһәрчеге урынында табылган борынгы әйберләрне Татарстан финанс комиссариатыннан Татарстан Үзәк музеена тапшырылуы хакында хәбәре тыңлана.

8 март. «Кызыл Татарстан» газетасында З. Нуркин белән берлектәге «Әдипләргә, шагыйрьләргә мөрәҗәгать (Татар әдәбияты көтепханәсе турында кайбер материал кирәк)» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

13 март. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе утырышында катнаша; Гыйльми үзәкнең 1924 елның 1 мартыннан 1925 елның 1 мартына кадәрге эшчәнлеге хакында доклад укый.

16 март. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакция коллегиясе утырышында фикер алышуларда катнаша.

25 март. «Кызыл Татарстан» газетасында «Пролетариат каләмнәренә бездән сәлам!» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 март. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе утырышында катнаша; Гыйльми үзәкнең эш планы һәм мәсрафларын 1925/1926 уку елы Дәүләт бюджетына кертергә кирәклеге хакында доклад укый; тиешле хезмәт хакы түләү шарты белән педагог, тел галиме Мөхетдин Корбангалиевне (1873–1941) Гыйльми үзәккә татар теле буенча методист штатына урнаштыру мәсьәләсен хәл итә.

26 март. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында карт татар большевигы Сибгатулла Гафуровның (1888–1937) мемуарлары хакында хәбәре, ТАССРны төзүдә Ленинның роле турында истәлекләр туплап, рус һәм татар телләрендә бастырырга тәкъдиме тыңлана.

27 март. Эшче хәбәрчеләрнең 2 еллык бәйрәме җыелышында сөйләгән чыгышы «Кызыл Татарстан» газетасында «Мәгариф комиссариаты һәм татар журналистлары исеменнән Галимҗан иптәш Ибраһимов котлый» дигән мәкалә бастырыла.

Март. «Мәгариф» журналының 3 нче санында «Татарлар арасында халык мәгарифе системасы мәсьәләсе» дигән мәкаләсе (б. 73–74), З. Нуркин белән берлектәге «Әдипләргә, шагыйрьләргә мөрәҗәгать (Татар әдәбияты көтепханәсе турында кайбер материал кирәк)» (б. 120–121) дигән мөрәҗәгате бастырыла.

«Мәгариф» журналының 3 нче санында (б. 112–113) язучы, әдәбият галиме Г. Рәхимнең [Гали Рәхимнең; 1892–1943] «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Безнең юл» журналының 3 нче санында «Татар феодализм заманын өйрәнүгә материаллар (ярлык, хәзинә, Ибне Фазлан әсәре)» дигән мәкаләсе (б. 115–116), «Марксист язучыларыбызга! (Тарихи материализм буенча китаплар кирәк)» (б. 121–123), З. Нуркин белән берлектәге «Әдипләргә, шагыйрьләргә мөрәҗәгать (Татар әдәбияты көтепханәсе турында кайбер материал кирәк)» (б. 143) дигән мөрәҗәгатьләре бастырыла.

4 апрель. «Кызыл Татарстан» газетасында «Марксист язучыларыбызга!» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

9 апрель. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Ф. Сәйфи-Казанлының «Авыл хатлары»н эшче-крестьян китапханәсенең планына кер-

тергә тәкъдим итә; ТАССР төзелүнең 5 еллыгы уңае белән җыентык төзү йөкләнә.

18 апрель. РКП(б) әгъзаларының Бөтенрусия исәп алу анкетасын тутыра.

18 апрель. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе утырышында катнаша; Татарны өйрәнү фәнни җәмгыятенең рус телендә ике айлык Бюллетенен чыгару мәсьәләсен хәл итә.

«Безнең юл» журналының 4 нче санында «Нәриман ага вафат» (б. 146), «Нәриман Нәриманов (Кыскача биографиясе)» (б. 147–148) дигән мәкаләләре, «Марксист язучыларыбызга (Тарихи материализм буенча китаплар кирәк)» дигән мөрәҗәгате бастырыла.

4 май. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты президиумы утырышында катнаша; Үзәк курсларга Арча кантоныннан һәм Петропавловск шәһәреннән мәгариф хезмәткәрләрен укырга китертү мәсьәләсен күтәрә.

5 май. «Кызыл Татарстан» газетасында «Кызыл каләм бәйрәменә» дигән мәкаләсе бастырыла.

7 май. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакция коллегиясе утырышында «Ялгыз» һәм «Үксез» пьесаларына Кәрим Тинчурин белән берлектәге бәяләмә тыңлана.

12 май. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты президиумы утырышында катнаша; Гыйльми үзәк каршында туган төбәкне өйрәнү өчен аппараты белән Татар Бюросы оештыру мәсьәләсен күтәрә.

14 май. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакция коллегиясе утырышында Татар китапханәсен тулыландырырга тәкъдим итә.

16 май. Казаннан Уфага М. Гафурига үз кулы белән биографиясен язып җибәрүен үтенеп хат яза.

21 май. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакция коллегиясе утырышында татар мәдәнияте инвалидларын кайгырту хакында тәкъдим белән чыга.

Май ае. Гыйльми үзәк каршында оештырылган туган төбәкне өйрәнү Бюросын җитәкли (1928 елның җәендә Бюро Татарстанны өйрәнү җәмгыятенә үзгәртелә, 1930 елда аның функцияләре яңа ачылган Татар икътисади фәнни-тикшеренү институтына тапшырыла).

«Безнең юл» журналының 5 нче санында «Гамәли һәм нәзари әдәбият дәресләре. Үзбәкстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты басмасы. Г. Сәгъди әсәре. 200 б.)» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 210).

18 июнь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Г. Сәгъдинең «Кешелек дөньясында тел, әдәбият һәм язмачылык һәм аларның тарихи үсеше» хезмәтенә бәяләмәсе тыңлана.

25 июнь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Мәдәни хезмәтләрдә бишьеллык тәҗрибә» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Мәгариф» журналының 6–7 нче кушма санында «Бу биш ел татар мәдәниятенә нәрсә бирде» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 3–26).

3 июль. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» хезмәтенә бәяләмәсе тыңлана.

Көз көне СССР Фәннәр академиясенең 200 еллык юбилее уңае белән Мәскәүдә һәм Ленинградта үткәрелгән юбилей җыелышларында катнаша.

1 сентябрь. М. Гафуриның шигырьләр җыентыгын бастыру мәсьәләсе хакында Татарстан нәшрият комбинатына хат яза.

15 сентябрь. Муромнан Мәскәүгә профессор И. Н. Бороздинга хат яза.

23 сентябрь. «Кызыл Татарстан» газетасында, «Мәгариф» журналының 9 нчы санында (б. 78–83) «Академия бәйрәменнән кайткач» дигән мәкаләсе бастырыла.

2 октябрь. Казаннан Мәскәүгә академик В. В. Бартольдка (1869–1930) хат яза.

Сентябрь-октябрь. «Безнең юл» журналының 9–10 нчы кушма санында «1905 нче ел революциясе турында» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 6–9).

21 октябрь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татарстан җөмһүриятенең нәшрият планы турында» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 декабрь. Тел галиме М. Корбангалиевнең юбилее уңаеннан «Кызыл Татарстан» газетасында «Мәдәни хезмәт юлында 30 ел» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 декабрь. РКП(б)ның Татарстан Өлкә комитетына Ш. Әхмәдиев хакында уңай характеристика яза.

20 декабрь. «Кызыл Татарстан» газетасында «1905 ел революциясендә татар пролетариатының эшләү методлары» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Карт ялчы» (24 б.) хикәясенең өченче басмасы, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Беренче бүлек (1905)» (235 б.), «Татары в революции 1905 года» (259 с.) дигән хезмәтләре нәшер ителә.

Профессор Н. И. Воробьёв (1894–1967) белән берлектә «Материалы по изучению Татарстана (Сборник статей). Вып. II» дигән җыентык төзеп бастыралар (275 с.).

«Беренче баскыч мәктәпләрнең соңгы сыйныфлары өчен гамәли тел сабаклары. Өченче китап. Гамәли сарыф-нәхү. Гыйльми мәркәз хозурындагы тел-әдәбият дәреслекләре хәзерләүче һәйәт тарафыннан төзелде. Өченче басма» (99 б.) дигән дәреслекне төзүдә катнаша.

«Биш ел эчендә» дигән китапта «Бу биш ел татар мәдәниятенә нәрсә бирде?» (б. 107–140), «Татарстан Җөмһүрияте төзелү тарихына материаллар» (б. 229–240), «Кызыл юл. Дүртенче китап»та «Бөек тарихи көн» (б. 129–132), «Ленин үлде. Олуг матәм» (б. 199–209), К. Нәҗми төзегән «Кызыл Армия сафында татар-башкортлар. Тарихи, әдәби рәсемле альбом»да «Пролетариат кылычы (Эшче-крестьян Кызыл Ордасының дүрт еллык бәйрәме)» (б. 14–15), «Дошманнар арасында дүрт ай (Хисап докладымның кыскасы)» (б. 88–93), «Утыз еллык хезмәт. 1895–1925

(Мөхетдин абзый Корбангалиевнең мәдәни-иҗтимагый хезмәтенә утыз ел тулу уңае белән)»дә «Мәдәни хезмәт юлында утыз ел (1895–1925)» (б. 4–7), «За 5 лет. К V годовщине провозглашения Татарской Советской Социалистической Республики»да «Материалы по истории организации Татреспублики» (с. 202–208) дигән мәкаләләре бастырыла.

**1926**

9 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар эшче большевигының истәлекләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

12 гыйнвар. Язучы, публицист Гафур Коләхмәтовның (1881–1918) пьесалары басылып чыгу уңаеннан «Кызыл Татарстан» газетасында «Беренче марксистик әдипнең мәҗмугасы» исемле мәкаләсе бастырыла.

18 гыйнвар. Казаннан Мәскәүгә профессор И. Н. Бороздинга хат яза.

«Безнең юл» журналының 1–2 нче кушма санында Беренче тюркология съезды» (б. 1–2), 3 нче санында «Беренче тюркология съезды нәрсә бирде?» (б. 1–3), 5–6 кушма санында (б. 1–3) дигән мәкаләләре бастырыла.

23 гыйнвар. Гыйльми үзәк хезмәткәрләренә билет җибәрүләрен үтенеп театр юбилеен уздыру комиссиясенә хат яза.

25 гыйнвар. Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлануы хакында үзенә һәм ТАССР Мәгариф халык комиссариатына хәбәр итә.

28 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында З. Нуркин белән берлектә «Тел һәм атамалар турысында инструкция (Бу инструкция Гыйльми үзәк президиумының 1925 нче ел 6 нчы ноябрьдә булган утырышында кабул ителде)» дигән мәкаләсе бастырыла.

15 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында «Каюм бабаның йөз еллыгы» исемле мәкаләсе бастырыла.

27 февраль – 6 март. Бакуда үткәрелгән I Тюркология съездында катнаша.

1 март. Бакуда үткәрелгән I Тюркология съездында «Төрки телләрнең имлясы» дигән доклад укый.

3 март. I Тюркология съездында ясаган «Төрек телләренең имлясы» дигән чыгышы «Кызыл Татарстан» газетасында «Галимҗан Ибраһимов доклады» исеме белән бастырыла.

20, 21, 24 март. «Кызыл Татарстан» газетасында «Тюркология съездында тикшерелеп үтелгән мәсьәләләр. I. Реформамы, революцияме?; II. Төрек халыклары арасында әдәби-мәдәни федерация нигезләре; III. Гомуми нәтиҗәләр, алдагы бурычлар» дигән мәкаләләре бастырыла.

26 март. Гәжур мөдире Сәлах Атнагуловка (1893–1937) Һ. Такташны Гыйльми үзәккә ике ай ярымга командировкага җибәреп торуны сорап хат яза.

28 март. «Кызыл Татарстан» газетасында язучы Шәриф Камалның (1884–1942) «Гарәп хәрефеме, латин хәрефеме? «100%» дигән мәкаләсе бастырыла.

31 март. «Кызыл Татарстан» газетасында «Гарәп хәрефләре һәм аларны реформалау мәсьәләсе» дигән мәкаләсе бастырыла.

6 апрель. Башкортстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәккә терминология буенча материаллар җибәрүне сорап хат яза.

8 апрель. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты янындагы Гыйльми үзәк Татар редакцион коллегиясе утырышында Бакуда үткәрелгән I Тюркология съезды карарларын гамәлгә ашыру хакында доклады тыңлана.

9 апрель. ТАССР Мәгариф халык комиссариаты президиумы утырышында катнаша; Бакуда үткәрелгән I Тюркология съезды карарларын гамәлгә ашыру буенча эшләр хакында доклад укый.

18 апрель. «Урал» газетасы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында «Беренче большевик татар гәзитен тергезергә кирәк», К. Нәҗминең «Кызыл Татарстан» газетасының 11 апрель санындагы «Үпкәләштән булмасын, чыннан әйтик» мәкаләсенә карата «Татарстан» газетасында «Кави Нәҗми иптәш мәкаләсе турында (Редакциягә хат)» дигән мәкаләләре бастырыла.

22 апрель. «Кызыл Татарстан» газетасында «Яңа батырлар, муллалар, миссионерлар, диннәр, техникалар» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 май. «Кызыл Татарстан» газетасында «Правда», 1912–5/V-1926» дигән мәкаләсе бастырыла.

Казаннан Мәскәүгә профессор И. Н. Бороздинга хат яза.

30 май. Яңалифкә күчү мәсьәләсе хакында «Кызыл Татарстан» газетасында «Банкротлар (Метод мәсьәләсе. Ахыргы сүз)» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 август. Гыйльми үзәк йөкләмәсе белән эшче-крестьян районнарында командировкасы хакында хисап бирүне сорап Һ. Такташка хат яза.

26 август. «Кызыл Татарстан» газетасында «Казанда татар мәдәнияте йорты ачарга кирәк!» дигән мәкаләсе бастырыла.

8 сентябрь. «Татардан гыйльми, мәдәни көчләр җитештерү мәсьәләсе (Партиянең Татарстан Өлкә комитетында кабул кылынган соңгы карарлар уңае белән)» дигән мәкаләсе бастырыла.

10 сентябрь. Башкортстанда «Безнең юл» журналын тарату мәсьәләсен хәл итүне сорап Башкортстан Мәгариф халык комиссариатының баш сәяси агарту оешмасына хат яза.

10 сентябрь. Башкортстанда «Безнең юл» журналын тарату мәсьәләсен хәл итүне сорап Башкортстан Мәгариф халык комиссариаты хезмәткәре Габдулла Гыйсмәтигә (1883–1938) хат яза.

5 ноябрь. Аның катнашлыгында Гыйльми үзәк президиумы тел һәм атамалар хакында инструкция кабул итә.

5 ноябрь. Уллары Рөстәм туа.

Ноябрь. Аның катнашлыгында Гыйльми үзәк татар әлифбасы хакында карар һәм Татарстан нәшриятының 1925/26 елга эш планын кабул итә.

Рәссам П. П. Беньков (1872–1949) тарафыннан портреты язылa.

«Безнең юл» журналының 5–6 нчы кушма санында «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында)» дигән мәкаләсе бастырыла.

«Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре» дигән җыентыкта «Башлангыч (2)» (б. 3–5), «Каюм бабаның йөз еллыгы» (б. 113–119); М. Парсин, Мохтар Мутин (1885–1941), Зәки Баязидский (1889–1959) төзегән «Татар театры. 1906–1926» дигән җыентыкта «20 еллык көрәш бәйрәме» (б. 5–7), «Татар театрының 20 еллыгы турында Галимҗан Ибраһимов иптәш доклады» (б. 249–250); Г. Рәхим тарафыннан төзелгән «Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре» дигән китапта «Революцияме, реформамы?» (б. 43–49), «Төрек халыклары арасында әдәби-мәдәни федерация нигезләре» (б. 49–54), «Гомуми нәтиҗәләр, алдагы бурычлар» (б. 54–61), «Гарәп хәрефләре» (б. 61–69), «Муллалар, миссионерлар, диннәр, техникалар» (б. 69–80), «Банкротлар» (б. 81–93) дигән кереш сүз һәм мәкаләләре бастырыла.

Гыйльми үзәктә тел комиссиясе составына кертелә; К. Насыйри мәҗмугасын төзү эше йөкләнә.

Сухумда Гульрипш шифаханәсендә дәвалана.

**1927**

8 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында Зыя Насыйров (?–?) белән берлектә «Беренче татар большевик газеты «Урал»ның 20 еллык бәйрәме турында. 1907–17/I-1927. Тезислар» дигән мәкаләсе бастырыла.

14 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Урал» бәйрәменнән гыйльми яктан файдалану» дигән мәкаләсе бастырыла.

16 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Урал» һәм заманы» дигән мәкаләсе бастырыла.

19 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Урал»ның 20 еллык бәйрәме. Иптәш Галимҗан Ибраһимов сүзе» дигән мәкалә бастырыла.

26 гыйнвар. Бөтенсоюз мәгариф хезмәткәрләренең Татарстан Өлкә бүлеге тарафыннан аның төп категория буенча фәнни хезмәткәрләр секциясендә торуы хакында белешмә бирелә.

30 гыйнвар. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар әдәбияты җәмгыяте» дигән мәкаләсе бастырыла.

9 февраль. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты матбугат бүлеге коллегиясе утырышында татар язучыларының ассоциациясен төзү кирәклеге хакында чыгыш ясый. Бу мәсьәлә буенча комиссия оештыру аңа йөкләнә.

12 февраль. «Красная Татария» газетасында «Ассоциация татарских литераторов.– Галимджан Ибрагимов» дигән мәкалә бастырыла.

16 февраль. «Красная Татария» газетасында «К 20-летию первой татарской большевистской газеты «Урал» (1907–1926)» дигән мәкаләсе бастырыла.

24 февраль. Казанда яз көне үткәреләчәк татар теле һәм әдәбияты укытучыларының киңәшмәсенә вәкилләр җибәрүне сорап Башкортстан Гыйльми үзәгенә язылган хатка ул да имза куя.

17 март. Татарстан Советларының VII съездында катнаша, шунда хәле кинәт начарлана һәм Университет клиникасына салалар.

«Яңа авыл» газетасында Г. Касыймовның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? (Г. Ибраһимов, 27 ел, 19 февраль, Казан)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

18 март. Профессорлар М. Н. Чебоксаров (1878–1932), Р. А. Лурия (1874–1944), Ә. Б. Терегулов (1885–1966), доктор С. Б. Еналиевлардан (1894–1938) гыйбарәт беренче консилиум була.

22, 24, 25, 26, 27 март. Сәламәтлеге торышы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында хәбәр бастырыла.

2 апрель. РСФСР Мәгариф халык комиссариаты аны чит илгә 3 айга командировкага җибәрү хакында карар чыгара.

5 апрель. Профессор М. Н. Чебоксаров аның сәламәтлеге торышы хакында нәтиҗә чыгара.

27 апрель. Севастопольгә килеп җитәләр. Аннан китеп, кич белән Ялтага килеп, «Ялта» мосафирханәсендә тукталалар.

29 яки 30 апрель. Ялтада Халтурин урамындагы 5 санлы йортта икенче каттагы верандалы ике бүлмәгә күченәләр.

19 май. РСФСР Мәгариф халык комиссариаты аны 3 айга Төркиягә командировкага җибәрү хакында карар чыгара.

Август. Журналист Бәкер Гомәров (Бекир Умеров), мәктәп директоры Мәмут Баясанов хәл белергә килә.

17 сентябрь. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты аның 1925 елның 7 гыйнварыннан 1927 елның 17 мартына кадәр Мәгариф халык комиссариатында Коллегия әгъзасы һәм Академик үзәк рәисе булганлыгы, озак вакытка курортка дәваланырга китүе сәбәпле, эшеннән азат ителүе хакында таныклык бирә.

17 сентябрь. Татар коммунистик университеты аның бу уку йортында ачылган вакыттан башлап 1925 елга кадәр татар әдәбияты һәм ВКП(б) тарихы укытуы хакында таныклык бирә.

18 сентябрь. Персональ пенсия билгеләү һәм аны ай саен бирү, 1 апрельдән күләмен 120 сумга җиткерү хакындагы ТАССР Үзәк Башкарма Комитетының РСФСР Халык комиссарлары Советы янындагы Социаль-тәэминат комиссариатының персональ пенсия билгеләү комиссиясенә җибәрелә.

10/23 сентябрь. Татарстан Үзәк Комитеты, Татарстан Халык Советлары комиссариаты рәисләре, Татарстан Халык Советлары комиссариаты җаваплы секретаре имзалаган характеристикасы Бөтенроссия Үзәк башкарма Комитетына, РСФСР Халык комиссарлары Советына, Татарстан вәкиллегенә җибәрелә.

12 октябарь. ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты персональ пенсия билгеләү тәкъдимен Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты РСФСР Халык комиссарлары Советы янындагы Социаль-тәэминат комиссариатының персональ пенсия билгеләү комиссиясенә җибәрә.

7 ноябрь. «Кызылармеец» газетасының Октябрь 10 еллыгы номерына өстәп чыгарылган «Октябрь» әдәби җыентыгында «Бәрелешүдән соң» дигән әсәре бастырыла (б. 3).

22 ноябрь. 20 еллык хезмәт бәйрәмен үткәрү мәсьәләсе кузгалу уңае белән Гыйльми үзәк җитәкчесе Мөхәммәт Таһировка (1895–1929) Ялтадан хат яза.

28 декабрь. «Татар педагогия җәмгыяте» үзенең утырышында аны мактаулы әгъза итеп кабул итү һәм җәмгыять янында оештырыла торган тел-әдәбият кабинетына аның исемен бирергә дигән карар чыгара.

Нәшер ителгән китапларының исемлеге «Безнең юл» журналының 12 нче санында бастырыла.

«Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре (1924–1911)» (144 б.), «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (40 б), «Урал» һәм «уралчылар» («Урал» гәзитәсенең 20 еллык бәйрәмен үткәрү комиссиясе карамагында басыла)» (44 б.) хезмәтләре нәшер ителә.

**1928**

4 гыйнвар. Ялта медицина экспертизасы бюросы аның сәламәтлеге хакында нәтиҗә чыгара.

4 гыйнвар. Гаилә составы хакында Ялта шәһәре 375 санлы торак-кооператив ширкәтеннән акт алына; инвалидлыгын билгеләү өчен акт төзелә.

4 гыйнвар. «Безнең юл» журналының 1 нче, «Мәгариф» журналының 2 нче саннарында коллектив тарафыннан төзелгән «Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык)» дигән мәҗмуга нәшер ителүе хакында белдерү бастырыла.

13 гыйнвар. Дәүләт нәфис сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана.

16 гыйнвар. Татарстан Халык комиссариаты секретариаты Мәскәүдәге республика вәкиллегеннән җибәрелгән документлар нигезендә персональ пенсия билгеләү мәсьәләсен тизләтүне сорый.

18 гыйнвар. Үзенең хәлен аңлатып М. Гафурига Ялтадан хат яза.

21 гыйнвар. 1 февральдән 180 сум күләмендә персональ пенсия билгеләү тәкъдимен РСФСР Халык комиссарлары Советы янындагы Социаль-тәэминат комиссариатының персональ пенсия билгеләү комиссиясе утырышында җиткерү хакында ТАССРның Мәскәүдәге вәкиле ТАССР Үзәк Башкарма Комитетына хәбәр итә.

22 гыйнвар. «Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык)» дигән мәҗмуга нәшер ителәчәге хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

29 гыйнвар. Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы булып сайлануы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

10, 15 февраль. «Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык)» дигән мәҗмуга нәшер ителгәне хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

20 февраль. Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлануы уңае белән әлеге оешмага рәхмәт белдереп һәм үзенең хәлен аңлатып хат яза.

25 февраль. XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәме уңаеннан Мәскәүдә Коммунистик академия бинасында тантаналы кичә үткәрелә.

26 февраль. XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәме уңаеннан Мәскәү татар эшчеләр клубында җыелыш була.

«Азат хатын» журналының 2 нче санында «Татар хатынының тарихи үсүе» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 6–7).

26 февраль. Үзенең матди хәлен аңлатып М. Таһировка Ялтадан хат яза.

2 март. XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәме уңаеннан 25 февральдә Мәскәүдә Коммунистик академия бинасында һәм татар эшчеләр клубында җыелышлар булуы хакында «Коммунист» газетасында белдерү бастырыла.

9 март. «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән китабы нәшер ителү хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

10 март. Иҗат эшчәнлегенә 20 ел тулу уңаеннан Казанда Татар дәүләт театрында тантаналы зур кичә уздырыла.

Ташкентта Ташокруг партия комитеты янындагы татар-башкорт комсекциясе тарафыннан 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәме үткәрелә. «Матбугат» сәнәгать кооперация типографиясендә яшь вакытында ак эшләпә, плащ-накидка киеп төшкән фотосы открыткада 1500 тираж белән күбәйтелә.

Казанда әдәбият тарихчысы, тәнкыйтьче П. С. Коган (1872–1932), шәркыятьче-тюрколог А. Н. Самойлович (1880–1938), тарихчы Н. Н. Фирсов (1864–1934), И. Н. Бороздин һәм Г. Сәгъди мәкаләләре тупланган «Галимджан Ибрагимов: Статьи» (50 с.); Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан (1899–1937), Галимҗан Нигъмәти (1897–1941) редакциясендә «Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык)» (196 б.); Ташкентта Нәҗип Җәләлов, Зыя Гыймадиев, Хәйрулла Габидовлар редакциясендә «Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт туена каратылып чыгарылган мәҗмуга)» (36 б.) дигән җыентыклар нәшер ителә.

«Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык)» дигән мәҗмуга, зурайтылган рәсеме, «Безнең көннәр» романы, «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак», «Пролетариат әдәбияты мәсьәләләре», «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» исемле хезмәтләре, «Карт ялчы»,

«Алмачуар», «Диңгездә» хикәяләренә заказлар кабул ителүе хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

16 март. Уфада Башкорт дәүләт театры «Яңа кешеләр» пьесасын сәхнәгә куя.

20 еллык хезмәт бәйрәме Уфада Хезмәт сараенда уздырыла.

17 март. 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәме белән котлаулары өчен «Башҡортостан» газетасы редакциясенә язган хаты бастырыла.

30 март. ТАССР профсозлар Советы аңа Хезмәт Батыры дигән исем бирү тәкъдиме белән чыга.

8 апрель. 20 еллык юбилее уңае белән Татар мәдәнияте йортында тәбрикләр күргәзмәсе хакында «Татарстан» газетасында хәбәр бастырыла.

17 апрель. 20 еллык юбилеен үткәрү уңае белән һәм хәлен белешергә Гыйльми үзәк рәисе Хәмзә Таһировны (1895–1929) җибәргәннәре өчен Татарстан Мәгариф халык комиссариатына Ялтадан хат яза һәм ул «Безнең юл» журналының 5 нче санында бастырыла (б. 29).

13 май. Гыйльми үзәк рәисе Х. Таһировның Ялтада аның янында булып кайтуы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында «Кырым истәлекләре» дигән мәкаләсе бастырыла.

Х. Таһировның Ялтада аның янында булып кайтуы хакында «Безнең юл» журналының 5 нче санында хәбәр бастырыла (б. 29).

«Безнең юл» журналының 5 нче санында «Яңалиф турында Галимҗан Ибраһимов» дигән мәкалә бастырыла (б. 30).

13 август. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумы Хезмәт Батыры исеме бирергә карар кабул итә.

16 август. Хезмәт Батыры исеме бирелүе хакында «Красная Татария» газетасында белдерү бастырыла.

4 ноябрь. Инвалидлык билгеләнә.

20 декабрь. Ялта хирургия хастаханәсе аның сәламәтлеге хакында белешмә бирә.

Көнчыгышны өйрәнү буенча Бөтенроссия гыйльми ассоциациясенең әгъза-учредителе була.

«Тирән тамырлар (Тугры сүз)» романы аерым китап булып нәшер ителә (китапта: хикәя).

«Советская страна. Литературно-художественный и публицистический альманах народов СССР»да «Табигать балалары» хикәясе Солтангалиев тәрҗемәсендә рус телендә «Табиат балалары» исеме белән бастырыла (с. 29–37).

**1929**

«Белем» журналының 2 нче санында (б. 87–98) Касыйм Гыйрфановның «Тирән тамырлар» (Г. Ибраһимовның яңа әсәре)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Сәсән» журналының 5–6 нчы кушма санында Ш. Бабич турында «Ваҡытһыҙ һәләк булды» дигән мәкаләсе бастырыла.

17 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында К. Казыйның «Тирән тамырлар» (Гомәр Галиев докладына уңае белән)» дигән бәяләмәсе бастырыла.

24 февраль. «Кызыл Татарстан» газетасында А. Федотовның «Тирән тамырлар» дигән бәяләмәсе бастырыла.

23 март. «Азат Себер» газетасында С. И. имзалы авторның «Тирән тамырлар» дигән бәяләмәсе бастырыла.

2 сентябрь. Дәвалану өчен түләүне дәвам иттерү өчен ТССР Мәгариф халык комиссариатына ТССР хөкүмәтенә мөрәҗәгать белән чыгуларын сорап гариза яза.

Сентябрь. Хәлен белергә әдәбият һәм сәнгать әһелләре Демьян Фәтхи (Касыйм Фәтхетдин улы Фәтхетдинов, 1906–1943), Мирсәй (Мирсәяф) Мәсәлим улы Әмир (Әмиров, 1907–1980), Һади (Мөхәммәтһади) Хәйрулла улы Такташ (Такташев, 1901–1931), Газиз (Габделгазиз) Сәлах улы Иделле (Усманов, 1905–1985), Кави (Габделкави) Һибәт улы Нәҗми (Нәҗметдинов, 1901–1957), Кәрим Гали улы Тинчурин (1887–1938), Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәти (Нигъмәтуллин, 1897–1941), Мәҗит (Габделмәҗит) Нургани улы Гафури (Гафуров, 1880–1934), Сәрвәр Сабир кызы Әдһәмова (1901–1979), Шәриф Камалетдин улы Камал (Байгильдиев, 1884–1942), Гомәр Билал улы Галиев (1900–1954), Гадел (Гаделша) Нурмөхәммәт улы Кутуй (Кутуев, 1903–1945), Закир Халит улы Гали (Галиев, 1902–1941), Лазарь Рубинштейн, Салих Җәмалетдин улы Сәйдәшев (1900–1954), Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев (1895–1969), Мөхәммәт Вәли улы Гали (Галиев, 1893–1952), Сәйфи (Сәйфетдин) Фәттах улы Кудаш (Кудашев, 1894–1993), Шакир Әбделгани улы Шамильский (Вахитов, 1892–1945), Гариф Мортаза улы Гомәр (Гомәров, 1891–1974) килә, күмәк фотога төшәләр.

Казанда «Яңалиф» басмасында «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең 2 нче томы нәшер ителә (474 б.).

Әдәбият һәм театр тәнкыйтьчесе, журналист М. Парсин тарафыннан төзелеп нәшер ителгән «Быргы тавышлары. Авыл хуҗалыгы-урман эшчеләре өчен хикәя һәм шигырьләр җыентыгы» дигән китапта «Карт ялчы» хикәясеннән өземтәләр бастырыла (б. 5–12).

«Безнең юл» журналының 11 нче санында язучы, әдәбият галиме Г. Толымбайскийның [Гомәр Толымбай (Толымбайскийның); 1900–1938] «Искермәгән бер уңлык турында» дигән бәяләмәсе бастырыла.

«Яңалиф» журналының 12 нче санында (б. 14–16) Салах Җамалиевның «Тирән тамырлар». Г. Ибраһимов әсәре» дигән бәяләмәсе бастырыла.

**1930**

25 апрель. Педагог Шәһәретдин Шәрәфнең (1879–1938) «Коммуна» газетасында бастырылган «Җил тимәгән әдәбият утравында» дигән мәкаләсендә Г. Ибраһимов та тәнкыйтьләнә.

«Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (Казан, 1927) дигән китабына һәм яңалифкә булган мөнәсәбәтенә карашларга аңлатма хаты «Безнең юл» журналының 3–4 нче кушма санында бастырыла (б. 53).

27 май. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат һәм «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты (1920–1930)» альманахы өчен «Ерактан сәлам» дигән мәкалә яза һәм ул бастырыла (б. 97–104).

9 июнь. Казанга К. Нәҗмигә һәм Сәрвәр Әдһәмовага (1901–1979) риванол сорап Ялтадан хат яза.

27 июнь. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татарстан җөмһүрияте нинди каршылыклар эчендә туды һәм беренче ун елда нинди каршылыкларга очрады? (Тарихи сызык)» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 июль. Казанга К. Нәҗмигә һәм С. Әдһәмовага Ялтадан хат яза.

23 июль. Татарстанның 10 еллык юбилее уңае белән Казанга Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Харис Моратхуҗинга (1895–1955) Ялтадан тәбрик хаты яза.

27 июль. «Кызыл Татарстан» газетасында «Татар җөмһүрияте нинди каршылыклар эчендә туды һәм беренче 10 елда нинди каршылыкларга очрады» дигән мәкаләсе бастырыла.

5 ноябрь. «Коммуна» газетасында «Бөек Октябрьнең беренче елларында» дигән мәкаләсе бастырыла.

13 август. «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты (1920–1930)» альманахын алуын хәбәр итеп һәм кунакка чакырып К. Нәҗмигә хат яза.

21 декабрь. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

Казанда «Яңалиф» басмасында «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең 6 нчы томы нәшер ителә (116 б.).

«Альманах художественной литературы тюркских народов СССР»-да «Казакъ кызы» романының зур булмаган бер өлеше Гайшә Шәрипова (1901–1969) тәрҗемәсендә «Утро в степи» исеме белән бастырыла (с. 16–18).

«Табигать балалары» хикәясе үзбәк теленә тәрҗемә итеп бастырыла («Təbiət balalarь»).

**1931**

23 гыйнвар. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

«Атака» журналының 1 нче санында «Г. Коләхмәтов большевиклар белән эшләде» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 13).

17 февраль. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

21 март. Улы Рөстәм йөрәк параличыннан вафат була.

22 март. «Кызыл Татарстан» газетасында «Революция тарихына материаллар җыю һәм тикшерү турында» дигән мәкаләсе бастырыла.

23 март. Мәрхүм улы Рөстәм Ялтада дәфен кылына.

4 май. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

4 май. Кайгыларын уртаклашканнары өчен Казанга С. Әдһәмовага Ялтадан хат яза һәм Рөстәмнең дәфен кылыначак көнне алдырылган фотосын җибәрә.

5 апрель. Үзләренең хәлен аңлатып Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

5 ноябрь. Сухумига дәваланырга килгән М. Гафурига Ялтадан хат яза.

Казанда «Яңалиф» басмасында «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең 5 нче томы нәшер ителә (198 б.).

«Табигать балалары» һәм «Карт ялчы» хикәяләре П. Радимов редакциясендә, П. Коганның сүзбашы белән нәшер ителгән «Сборник татарской литературы (Дореволюционный)» дигән җыентыкта «Дети природы» (с. 78–92), «Старый батрак» (с. 92–107) исеме белән бастырыла.

«Атака» журналының 3 нче санында «Әдәби програм турында» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 65–68).

«Яңалиф» журналының 5/6 нчы кушма санында язучы Гафур Коләхмәтовка (1881–1918) багышланган «Әдәби тарихыбызның кадерле битләре болай таптатылмасын иде» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 96–103).

**1932**

1 февраль. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

4 февраль. Мәскәүгә Гайшә Шәриповага (1901–1969) Ялтадан хат яза.

19 февраль. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

М. Гафуриның җыентыгы басылып чыгу уңаеннан «Совет әдәбияты» журналының 2–3 нче кушма санында «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» дигән мәкаләсе бастырыла.

21 апрель. Якуб Мусаннифка Ялтадан хат яза һәм ул «Большевик ёлы» журналының 6–7 нче кушма санында бастырыла (б. 41).

31 июль. Казанга К. Нәҗми һәм С. Әдһәмовага Ялтадан хат яза.

19 август. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

24–31 август. Туганнан туган кардәше Габделхак Газизҗан улы Ибраһимов (1905–1960) (Газизҗан белән Гыйрфан бертуганнар) Ялтада аның янында була.

Икенче хатыны Ө. Мөхәммәдова ташлап китә.

5 октябрь. Ташкентка туганы Мохтар Ибраһимовка Ялтадан хат яза.

6 октябрь. Татарстан колхозчы ударникларның 2 нче съездында ясаган чыгышы «Кызыл Татарстан» газетасында «Татарстанның йөзе үзгәрде. Галимҗан Ибраһимов рече» исеме белән бастырыла.

11 октябрь. Ялтада Тубинститутта дәваланучы М. Гафурига хат яза.

22 октябрь. Башкортстан педагогия институтының тел-әдәбият бүлеге 3 нче курс студентлары Афзал Кудашевка (1912–1981), Зәйнәп Зөбәировага (1905–1980), Зәкиҗан Локмановка (1912–1959) үзләрен кызыксындырган сорауларына Ялтадан җавап хаты яза һәм ул «Әдәбият мәсьәләләре» исеме белән «Коммуна» газетасында бастырыла.

5 ноябрь. «Коммуна» газетасында «Бөек Октябрьнең беренче елларында (Үтелгән бер баскыч турында материал җыю эше)» дигән мәкаләсе бастырыла.

11 ноябрь. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Президиумының карары белән Хезмәт Батыры дигән исем бирелә.

25 ноябрь. Уфага Мөхәммәт Бикбулатовка (1899–1961) Ялтадан хат яза.

11 декабрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

19 декабрь. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

26 декабрь. Уфага М. Бикбулатовка Ялтадан хат яза.

28 декабрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

«Кызыл чәчәкләр» повесте М. Роикъ тәрҗемәсендә үзбәк телендә нәшер ителә («Qьzьl cecəklər hikəjəse (Biz pastadan kutarildik)», 106 b.).

**1933**

4 февраль. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

10 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

21 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

29 февраль. Ташкентка туганы М. Ибраһимовка Ялтадан хат яза.

М. Гафуриның «Сайланма әсәрләр»е (Казан, 1932) нәшер ителү уңае белән «Яңалиф» журналының 2–3 нче кушма санында «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 116–117).

3 апрель. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

7 апрель. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

5 апрель. «Литературная газета»да «Тирән тамырлар» романыннан өзек «Черное и красное» дигән исем белән бастырыла.

14 апрель. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

15 апрель. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

10 май. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

29 сентябрь. Ударник колхозчыларының икенче Бөтентатарстан съездына кайтышлый Мәскәүдә туктала, язучылар белән очраша. Кич белән поездда Казанга китә.

30 сентябрь. Ударник колхозчыларының икенче Бөтентатарстан съездына кайтышлый 29 сентябрьдә Мәскәүдә тукталуы, язучылар белән очрашуы һәм кич белән поездда Казанга китүе хакында «Коммунист» газетасында белдерү бастырыла.

31 сентябрь. Ударник колхозчыларының икенче Бөтентатарстан съездында катнаша.

1 октябрь. Кичке утырышта чыгыш ясый.

2 октябрь. Ударник колхозчыларының икенче Бөтентатарстан съездына кайтышлый 29 сентябрьдә Мәскәүдән Казанга китүе хакында «Коммунист» газетасында белдерү бастырыла.

3 октябрь. Ударник колхозчыларының икенче Бөтентатарстан съездына кайтышлый 29 сентябрьдә Мәскәүдә тукталуы, «Коммунист» газетасы редакциясендә язучылар һәм журналистлар белән очрашуы редакциясендә язучылар һәм журналистлар белән очрашуы хакында «Коммунист» газетасында белдерү бастырыла.

22 октябрь. «Коммуна» газетасында «Кайбер әдәби мәсьәләләр (Башкыртстан педагогия институты 3 нче курсы тел-әдәбият бүлеге студентлары исеменнән Локманов, Зөбәерова һәм Әфзал Кудашовлар тарафыннан язылган хатка җавап)» дигән мәкаләсе бастырыла.

25 октябрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

8 ноябрь. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

4 декабрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

17 декабрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

Казанда Татгосиздатта «Сайланма әсәрләре»нең беренче китабы нәшер ителә (274 б.).

«Тирән тамырлар» романы М. Роикъ тәрҗемәсендә үзбәк телендә нәшер ителә («Teran tomirlar», 204 b.).

**1934**

1 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

28 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

8 апрель. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

27 апрель. «Кызыл Татарстан» газетасында Татарстан Совет язучылары Союзын оештыру комитетына телеграммасы бастырыла.

«Совет әдәбияты» журналының 5 нче санында «Безнең көннәр» романы турында язучыдан (Сүз ахыры урынында)» дигән мәкалә бастырыла.

24 май. Уфага М. Гафуриga Ялтадан хат яза.

25 май. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан Хәдичә Әпсәләмова (1893–1967) хат яза.

15 июнь. Татарстан Совет язучылары союзының оештыру комитеты президиумы карары нигезендә СССР совет язучылары берлегенә кабул ителүе хакында «Кызыл Татарстан» газетасында белдерү бастырыла.

24 июнь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

24 август. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

12 сентябрь. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

12 сентябрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

7 октябрь. Уфага М. Гафурига Ялтадан хат яза.

4 декабрь. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты бюросы утырышында аның дәвалану һәм көнкүреш-матди мәсьәләләре тикшерелеп, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитетына персональ пенсиясен арттыруны, дәвалау өчен Татарстаннан бирелә торган айлык акчаны 500 сумга күтәрүне сорау хакында карар кабул ителә.

Ялта Хирургия хастаханәсендә плевритка операция ясала.

Казанда Татгосиздатта «Сайланма әсәрләре»нең 2 нче (275 б.), 3 һәм 4 нче (б. 488), 5 нче (б. 303) китаплары, «Безнең көннәр» романының икенче варианты нәшер ителә.

«Казакъ кызы» романы Г. Шәрипова тәрҗемәсендә Мәскәүдә Нәфис әдәбият дәүләт нәшриятында «Дочь степи» (130 с.) исеме белән нәшер ителә.

**1935**

1 гыйнвар. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

Ялта Хирургия хастаханәсендә ике кабыргасы кисеп алына.

15 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

19 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

15 март. Х. Канзафаров «Галимҗан ага белән сөйләшү» дигән мәкалә яза.

1 апрель. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

15 апрель. Х. Канзафаровның «Галимҗан ага белән сөйләшү» дигән мәкаләсе «Коммуна» газетасында бастырыла.

16 май. Казанга К. Нәҗмигә Ялтадан хат яза.

7 июнь. Ялта шәһәре гражданлык актларын теркәү бүлегендә Хәдичә Мөхәммәтдин кызы Фәтхуллина белән рәсми язылышалар (№ 153).

13 июнь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан Х. Әпсәләмова хат яза.

20 июнь. ТАССР төзелүенә 15 ел тулу уңае белән Татарстан Язучылар берлеге Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына һәм юбилей комиссиясенә бүләкләү өчен тәкъдим иткән исемлектә Г. Г. Ибраһимов та бар.

«Тирән тамырлар» романыннан өзек Уфада чыккан «Октябрь» журналының 7–8 нче кушма санында башкорт телендә «Һәнәк фетнәһе» исеме белән бастырыла (б. 37–44).

21 июнь. Аңа характеристика языла.

15 август. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты бюросы утырышында аның хәлен белешү өчен Кави Нәҗмигә Ялтага бару бурычы, бер мәртәбә 3000 сум акча күчерергә Халык комиссарлары Советына, әсәрләрен бастыруны әзерләргә Татгосиздат җитәкчесе Сәгыйть Юнысов (1901–1967) белән К. Нәҗмигә йөкләнә.

9 сентябрь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан Х. Әпсәләмова хат яза.

16 декабрь. А. С. Пушкинның вафатына (1799–1837) 100 ел тулу уңаеннан мәдәни чаралар үткәрү өчен Бөтенсоюз Башкарма Комитеты карары нигезендә төзелгән Комитетка әгъза итеп кертелә (исемлектә № 45).

17 декабрь. А. С. Пушкинның вафатына 100 ел тулу уңаеннан мәдәни чаралар үткәрү өчен Бөтенсоюз Башкарма Комитеты карары нигезендә төзелгән Комитетка әгъза итеп кертелүе хакында «Правда» газетасында хәбәр бастырыла.

20 декабрь. Икенче хатыны Х. Фәтхуллина белән фотога төшәләр (оригиналы Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана: 118840–2).

«Совет әдәбияты» журналының 12 нче санында Татарстан Язучылар союзы әгъзаларына Ялтадан хаты бастырыла (б. 69).

«Татар хатыны ниләр күрми» романы Г. Шәрипова тәрҗемәсендә Мәскәүдә Нәфис әдәбият дәүләт нәшриятында «Татарка» (174 с.) исеме белән нәшер ителә.

«Казакъ кызы» романы рус телендә («Дочь степи») һәм «Тирән тамырлар» романы таҗик телендә («Решанойи чукуррафта») китап булып нәшер ителүләре хакында «Совет әдәбияты» журналының 4–5 нче кушма санында белдерү бастырыла (б. 123).

**1936**

14 гыйнвар. «Пионер каләме» журналы редакциясенә Ялтадан хат яза һәм ул басманың 2 нче санында бастырыла (б. 33).

16 февраль. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

7 март. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

20 март. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

13 апрель. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

13 апрель. Мәскәүгә «Альманах творчество народов СССР» редакциясенә Ялтадан хат яза.

10 май. Казанга К. Тинчуринга 20 еллык хезмәт бәйрәме белән тәбрикләп Ялтадан хат яза.

30 июнь. Мәскәүгә Г. Шәриповага Ялтадан хат яза.

16 август. Персональ пенсиясен 600 сумга җиткерү тәкъдиме белән ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты президиумы Советларның Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты президиумына мөрәҗәгать итәргә карар чыгара.

11 октябрь. Персональ пенсиясен аена 500 сумга җиткерү хакында Советларның Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты президиумы карар кабул итә.

16 октябрь. Персональ пенсиясен аена 500 сумга җиткерү хакында Советларның Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты президиумының карары Татарстан Совет язучылары союзына хәбәр ителә.

26 октябрь. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре Альфред Лепа (1896–1938) ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты бюросында Татарстан Язучылар союзындагы хәлне тикшерү вакытында ясаган чыгышында Г. Ибраһимовка югары бәяләмә бирә.

20 ноябрь. Казанга Татарстан Язучылар союзына Ялтадан хат яза.

Казанда Татгосиздатта «Сайланма әсәрләре»нең 2 нче (532 б.), 3 нче (301 б.) томнары нәшер ителә.

«Тирән тамырлар» романыннан өзек Уфада Башгосиздат нәшриятында башкорт телендә «Суд» исеме белән нәшер ителә (36 б.).

**1937**

8 гыйнвар. Казанга Татарстан Язучылар союзы альманахы редакциясенә Ялтадан хат яза.

14 февраль. Сәясәт эшлеклесе, публицист, шәхес культы чоры корбаннарының берсе (үлгәннән соң акланган) М. Сәгыйдуллин сорау алу вакытында аның хакында объектив фикерләр әйтә.

4 март. ВКП(б) ның Татарстан Өлкә комитеты партия архивы җитәкчесе ВКП(б) Үзәк комитеты каршындагы Татарстан буенча партия контроле комитеты вәкаләтлесе янындагы партия коллегиясенә аның хакында архив белешмәсе бирә.

4 март. ВКП(б) ның Татарстан Өлкә комитеты партия архивы җитәкчесе ВКП(б) Үзәк комитеты каршындагы Татарстан буенча партия контроле комитеты вәкаләтлесе янындагы партия коллегиясенә аның 1921 елда партия чистартуларында булуы хакында архив белешмәсе бирә.

20 март. Язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Галиев (1900–1954) сорау алу вакытында аның хакында тискәре фикерләр әйтә.

25 август. ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты тарафыннан ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе 4 бүлегенең 3 бүлекчәсе башлыгы аны кулга алу хакында карар чыгара.

25 август. Тентү үткәрү һәм аны кулга алу өчен ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты тарафыннан ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе хезмәткәре Сөнгатулла Корбановка (1907–?) ордер бирелә (№ 822).

29 август. Тентү үткәрергә һәм кулга алырга Кырым буенча Эчке эшләр халык комиссариаты идарәсе һәм дәүләт иминлеге Ялта шәһәр бүлеге тарафыннан ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе хезмәткәре С. Корбановка ордер бирелә (№ 197).

29 август. ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе хезмәткәре С. Корбанов аны кулга алу һәм махсус конвой белән Казанга озатканчы Симферополь шәһәрендәге 2 нче категорияле төрмәгә ябып тору хакында карар чыгара.

29 август. Тентү үткәрелә һәм 1920 елда татар партия оешмасында «суллар» дип аталган контрреволюцион милләтче төркемгә кергәне, ә 1925 елда шул төркемнең аерым бер өлеше белән контрреволюцион троцкичы-милләтчел оешмага кергәне һәм анда соңгы вакытка кадәр җитәкчеләрнең берсе булып мәдәни-идеологик фронтта контрреволюцион эш алып баруда гаепләнеп кулга алына һәм Эчке эшләр халык комиссариатының Ялта шәһәре бүлегенә тапшырыла.

30 август. Сәламәтлеге хакында Ялта үзәк хастаханәсе табиплары комиссиясе тарафыннан справка төзелә.

[Дата әлегә билгеле түгел]. Этап белән Казанга кайтарылганчы Симферопольдәге 2 нче категорияле төрмәгә озатыла.

2 сентябрь. 1266744 санлы партбилеты ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе хезмәткәре С. Корбанов тарафыннан ВКП(б)ның Ялта район комитетына секретаре Меджитовка тапшырыла.

3 сентябрь. Партиядән чыгару хакында ВКП(б)ның Ялта район комитеты бюросы карар чыгара.

4 сентябрь. Тентү вакытында алынган «Браунинг»ны 5 патроны белән ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе хезмәткәре С. Корбанов Эчке эшләр халык комиссариатының Ялта шәһәре бүлегенә тапшыра.

4, 5, 7, 8 октябрь. Татарстан язучыларының гомуми җыелышы була һәм анда Г. Ибраһимов та «фаш» ителә. Җыелыш карарының 7 нче маддәсендә «Үзенең әдәби, тарихи әсәрләрендә аңлы рәвештә эсерлык идеологиясен үткәрүче, көндәлек әдәби практикада халык дошманнары белән үсеп тоташкан эсер, милләтче, ялган классик Г. Ибраһимовның зарарлы әсәрләрен газета-журнал битләрендә киң укучылар алдында фаш итүне дәвам итәргә. Г. Ибраһимовка халык дошманы Л. Гыйльми тарафыннан билгеле политик максат белән оештырылган хатка кул куючыларның бу мәсьәлә буенча эшләрен тикшереп ачыкландырырга һәм тиешле чара күрергә» диелә.

5 октябрь. Этап белән Казанга кайтарыла һәм 1 нче санлы төрмәгә ябыла.

21 октябрь. Тикшерү мәнфәгатьләрендә Казанның 1 нче санлы төрмәсенең эчке изоляторына күчерү хакында карар кабул ителә.

Октябрь. «Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы 10 нчы санында әдәбият белгече Гали Халитның (Гали Мөхәммәтгалиевич Халитов, 1915–1992) «Совет матур әдәбияты фронтында көрәш һәм уңышларның 20 елы» дигән мәкаләсе бастырыла (б. 70–87). Анда Г. Ибраһимовны «фаш» итүгә юнәлтелгән өлешләр дә бар.

10 ноябрь. Тентү вакытында алынган паспорты (КВ № 048543), галимнәргә булышлык итү Комиссиясе таныклыгы, Язучылар союзы әгъзасы билеты (№ 1683), Хезмәт Батыры грамотасы ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсенә сакланмага тапшыру турында ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсенең карары кабул ителә.

10 ноябрь. Тентү вакытында алынган ике саклык кенәгәсен алу һәм аларны ТАССР Эчке эшләр халык комиссариатының финанс бүлегенә тапшыру турында ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсенең карары кабул ителә.

16 ноябрь. Тентү вакытында алынган ике саклык кенәгәсе ТАССР Эчке эшләр халык комиссариатының финанс бүлегенә тапшырыла.

8 декабрь. Аның белән аралашкан кешеләр хакында Дәүләт иминлеге хезмәткәре З. Әминов ВКП(б)ның ТАССР Өлкә комитеты беренче секретаре Александр Алемасовка (1902–1972) хат яза.

9 декабрь. 1 нче санлы төрмәдән ОМЗга күчерү хакында Дәүләт иминлеге идарәсе карар кабул итә.

31 декабрь. ГИДУВ доценты Захаров аның сәламәтлеген тикшергәннән соң, ышанычсыз дип таба.

**1938**

4 гыйнвар. Партия сафларыннан чыгару хакында ВКП(б)ның Ялта район комитеты карар кабул итә.

21 гыйнвар. Казан шәһәренең 1 нче санлы төрмә лазаретында вафат була. Бу хакта ОМЗ табибы Маврина, лекпом Байкеев һәм өлкән надзиратель Петров тарафыннан акт төзелә (№ 3) һәм үлем сәбәбе үпкә һәм плеврит туберкулезы дип күрсәтелә.

24 гыйнвар. Вафаты хакында төрмә башлыгына хәбәр ителә (22, 23 гыйнвар ял көннәре булу сәбәпле).

27 гыйнвар. Казанның Архангел зиратында гомуми тәртиптә җирләнелә.

29 гыйнвар. Җирләнүе хакында белешмә языла.

17 апрель. ВКП(б)ның ТАССР Өлкә комитеты бюросының утырышы Татар АССРы Главлитының авторлары халык дошманы булган китапларны, брошюраларны китап сәүдәсе челтәреннән һәм җәмәгать файдалана торган китапханәләрдән алдыру хакындагы 1 нче санлы приказы белән килешергә дигән карар чыгара. Исемлектә Г. Ибраһимов 13 нче сан белән теркәлгән.

17 июнь. ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсе, Г. Ибраһимов үлү сәбәпле, аңа карата тикшерү эшләрен туктату хакында карар кабул итә.

**1939**

4 апрель. Г. Ибраһимов эше 1 нче махсус бүлеккә тапшырыла.

26 апрель. ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты дәүләт иминлеге идарәсенең эчке төрмәсе башлыгы Г. Ибраһимовның 1937 елның август, сентябрь, октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында анда булмавы һәм ул Казанның башка төрмәләреннән комиссариатка сорау алырга китерелмәве хакында белешмә яза.

31 август. Сәясәт эшлеклесе Микъдәт Борындыков (1896–1965) ТАССР Эчке эшләр халык комиссарына язган гаризасында Г. Ибраһимовның латин алфавитына күчүгә нык каршы булуын белдерә.

**1944**

Апрель. Элекке язучы Г.Г. Ибраһимовның тормышы һәм эшчәнлеге хакында дәүләт иминлеге хезмәткәре майор Юнысов белешмә яза.

**1954**

Декабрь. Тел, әдәбият һәм тарих институтында язучылар катнашлыгында шәхес культы чоры корбаннары булган язучыларга, шул исәптән Г. Ибраһимовка багышлы вакыйгаларны ачыкларга кирәклеге хакында җыелыш үткәрелә. Тиздән җитәкчесе партия Өлкә комитетының өченче секретаре Салих Батыев (1911–1985) булган комиссия төзелә. Анда Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гомәр Бәширов (1901–1999) та кертелә.

**1955**

30 март. Язучы Әмирхан Еники (1909–2000) Советлар Союзы коммунистлар партиясе Үзәк комитетына (күчермәсе: КПССның Татарстан Өлкә комитетына) Г. Ибраһимовның эшен яңадан карап, аның шәхси тормышына да һәм иҗади мирасына да ачыклык кертүне үтенеп мөрәҗәгать итә.

24 май. Татарстан АССРы прокуратурасы Г.Г. Ибраһимов эшен карауны ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына тапшыру хакында карар кабул итә.

30 май. Татарстан АССРы прокуратурасы Г.Г. Ибраһимов эшен карауны яңадан башлау хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә хат юллый.

7 май. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты Г. Ибраһимовның әсәрләрен өйрәнү һәм аның иҗат юлын ачыклау өчен эксперт комиссиясе төзү хакында карар кабул итә.

5 июнь. Мәскәү өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсенең тикшерү бүлеге башлыгы һәм аның урынбасары Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны сорап СССР Эчке эшләр министрлыгының Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы идарәсе башлыгына хат юллыйлар.

6 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары Г. Ибраһимовның

эсерлар партиясенә мөнәсәбәте, Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соңгы эшчәнлеге хакында мәгълүматны бирүне сорап Башкорт АССРы Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгына хат юллый.

6 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары Г. Г. Ибраһимов хакында архив документлары бирүне сорап СССР Министрлар Советы янындагы Мәскәү өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе башлыгына хат юллый.

6 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары Г. Ибраһимовның электә эсерлар партиясе белән бәйле һәм аның татар партия оешмасында төркемнәрендә катнашуы хакында булган мәгълүматны бирүне сорап УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгына хат юллый.

11 июнь. УССРның Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгы Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны бирүне сорап Кырым өлкәсе буенча Эчке эшләр министрлыгы идарәсенең 1 нче махсус бүлегенә хат юллый.

13 июнь. УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгы Г. Ибраһимовның эсерлар партиясе белән бәйле һәм татар партия оешмасында төркемнәрдә катнашуы хакында булган мәгълүматны бирүне сорап Украина коммунистлар партиясенең Кырым Өлкә комитеты партия архивы мөдиренә хат юллый.

15 июнь. КПССның Татарстан Өлкә комитеты янындагы Партия тарихы институты архивы сектор мөдире Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә хәбәр итә.

20 июнь. Мәскәү өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгына Г. Ибраһимовка кагылышлы мәсьәләләр белән СССРдагы башка архивларга мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә.

20 июнь. Уфа шәһәренең Үзәк дәүләт архивы башлыгы БАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлегенә Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны хәбәр итә.

22 июнь. ТАССР Үзәк дәүләт архивы башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгына Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны хәбәр итә.

23 июнь. СССР Үзәк дәүләт тарих архивы башлыгы Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны әзерли.

23 июнь. Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә Г. Ибраһимов хакында булган белешмәне хәбәр итә.

23 июнь. Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш үзәк дәүләт архивы Г. Ибраһимов хакында белешмә әзерли.

25 июнь. СССР Эчке эшләр министрлыгының Баш архив идарәсе ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә Г. Ибраһимов хакында булган белешмәне җибәрүне хәбәр итә.

27 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты Г. Ибраһимовның әсәрләрен өйрәнү һәм аның иҗат юлын ачыклау өчен төзелгән эксперт комиссиясенә өстәмә белгечләр кертү хакында карар кабул итә.

28 июнь. УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты тикшерү бүлеге башлыгына Украина коммунистлар партиясе Кырым Өлкә комитеты партия архивы белән хәбәрләшүен җиткерә.

28 июнь. БАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының тикшерү бүлеге башлыгы Үзәк архивта Г. Г. Ибраһимов хакында нинди дә булса башка мәгълүмат юклыгын хәбәр итә.

6 июль. Харьков шәһәрендәге Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш Үзәк дәүләт архивы директоры УССР Министрлар Советы янындагы Киев өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгына Г. Г. Ибраһимов хакында мәгълүмат юклыгын хәбәр итә.

7 июль. Киев Өлкә дәүләт архивы директоры УССР Министрлар Советы янындагы Киев өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсе тикшерү бүлеге башлыгына Г. Г. Ибраһимов хакында мәгълүмат юклыгын хәбәр итә.

16 сентябрь. КПССның Татарстан Өлкә комитеты янындагы Партия тарихы институты архивы сектор мөдире ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә Г. Ибраһимов хакында булган мәгълүматны хәбәр итә.

20 сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзасы СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Г. Халит Г. Ибраһимов әсәрләренә бәяләмә яза.

22 сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзасы СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Хәйри Гыймадетдинов (1912–1961) Г. Ибраһимов әсәрләренә бәяләмә яза.

Сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзасы Казан дәүләт университеты укытучысы, филология фәннәре кандидаты Ибраһим Нуруллин (1923–1995) Г. Ибраһимов әсәрләренә бәяләмә яза.

24 сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзалары Г. Халит, Х. Гыймадетдинов, И. Нуруллин бәяләмәләрен берләштереп язалар.

24 сентябрь. Гамәлләрендә җинаять эше булмау сәбәпле, ТАССР Министрлар кабинеты каршындагы Дәүләт иминлеге комитеты карары нигезендә аңа карата тикшерү эшләре туктатыла.

Сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзасы Казан дәүләт педагогия институты доценты, филология фәннәре кандидаты И. Рахлин Г. Ибраһимов әсәрләренә бәяләмә яза.

26 сентябрь. Эксперт комиссиясе әгъзасы Казан дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты Иван Пехтелев (1906–1969) Г. Ибраһимов әсәрләренә бәяләмә яза.

29 октябрь. Аклануы хакында СССР Прокуратурасы язучы Ә. Еникигә хат юллый.

Казанда Татарстан китап нәшриятында өч томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче (595 б.), 3 нче (611 б.) томнары нәшер ителә.

**1956**

8 июнь. Энесе Хәким (Габделхәким) Ибраһимов (1896–1957) ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына Г. Г. Ибраһимовның үлү хакындагы таныклыгын бирүне сорап мөрәҗәгать итә.

11 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисе урынбасары ТАССР эчке эшләр министры урынбасарына Г. Г. Ибраһимовның үлү фактын теркәргә һәм үлү хакындагы таныклыгын туганы Х. Г. Ибраһимовка яки соңгысының туганы С. С. Янышевка бирүне сорап хат юллый.

**1957**

14 гыйнвар. Х. Фәтхуллина СССР Министрлар Советы рәисе Николай Булганинга (1895–1975) Кырымнан фатир бирүләрен сорап мөрәҗәгать итә.

1 февраль. Кырым Өлкә партия архивы мөдире КПССның Татарстан Өлкә комитеты партия комиссиясе рәисе Федотовка ВКП(б)ның Ялта район комитеты 1937 елның 3 сентябрендә Г. Г. Ибраһимовны партия сафларыннан чыгару карары хакында архив белешмәсе җибәрә.

14 февраль. КПССның Татарстан Өлкә комитеты бюросы утырышы Г. Г. Ибраһимовны партиядә реабилитацияләү (үлгәннән соң) хакында карар кабул итә.

10 март. Х. Фәтхуллина ирен кулга алганда конфискацияләнгән ике саклык кенәгәсен кире кайтарып бирүне сорап ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына мөрәҗәгать итә.

11 март. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының исәп-архив бүлеге башлыгы Г. Г. Ибраһимовны кулга алганда конфискацияләнгән ике саклык кенәгәсе кайчан, кая һәм ни рәвешле дәүләткә тапшырылганлыгы хакында хәбәр итүне сорап ТАССР Эчке эшләр министрлыгының финанс бүлеге башлыгына хат юллый.

12 март. Тууына 70 ел тулу уңаеннан Казан дәүләт университеты һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты белән берлектә университетның актлар залында тантаналы кичә уздыра.

28 март. Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитетының исәп-архив бүлеге башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт

иминлеге комитетының исәп-архив бүлеге башлыгына Х. Фәтхуллинаның хатын җибәрә.

11 май. ТАССР Эчке эшләр министрлыгының финанс бүлеге башлыгы һәм казначее Г. Ибраһимовның саклык кенәгәләре 1937 елның 16 ноябрендә ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты Дәүләт иминлеге комитетының финанс бүлеге тарафыннан кабул итеп алынганлыгы хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының исәп-архив бүлеге башлыгына хәбәр итә.

20 май. Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы ТАССР дәүләт хезмәт саклау кассалары һәм дәүләт кредиты җитәкчеләренә Г. Ибраһимовка кагылышлы документлар булу-булмавын хәбәр итүләрен сорап мөрәҗәгать итә.

20 май. Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Кырым өлкәсе Ялта шәһәре дәүләт хезмәт саклау кассалары һәм дәүләт кредиты җитәкчеләренә Г. Ибраһимовка кагылышлы документлар булу-булмавын хәбәр итүләрен сорап мөрәҗәгать итә.

29 май. Кырым өлкәсе Ялта шәһәре 4549 санлы Үзәк дәүләт хезмәт саклык кассасы мөдире, Бөек Ватан сугышы вакытында шәһәр оккупациядә булу сәбәпле, касса документларының сакланмавы хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына хәбәр итә.

6 июнь. ТАССР дәүләт хезмәт саклау кассалары һәм дәүләт кредиты идарәсе башлыгы урынбасары Казан шәһәре кассаларында Г. Г. Ибраһимовка кагылышлы документлар булмавы хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгына хәбәр итә.

25 июнь. Х. Фәтхуллина ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисе исеменә юллаган элекке хатына өстәмә мәгълүмат яза.

26 июнь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының исәп-архив бүлеге оператив уполномоченные ярдәмчесе, дәгъва вакыты чыгу сәбәпле, Х. М. Фәтхуллина-Ибраһимовага ике саклык кенәгәсен кайтарып бирүне кире кагу хакында карар чыгара.

5 ноябрь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлеге оператив уполномоченные ярдәмчесе Г. Г. Ибраһимов хакында белешмә яза.

Казанда Татарстан китап нәшриятында өч томлы «Сайланма әсәрләр»енең 1 нче томы нәшер ителә (527 б.).

«Казакъ кызы» һәм «Тирән тамырлар» Г. Шәрипова тәрҗемәсендә Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында «Дочь степи. Глубокие корни» исеме белән бер китап итеп нәшер ителә (323 с.).

Г. Шәрипова тәрҗемәсендә һәм Г. Халитнең «Галимджан Ибрагимов (Очерк жизни и творчества)» дигән кереш мәкаләсе белән Казанда Татарстан китап нәшриятында «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар» романнары тупланган рус телендә «Избранное» бастырыла (456 с.).

«Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «Мәдрәсә яшьләре» («Безнең көннәр» романыннан өзек), «Алмачуар» әсәрләре тупланмасы Казанда Татарстан китап нәшриятында «Алмачуар: Хикәяләр» исеме белән нәшер ителә.

«Карт ялчы» хикәясе язучы Газиз Иделле (1905–1985) тарафыннан әзерләнеп, Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында нәшер ителгән «Татарские рассказы» дигән китапта «Старый батрак» исеме белән бастырыла (с. 11–30).

**1958**

1 август. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Хәсән Хәйруллин (1910–1994) реабилитацияләнгән татар язучылары һәм галим филологларының архив материалларын һәм кульязмаларын эзләүдә ярдәм итүен үтенеп ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә мөрәҗәгать итә.

8 сентябрь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Дәүләт иминлеге комитеты архивында Г. Ибраһимовның кульязмалары юклыгы хакында СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Х. Хәйруллинга хәбәр итә.

Казанда Татарстан китап нәшриятында «Кызыл чәчәкләр (Без түбәннән күтәрелдек)» дигән хикәясе нәшер ителә.

**1959**

Әдәбият галиме Мансур Хәсәновның (1930–2010) «Яшь йөрәкләр» романы» дигән китабы нәшер ителә.

**1960**

Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театрында «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре сәхнәләштерелә.

Казанда «Әдәбият мәсьәләләре» (243 б.) дигән китабы нәшер ителә.

«Казакъ кызы» романы Җакан Сыздыков тәрҗемәсендә казакъ телендә нәшер ителә («Қазақ қызы»).

**1961**

Февраль. Әдәбиятчы М. Х. Хәсәнов тарафыннан «Галимҗан Ибраһимов иҗаты: (Октябрьгә кадәрге чор)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Уфа шәһәр Советы башкарма комитеты карары нигезендә «Уральский проспект» урамына күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, күп еллар Уфа шәһәрендә эшләгән Галимҗан Ибраһимов исеме бирелә. Әдипнең тууына 80 ел тулу уңае белән 1967 елда ул Ибраһимов бульвары дип үзгәртелә.

«Тирән тамырлар» романы Абдулла Уразаев тәрҗемәсендә үзбәк телендә нәшер ителә («Теран томирлар (Ҳақ гап)», 275 б.).

«Татар хатыны ниләр күрми» романыннан өзек «Җиләк җыйганда» исеме белән Казанда Татар китап нәшриятында нәшер ителә.

«Көтүчеләр» («Пастухи»), «Карт ялчы» («Старый батрак»), «Алмачуар» («Чубарый. История одной любви») хикәяләре Г. Кәримова тәрҗемә-

сендә Мәскәүдә «Детгиз» нәшриятында «Чубарый» исеме белән аерым китап итеп нәшер ителә (112 с.).

**1962**

14 март. Тууына 75 ел тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тантаналы җыелыш була.

15 март. Тууына 75 ел тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тантаналы җыелыш булуы хакында «Социалистик Татарстан» газетасында хәбәр ителә.

11 апрель. Иренең кулъязмаларын эзләүдә ярдәм итүен сорап, Х. Фәтхуллина ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты рәисенә мөрәҗәгать итә.

23 апрель. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Г. Ибраһимовка кагылышлы документлар хакында мәгълүмат бирүне сорап Кырым өлкәсе Ялта шәһәре 4549 санлы дәүләт хезмәт саклык кассасы мөдиренә хат юллый.

7 май. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Г. Ибраһимовка кагылышлы документлар хакында мәгълүмат бирүне тизләтүне сорап Кырым өлкәсе Ялта шәһәре 4549 санлы дәүләт хезмәт саклык кассасы мөдиренә хат юллый.

21 май. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек инспекторы Х. М. Фәтхуллина дәгъвасы буенча Г. Ибраһимов кулга алынганда конфискацияләнгән ике саклык кенәгәсендәге акчаларны аның варисларына кайтарып бирү мәсьәләсен хәл итүне карау өчен тикшерү материалларын ТАССР Финанс министрлыгы комиссиясенә тапшырырга кирәклеге хакында нәтиҗә чыгара.

31 май. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Х. М. Фәтхуллина дәгъвасы буенча ТАССР финанс министры урынбасарына хат юллый.

7 август. ТАССР финанс министры урынбасары һәм дәүләт керем бүлеге башлыгы Казан шәһәре финанс бүлеге башлыгына (күчермәсе ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына) Г. Г. Ибраһимовның саклык кенәгәләрендәге акчаны 1947, 1961 еллардагы акча реформасын истә тотып, варисларына бирергә тәкъдим итә.

15 август. Ялта шәһәре ЗАГС бюросы җитәкчесе Г. Г. Ибраһимов белән Х. М. Фәтхуллинаның рәсми язылышу актының күчермәсен җибәрү хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгына хәбәр итә.

6 декабрь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты архивында Г. Ибраһимовның 48 бит күләмендә сакланган кулъязмасы 1962 елның 6 декабрендә КПССның Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Мөнәвәр Тутаевка (1924–1994) тапшырыла.

«Безнең көннәр» романыннан өзек Р. Фәизова тәрҗемәсендә «Море людское» исеме белән «Советская Татария» газетасында бастырыла.

Тууына 75 ел тулу уңаеннан Ленинградта М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге дәүләт китапханәсенең СССР халыклары әдәбияты бүлегендә

бу датага багышлап күргәзмә оештырыла. Анда язучының әзәрбәйҗан, башкорт, үзбәк, казах һәм башка халыклар телләренә тәрҗемә ителгән әсәрләре куела.

«Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Карак мулла», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Сөю-сәгадәт (Карт шагыйрьнең тәэсораты)», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», «Габдрахман Салихов» хикәяләре тупланып, Уфада башкорт телендә «Хикәйәләр» җыентыгы нәшер ителә (168 б.).

«Безнең көннәр» романы Р. Фәизова тәрҗемәсендә Казанда Татарстан китап нәшриятында «Наши дни» исеме белән нәшер ителә (339 с.).

«Татар хатыныниләр күрми» романыннан өзек «Азат хатын» журналының 3 нче санында бастырыла (б. 20–21).

«Татар хатыны ниләр күрми» романыннан өзек «Фәгыйлә» исеме белән «Ялкын» журналының 3 нче санында бастырыла (б. 27–30).

**1963**

Педагог Г.М. Әдһәмова (1927–2016) тарафыннан «Галимҗан Ибраһимов иҗатында хатын-кыз азатлыгы проблемасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Сынчы Бакый Урманче (1897–1990) тарафыннан бюсты ясала.

**1964**

М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов: Тормышы һәм иҗат юлы» дигән китабы нәшер ителә.

Ш. Әхтәмовның «Мәктәптә Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнү: әдәбият укытучылары өчен кулланма» дигән китабы нәшер ителә.

«Казакъ кызы» романы А. Уразаев тәрҗемәсендә үзбәк телендә нәшер ителә («Қозоқ қизи», 207 б.).

«Тирән тамырлар» романы Р. Фәизова тәрҗемәсендә «Глубокие корни» исеме белән Мәскәүдә «Художественная литература» нәшриятында нәшер ителә (227 с.).

**1965**

27 гыйнвар. Архивларында Г.Г. Ибраһимовның кулъязмалары булу-булмавын тикшерүне сорап ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитетына хат юллый.

20 февраль. Архивларында Г.Г. Ибраһимовның кулъязмалары булу-булмавын тикшерүне сорап ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты исәп-архив бүлеге башлыгы СССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты исәп-архив бүлеге башлыгына хат юллый.

29 март. Архивларында Г.Г. Ибраһимовның кулъязмалары юклыгы хакында СССР Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивы башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгына хәбәр итә.

9 апрель. Г. Г. Ибраһимовның кульязмалары булу-булмавын тикшерүне сорап ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты исәп-архив бүлеге башлыгы Баш архив идарәсенә хат юллый.

13 август. Ире Г. Г. Ибраһимов кулга алынган вакытта конфискацияләнгән документларны, кульязмаларны һәм китапларны кире кайтарып бирүне сорап Э.-Г. Д. Мөхәммәдова СССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетына мөрәҗәгать итә.

21 август. Э.-Г. Д. Мөхәммәдова ире Г. Г. Ибраһимов кулга алынган вакытта конфискацияләнгән документларны, кульязмаларны һәм китапларны кире кайтарып бирүне сорап язган мөрәҗәгатен карауны сорап СССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының 1 нче бүлеге башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты исәп-архив бүлеге башлыгына хат юллый.

28 август. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы аларда Г. Г. Ибраһимовның кульязмалары һәм китаплары юклыгы хакында Э.-Г. Д. Мөхәммәдовага хәбәр итә.

8 октябрь. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы Г. Г. Ибраһимов кулга алынганда конфискацияләнгән документлы бер папканың вакытлар үтү белән юкка чыгуы хакында Э.-Г. Д. Мөхәммәдовага хәбәр итә.

12 октябрь. Файдалану өчен кирәге булмау сәбәпле Г. Г. Ибраһимовның архив җинаять эшен кире кайтару хакында СССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының 1 нче бүлеге башлыгы ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты исәп-архив бүлеге башлыгына хат юллый.

**1966**

14 декабрь. «Безнең көннәр» романыннан өзек «Комсомолец Татарии» газетасында «Наши дни» исеме белән бастырыла.

Казанда язучы А. Шамов тарафыннан төзелгән «Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр», М. Хәсәновның «Галимджан Ибрагимов: Краткий очерк жизни и творчества» дигән китаплар нәшер ителә.

«Безнең көннәр» романы Р. Фәизова тәрҗемәсендә Мәскәүдә «Советский писатель» нәшриятында «Наши дни» исеме белән нәшер ителә (411 с.).

Казанда нәшер ителгән «Безнең Ильич» дигән китапта «Пролетариат диктатурасы һәм Ленин» (б. 84–90) исемле мәкаләсе бастырыла.

**1967**

Г. Ибраһимовның тууына 80 ел тулу уңаеннан Солтанморат урта мәктәбендә аның музее ачыла. Аның төп оештыручылары мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәйруллина Нәҗибә Хәбибулла кызы һәм мәктәп рәссамы Галиәсгаров Галимҗан Сабирҗан улы була.

Гыйнвар-февраль. Әдәбият галиме О. Х. Кадыйров тарафыннан «Романтизм Галимджана Ибрагимова (Творчество и эстетика)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

18 гыйнвар. «Алмачуар» хикәясеннән өзек «Яшь ленинчы» газетасында бастырыла.

6 март. Казан шәһәренең Ленин районы Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы урта мәктәбендә әдипнең музее һәм һәйкәле ачыла.

10 март. «Казакъ кызы» романыннан өзек Г. Шәрипова тәрҗемәсендә «Казахстанская правда» газетасында «Похищение» исеме белән бастырыла.

16 март. Тууына 80 ел тулу уңаеннан Оренбургта Офицерлар йортында юбилей кичәсе уздырыла.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына Г. Ибраһимов исеме бирелә.

Әдәбият галиме Ү. И. Гыймадиев (1920–1987) тарафыннан «Г. Ибраһимовның Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорындагы публицистик эшчәнлеге» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Татарстан мәктәпләре арасында әдип исеменә лаек булу өчен конкурс игълан ителә һәм Казанның 89 нчы мәктәбе җиңүче дип табыла.

Уфада Ү. И. Гыймадиевның башкорт телендә «Ғалимьян Ибраһимов – журналист» дигән китабы нәшер ителә.

Казанда Татарстан китап нәшриятында «Алмачуар» хикәясе нәшер ителә.

Казанда нәшер ителгән «Габдулла Кариев турында истәлекләр» дигән китапта «Габдулла Кариев иптәш рухына» (б. 17–18) исемле мәкаләсе бастырыла.

**1968**

6 март. Казан шәһәренең Ленин районы Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы урта мәктәбендә (Восстание урамы, 104) әдипкә музей һәм һәйкәл ачыла (скульпторы Виктор Рогожин).

15 март. Тууына 90 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни конференция уздырыла.

21 май. Г. Г. Ибраһимов кулга алынган вакытта конфискацияләнгән кулъязмаларны һәм китапларны эзләүдә язучы Э. Д. Мөхәммәдовага ярдәм итүне сорап Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре А. Уразаев Ялта шәһәре Дәүләт иминлеге комитетына мөрәҗәгать итә.

20 июнь. Үзләрендә Г. Г. Ибраһимовның кулъязмалары һәм китаплары юклыгы хакында УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсенең бүлек башлыгы урынбасары УССР Министрлар Советы янындагы Кырым өлкәсе буенча Дәүләт иминлеге комитеты идарәсенең 10 нчы бүлекчәсе башлыгына һәм ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының 10 нчы бүлекчә башлыгына хат юллый һәм бу хакта 1968 елның 10 июнендә Э. Д. Мөхәммәдовага хәбәр ителүен белдерә.

26 июнь. Г.Г. Ибраһимов кулга алынганда аның кулъязмалары һәм китаплары конфискацияләнмәве хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитетының бүлек башлыгы Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Абдулла Уразаевка хат юллый һәм бу хакта 1965 елның 28 августында Э.Д. Мөхәммәдовага хәбәр ителүен белдерә.

Казанда нәшер ителгән «Шиһабетдин Мәрҗани: Мәкаләләр җыентыгы» дигән китапта «Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре (Юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть)» (б. 48–61) исемле мәкаләсе бастырыла.

**1969**

М. Хәсәновның «Галимджан Ибрагимов» дигән китабы нәшер ителә.

Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театрында «Тирән тамырлар» әсәре сәхнәләштерелә.

Казанда Татарстан китап нәшриятында «Карт ялчы» хикәясе нәшер ителә.

**1970**

Июль. Татарстан Культура министрлыгы һәм Татарстан Язучылар союзы идарәсе тәкъдиме белән Г. Ибраһимов каберенә һәйкәл куела (скульпторы – Ю.Л. Рычков).

«Оҗмах сезгә, дөнья безгә» дигән китапта «Карак мулла» хикәясе бастырыла (б. 208–222).

**1971**

Февраль. М.Ш. Маннурова тарафыннан «Татар тарихи-революцион романында интернациональ идеяләр һәм образлар (Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, И. Гази романнарында рус революционеры сурәтләнеше) дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

М.Х. Хәсәнов тарафыннан «Эволюция творчества Г. Ибрагимова в послеоктябрьский период» дигән темага докторлык диссертациясе яклана.

«Көтүчеләр» («Пастухи»), «Карт ялчы» («Старый батрак»), «Алмачуар» («Чубарый. История одной любви») хикәяләре Г. Кәримова тәрҗемәсендә Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында «Чубарый» исеме белән аерым китап булып нәшер ителә (111 с.).

Уфада С.Ш. Поварисовның (1924–2016) «Язык и стиль прозы Г. Ибрагимова» дигән махсус курс программасы нәшер ителә.

Рәссам Лотфулла Фәттахов (1918–1981) тарафыннан портреты языла.

**1973**

«Тирән тамырлар» романы Р. Фәизова тәрҗемәсендә «Глубокие корни» исеме белән Казанда Татарстан китап нәшриятында нәшер ителә (224 с.).

**1974**

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 1 нче томы нәшер ителә (510 б.).

Сигез томлы «Әсәрләр»енең 1 нче томы нәшер ителә.

Уфада С. Поварисовның «Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлекләре һәм аларны мәктәптә өйрәнү: (Методик кулланма)» дигән китабы нәшер ителә.

**1975**

Ф. М. Газизова тарафыннан «Галимҗан Ибраһимов прозасының теле һәм стиле» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Г. Мөхәммәдованың «Яшьлек көннәре» дигән повесте нәшер ителә.

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 2 нче (478 б.), 3 нче (454 б.), 5 нче (616 б.) томнары нәшер ителә.

**1976**

27 февраль. ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты архивында Г. Ибраһимовның 48 бит күләмендә сакланган кулъязмасы 1962 елның 6 декабрендә КПССның Татарстан Өлкә комитетының беренче секретаре Мөнәвәр Тутаевка (1924–1994) тапшырылуы хакында белешмә языла.

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 4 нче томы нәшер ителә (459 б.).

Р. Фәизова тәрҗемәсендә һәм Р. Мостафинның «Многогранный талант» дигән кереш мәкаләсе белән Мәскәүдә «Художественная литература» нәшриятында «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» романнары, «Карт ялчы», «Габдрахман Салихов» хикәяләре тупланган рус телендә «Избранное» бастырыла (395 с.).

Казанда нәшер ителгән «Габдулла Кариев: Мәкаләләр, истәлекләр, документлар» дигән китапта «Габдулла Кариев иптәш рухына» (б. 44–45) исемле мәкаләсе бастырыла.

**1977**

15 март. Тууына 90 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни конференция уздырыла.

Тууына 90 ел тулу уңаеннан Уфа шәһәрендәге 65 нче гимназия-мәктәбендә бәйрәм чаралары үткәрелә.

16 март. Тууына 90 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни конференция уздырылуы хакында «Социалистик Татарстан» газетасында хәбәр бастырыла.

«Карт ялчы» хикәясеннән өзек «Комсомолец Татарии» газетасында «Старый батрак» исеме белән бастырыла.

9 декабрь. Тууына 90 ел тулу уңаеннан Мәскәүдә, Язучылар Үзәк йортында тантаналы кичә үткәрелә.

М. Хәсәновның «Галимджан Ибрагимов» дигән монографиясе нәшер ителә.

Мәскәүдә М. Х. Хәсәновның «Писатель, ученый, революционер: Страницы жизни и творчества Галимджана Ибрагимова» дигән китабы нәшер ителә.

Рәссам Мансур Рәхимов тарафыннан портреты язылa.

Ш. Ә. Әхтәмовның «Галимҗан Ибраһимов мәктәптә: Әдәбият укытучылары өчен кулланма. Тулыландырылган икенче басма» дигән китабы нәшер ителә.

«Безнең көннәр» романыннан өзек «Наши дни» исеме белән Казанда Татарстан китап нәшриятында нәшер ителгән «Казань в художественной литературе» дигән китапта бастырыла (с. 199–207).

**1978**

Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театрында «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре сәхнәләштерелә.

Уфада С. Ш. Поварисовның «Система образных средств в художественной прозе Г. Ибрагимова: Лексика» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

Сигез томлы «Әсәрләр»енең 5 нче томы нәшер ителә.

**1979**

Уфада Ф. Г. Габсәламова, Ү. И. Гыймадиев тарафыннан төзелгән «Галимджан Ибрагимов: Библиографический указатель (1907–1977)» дигән китап нәшер ителә.

Уфада С. Ш. Поварисовның «Язык и стиль прозы Г. Ибрагимова» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

**1980**

10 октябрь. Гамәлләрендә җинаять эше булмау сәбәпле, Г. Ибраһимовка карата кузгатылган эшнең 1955 елның 24 сентябрендә туктатылуы хакында ТАССР Министрлар Советы янындагы Дәүләт иминлеге комитеты бүлек башлыгы КПССның Татарстан Өлкә комитеты партия архивы башлыгы Г. Касыймовка белешмә бирә.

М. Х. Хәсәнов (рәис), М. К. Мөхәррәмов, Н. Г. Гыйззәтуллин, Н. Г. Юзиев редакциясендә «Писатель, революционер, ученый: материалы науч. конф., посвящ. 90-летию Галимджана Ибрагимова» дигән җыентык нәшер ителә.

Уфада С. Ш. Поварисовның «Система образных средств в художественной прозе Г. Ибрагимова: Фразеология» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

**1982**

Уфада Ү. Гыймадиевның башкорт телендә «Талант һәм хеҙмәт. Ғалимьян Ибраһимов ижады тураһында әҙәби-публицистик мәҡәләләр» дигән китабы нәшер ителә.

**1983**

Р. М. Мөхәммәтшин тарафыннан «От революционного демократизма к марксизму-ленинизму (эволюция философских и общественно-политических взглядов Г. Ибрагимова)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

**1984**

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 7 нче томы нәшер ителә (539 б.).

**1986**

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 6 нчы томы нәшер ителә (605 б.).

**1987**

11 март. Тууына 100 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә фәнни конференция уздыра.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында студентларның Бөтенсоюз фәнни конференциясе була.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында музей-бүлмәсе ачыла.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан Казанның 73 нче мәктәбендә кичә уздырылуы хакында «Яшь ленинчы» газетасында хәбәр бастырыла.

12 март. Тууына 100 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтына Татарстан Язучылар берлеге белән берлектә фәнни конференция уздырыла.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан Казан дәүләт университетында студентларның Бөтенсоюз фәнни конференциясе уздырыла.

Тууына 100 ел тулу уңаеннан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында тантаналы җыелыш була.

13 март. Тууына 100 ел тулуны үткәрү буенча СССР Язучылар союзы идарәсе Бөтенсоюз юбилей комиссиясе төзү хакында «Социалистик Татарстан» газетасында хәбәр бастырыла.

18 март. Тууына 100 ел тулу уңаеннан Октябрьнең 40 еллыгы исем. Башкорт дәүләт университеты ректораты, парткомы тантаналы кичә уздыра.

М. Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театрында тантаналы җыелыш була.

13 март. Тууына 100 ел тулу уңаеннан СССР Язучылар берлеге идарәсе Бөтенсоюз юбилей комиссиясе төзүе хакында «Социалистик Татарстан» газетасында хәбәр бастырыла.

22 март. Тууына 100 ел тулу уңаеннан Оренбургта «Строитель» Мәдәният сараенда тантаналы кичә уздырыла.

3 апрель. Тууына 100 ел тулу уңаеннан Мәскәүдә язучыларның Үзәк йортында тантаналы кичә уздырыла.

4 апрель. Тууына 100 ел тулу уңаеннан 3 апрельдә Мәскәүдә язучыларның Үзәк йортында тантаналы кичә уздырылуы хакында «Вечерняя Казань» газетасында хәбәр бастырыла.

7 апрель. Тууына 100 ел тулу уңаеннан истәлеген мәңгеләштерү максатыннан ТАССР Министрлар Советы, Актаныш районының «Кызыл көч» колхозы членнарының гомуми җыелышы, КПССның Актаныш райкомы бюросы һәм район Советы башкарма комитеты тәкъдимен исәпкә алып, «Кызыл көч» колхозының исемен «Галимҗан Ибраһимов исемендәге» дип үзгәртү турында карар кабул итә.

6 июнь. Тууына 100 ел тулу уңаеннан Солтанморат авылында язучының әдәби музее ачыла һәм һәйкәле (скульптор – З. Басыйров (1927–2000) куела.

Казанда Татарстан китап нәшриятында сигез томлы «Сайланма әсәрләр»енең 8 нче томы нәшер ителә (431 б.).

Уфада «Тирән тамырлар» романы һәм хикәяләре башкорт теленә тәрҗемә итеп бастырыла («Тәрән тамырҙар: Роман, хикәйәләр»).

Уфада Ү. И. Гыймадиев (җитәкче), Р. Г. Сибәгатов, К. С. Дәүләтшин редакциясендә «Галимҗан Ибраһимов: әдипнең 100 еллыгына багышланган фәнни конференция тезислары» дигән җыентык нәшер ителә.

Г. Мөхәммәдованың «Олы юл» дигән документаль повесте нәшер ителә.

Уфада С. Ш. Поварисовның «Поэтика художественной прозы Г. Ибрагимова: (Учебное пособие для студентов-филологов)» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

**1990**

Бакуда С. Ш. Поварисовның «Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка» дигән монографиясе нәшер ителә.

Бакуда С. Ш. Поварисов тарафыннан «Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка» дигән темага докторлык диссертациясе яклана.

**1991**

Казан шәһәре Мәскәү районы халык депутатлары Советының 26 нчы август 701 нче санлы карары нигезендә Восстания урамындагы 48 йортта урнашкан 13 нче санлы урта мәктәп бинасының бер өлеше 1 сентябрьдә ачылачак татар гимназиясенә тапшырыла һәм, аңа санау номеры бирелмичә, алга таба «Галимҗан Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе» дип атала.

**1992**

24 ноябрь. А. Х. Садекова тарафыннан «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Уфада С. Ш. Поварисовның «Г. Ибрагимов и татарский литературный язык» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

**1993**

Апрель башлары. Башкортстан АССРның Авыргазы районы Солтанморат авылында 1987 елның 6 июнендә ачылган әдәби музее янгын казасына дучар була.

Уфа шәһәрендә Ибраһимов исемендге бульварда урнашкан 25 санлы йортның диварына истәлек тактасы куела.

**1994**

Казанда Г. Мөхәммәдованың «Олы юл» дигән документаль повестьте нәшер ителә.

**1995**

Казанда А. Х. Садекованың «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» дигән монографиясе нәшер ителә.

**1996**

Әдәбиятны, сәнгатьне һәм халык иҗатын үстерү, пропагандалау максатында Авыргазы районы хакимияте тарафыннан Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия булдырыла.

28 ноябрь. Тууына 110 ел тулу уңаеннан Казанда Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясендә әдипнең музее ачыла.

**1997**

Тууына 110 ел тулу уңаеннан Солтанморат авылында Г. Ибраһимовның яңа йорт-музее ачыла.

28 март. Тууына 110 ел тулу уңаеннан Башкорт дәүләт педагогия институтында фәнни конференция уздырыла.

19 март. Тууына 110 ел тулу уңаеннан 17 мартта Башкорт дәүләт педагогия институтында республика фәнни конференция уздырылуы хакында «Башҡортостан» газетасында хәбәр бастырыла.

24 март. Тууына 110 ел тулу уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясе, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни конференция уздыра.

Тууына 110 ел тулу уңаеннан Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театрында тантаналы кичә уздыра.

31 март. Җәмгыятькә файдалы зур эзләнү-тикшерү эшләре алып барган, кызыклы экспозицияләр (күргәзмә әсбаплар) булдырган һәм укучыларны тәрбияләүдәге уңышлары өчен Казан шәһәре Г. Ибраһимов исемендәге гимназия әдәби музеена Мәктәп музее исеме бирелә.

Казанда С. Ш. Поварисовның аңа багышланган трилогиясенең «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында» дигән беренче һәм икенче томнары нәшер ителә.

Кырымның җөмһүрият мәдәният фонды янында оешкан милли җәмгыятьләр ассоциациясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге премия булдыра.

**2000**

Тууына 100 ел тулу уңаеннан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында 1987 елның 11 мартында ачылган музей-бүлмәсе юкка чыгарыла.

Уфада С. Г. Сафуановның (1931–2009) «Галимҗан Ибраһимов һәм Башкортстан: «Әдәбияттан туган як белән бәйләп өйрәнү» фәне буенча кулланма» дигән китабы нәшер ителә.

Ялта шәһәрендәге «Равенство» (рәисе С. Невретдинов) милли азчылыклар шурасы, «Акчура» (рәисләре Р. Акчурин, Рәисә Алексеева) татар үзәге Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы урнаштыру турында шәһәр җитәкчелегенә мөрәҗәгать итә.

**2001**

Г.С. Хәйруллина тарафыннан «Переводы произведений Галимджана Ибрагимова на русский язык: поэтика и стиль» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

«Әсәрләр»енең 9 нчы томы нәшер ителүе хакында «Казан утлары» журналының 5 нче санында хәбәр бастырыла.

Казанда С.Ш. Поварисовның аңа багышланган трилогиясенең «Оҗмахка бер адым» дигән өченче томы нәшер ителә.

**2002**

Казанда Р. Ф. Исламов тарафыннан төзелгән «Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары» нәшер ителә.

Уфада әдәбият галиме С.Г. Сафуановның «Галимҗан Ибраһимов һәм Башкортстан» дигән китабы нәшер ителә.

**2003**

Уфада С.Ш. Поварисовның «Роль Г. Ибрагимова в развитии татарского литературного языка: Учебное пособие» дигән уку әсбабы нәшер ителә.

**2004**

2 июль. З.Г. Сәлахова тарафыннан «Галимҗан Ибраһимов иҗатында натурализм» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Л.З. Хәкимова тарафыннан «Формирование и эволюция общественно-политических и исторических взглядов Галимджана Ибрагимова» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

Казан Татар дәүләт яшь тамашачылар театрында Фәнәвил Галиев (1960–2012) тарафыннан Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәре сәхнәләштерелә.

Уфада С.Ш. Поварисовның «Г. Ибраһимов поэтикасында фразеология» дигән китабы нәшер ителә.

**2005**

21 ноябрь. Б.Э. Хәкимов тарафыннан «Галимҗан Ибраһимовның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклана.

**2007**

Казанда «Галимҗан Ибраһимов. Хикәяләр, повесть, роман», «Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр» дигән китаплар нәшер ителә.

5 март. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Яр Чаллы педагогия институтында «Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман» дигән фәнни-гамәли конференция уздырыла.

16 март. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Түгәрәк өстәл» уздырылуы хакында «Мәдәни җомга» газетасында хәбәр бастырыла.

23 апрель. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Казанда «Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция уздырыла һәм Ф. Х. Миңнуллина төзегән шул исемдә җыентык нәшер ителә.

16–17 март. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Стәрлетамак дәүләт педагогия академиясендә «Галимҗан Ибраһимов һәм татар дөньясы» дигән Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция уздырыла.

22 март. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Стәрлетамак шәһәрендә уздырылган фәнни-мәдәни чаралар хакында «Кызыл таң» газетасында хәбәр бастырыла.

23 апрель. Тууына 120 ел тулу уңаеннан Казанда «Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция уздырыла.

Тууына 120 ел тулу уңаеннан Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры «Тирән тамырлар» дигән әдәби-музыкаль кичә уздыра (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында).

Казанда Рөстәм Акъегет төзегән «Ибраһимов Г.: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр» дигән китап нәшер ителә.

25 октябрь. Ялта шәһәре хакимияте Халтурин урамында Г. Ибраһимов яшәгән йортка истәлек тактасы кую хакында 2119 санлы Карар кабул итә.

